*Тел язмышы –*
*халык язмышы*



*Асыл сүзләреңне, туган телем,*
*Биреп торчы миңа азга гына.*
*Бөтенләйгә түгел – вакытлыча,*
*Тик җитәрлек гомер азагыма.*

*Родной язык, мне драгоценных слов*
*Побольше дай, сокровищ не жалей.*
*Не навсегда, я их вернуть готов*
*В последний миг исхода моих дней.*

Р. М. Миңнуллин, К. М. Миңнуллин

# Тел язмышы – халык язмышы

Казан • «Мәгариф» нәшрияты • 2008

УДК 811.512.145 : 94(470.41)
ББК 81.2Тат я7
М 57

**Миңнуллин Р. М.**
М 57 Тел язмышы — халык язмышы / Р. М. Миңнуллин, К. М. Миңнулин.— Казан : Мәгариф, 2008.— 231 б.: рәс. б-н.
ISBN 978-5-7761-1905-7

ISBN 978-5-7761-1905-7 © «Мәгариф» нәшрияты, 2008

# Кереш сүз

Туган телебезне, шулай ук Татарстанда яшәүче башка халыкларның телләрен дә саклау, үстерү, баету, аларның киләчәген кайгырту мәсьәләләренә багышланган ошбу куш китапның дөнья күрүе бик тә табигыйдер шикелле. Чөнки без — биш бертуган Миңнуллиннар — һәммәбез дә, гомеребез буе мәктәп-мәгърифәткә, әдәбият-сәнгатькә, фән-гыйлемгә хәл кадәри хезмәт куеп, туган телнең кадерен тоеп, тел хәзинәбезне башка милләттәшләребез дә, бигрәк тә яшь буын һәм читтә гомер кичерүче кардәшләребез белсен дип яшәүче кешеләр. Ә инде икебезгә – шушы китапның авторларына – туган телгә кагылышлы бик тә җаваплы, шул ук вакытта үтә дә катлаулы мәсьәләләр белән (беребезгә республикабыз парламентында, икенчебезгә хөкүмәттә) озак еллар шөгыльләнергә туры килде. Язмыш безгә милләтебез язмышы хәл ителгән шушы авыр һәм хәлиткеч бер чорда телләрне саклау һәм үстерү өлкәсендә дәүләт сәясәтен булдыруда һәм аны тормышка ашыруда турыдан-туры катнашу мөмкинлеге бирде. Китапка нәкъ менә шул вакытларда язылган мәкаләләр, төрле югарылыктагы мөнбәрләрдән сөйләнгән чыгышлар, шул еллардагы эшчәнлегебезне чагылдырган актуаль әңгәмәләр туплап бирелде.

Татарстанда ике дәүләт теле закон нигезендә гамәлгә кертелеп, алар акрынлап булса да шактый актив кулланылышка керә башлаган шартларда, безгә, әлбәттә, һәм татар, һәм рус телләрендә язарга, гәпләшергә, чыгышлар ясарга туры килә. Китаптагы материалларның ике телдә булуы шуның белән бәйләнгән, һәрберебезнең язмалары, хронологик тәртипләрен саклаган хәлдә, аерым-аерым ике бүлеккә бүлеп бирелде. Бу үз чиратында, әлеге мәкаләләргә, чыгышларга карап, узган гасырның 90 нчы елларыннан бүгенге көнгә кадәр Татар-

стандагы тел сәясәтенең нинди шартларда үсүен, тирәнәюен, нинди яңа аспектлар белән баюын күзәтергә мөмкинлек бирер дип уйлаштык.

Безнең беребез — Татарстанның халык шагыйре, Татарстан Дәүләт Советы депутаты, Татарстан Республикасы законнарын тәңгәлләштерү комиссиясе рәисе, икенчебез — әдәбиятны һәм халык авыз иҗатын өйрәнүче галим, фәннәр докторы, Татарстан Фәннәр академиясенең мөхбир әгъзасы, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры. Табигый ки, күңелебез кушканга да, вазифаларыбыз буенча да без татар теленең язмышы өчен борчылып, аны кайгыртып яшибез, татар теле чын мәгънәсендә дәүләт теле булсын өчен, кулыбыздан килгәннең барысын да эшләргә тырышабыз. Җәмгыятьтә кайсыдыр бер телгә генә өстенлекләр бирелергә тиеш түгел, киресенчә, яшәсен, үссен өчен, һәрбер телгә тигез хокуклар, тигез мөмкинлекләр тудырырга кирәк. Татарстанда алып барылган телләр сәясәте нәкъ шуны күздә тота да.

*Авторлар*

# Душа народа в его языке

Пожалуй, в любом сборнике афоризмов, мудрых мыслей выдающихся людей разных времен и народов едва не самый большой раздел занимают высказывания о роли и судьбах языков. Вот лишь несколько примеров в подтверждение: «Как ни говори, а родной язык всегда останется родным. Когда хочешь говорить по душе, ни одного французского слова в голову нейдет, а ежели хочешь блеснуть, тогда другое дело» (*Лев Толстой*). «Знать много языков — значит иметь много ключей к одному замку» (*Вольтер*). «Для познания нравов какого ни есть народа старайся прежде изучить его язык» (*Пифагор*). «В языке одухотворяется весь народ и вся его родина... Язык есть самая живая, самая обильная и прочная связь, соединяющая отжившие, живущие и будущие поколения народа в одно великое, историческое, живое целое» (*К.Д.Ушинский*).

В мудрой справедливости приведенных слов глубоко убеждаешься, читая страницы книги, которую вы, читатель, держите в своих руках. В ней собраны материалы — интервью, статьи в периодических изданиях, тексты публичных выступлений, объединенные одной темой — заботой о сохранении и развитии родного языка татарского народа. Их авторы — братья Миннуллины, люди в нашей республике широко известные, уважаемые, и по призванию, и по душе тесно связанные с татарским языком, преданно ему служащие: Роберт Миннуллин — народный поэт Татарстана, лауреат Госпремии имени Г.Тукая, депутат Госсовета РТ, в котором сегодня возглавляет Комиссию по установлению идентичности текстов законов на татарском и русском языках; Ким Миннуллин многие годы возглавлял отдел по развитию языков народов Татарстана Аппарата Кабинета Министров РТ, ныне — директор Института языка, литературы и искусства имени Г.Ибрагимова Академии наук РТ.

Книга рассчитана на двуязычного читателя, в ней в равной степени представлены публикации как на татарском, так и на русском языке. И начать читать ее я предложил бы прежде всего со статьи Роберта Мин-

нуллина «Ни хәлдә син, туган тел?» («Как живется тебе, язык родной?»). В ней, на мой взгляд, — суть, квинтэссенция данной книги: безмерная любовь автора к родному языку, восхищение его мощью и красотой и одновременно беспокойные раздумья о дальнейшей судьбе его в условиях экспансии мирового глобализма.

Я употребил слово «статья» для определения жанра этой публикации, но это скорее условно, ибо трудно точно сказать, что это — статья, новелла, эссе; это душевный, доверительный разговор автора с читателем, способным близко к сердцу принять его волнения, тревоги, раздумья об историческом пути татарского народа, прошлом и нынешнем состоянии его родного языка.

И вот эта доверительность, искренность авторов красной нитью пронизывает все материалы данного сборника. Констатируя, что с обретением суверенитета в Татарстане были сделаны важные шаги на пути возрождения национального самосознания, сохранения и развития языков и культур проживающих здесь народов, в том числе приняты Закон о государственных языках и программы по его реализации, Роберт и Ким Миннуллины не устают, каждый со своих гражданских и должностных позиций, вновь и вновь повторять: это лишь первые шаги на трудном, тернистом пути, ни в коем случае нельзя успокаиваться, а надо постоянно наращивать усилия по претворению замыслов в жизнь, нужна ежедневная кропотливая работа власти, общественных институтов для осуществления реального, а не декларативного двуязычия в республике.

Не буду пересказывать содержания книги, предоставлю читателю возможность самому убедиться в том, что она не оставляет равнодушным. Да, наверное, можно поспорить с авторами по тем или иным частным моментам, найти, быть может, контраргументы в трактовке отдельных положений, но в целом невозможно не согласиться с ними в том, что сохранение и дальнейшее развитие татарского языка, так же как и русского, и других языков Татарстана, есть непременное условие благополучия и процветания нашей многонациональной республики. Иных вариантов эта задача для положительного ответа не имеет.

*Шамиль Мулаянов*

# Р. М. МИҢНУЛЛИН



*Телләр күп ул бу дөньяда, әмма синең кебеге булмас. Минем өчен синнән дә затлысы, синнән дә татлысы табылмас. Булса да, аңысы барыбер чит-ят, үги тел булыр. Башка телгә минем ата-бабамнарның моңы, аларның ачы газабы, өмет-хыяллары сеңмәгән. Фәкать син генә минем туган телем!*

*Я твердо верю в одно: язык – зеркало души народа. Каков дух народа, таков и его язык.*

## ТУГАН ТЕЛ БӘЙРӘМЕ

«Газизләрдән газиз, изгеләрдән изге туган телем, мин бу бәйрәмгә синнән гафу сорарга килдем. Булдыралсаң кичер син без фәкыйрьләреңне. Без бит сине шушы хәлгә төшердек, без бит сине тоткын шикелле өйләребездә бикләп тоттык, без бит сине җәмгыятебезнең иң кирәк урыннарыннан куып чыгардык, без бит сине дәүләт күләмендә хәл ителә торган биек йортларга якын да җибәрмәдек. Телем-телем итеп телдек без сине, газиз телем. Кичер син безне!

Бу ялваруларым сине оныткан, сине санга сукмаган, синнән оялган милләттәшләрем исеменнән дә, үзләре дә руслашып беткән, балаларын да, оныкларын да шул юлга этәргән татарлар исеменнән дә, сине «законнан тыш» дип игълан иткән, сине мәктәпләребездән, балалар бакчаларыннан куып чыгарган бәгъзе иптәшләр исеменнән дә...

Газиз телем, без сине имгәтеп, гарипләндереп бетердек түгелме? Сине танымаслык хәлгә китердек түгелме? Кол Галиләр кайтса, телдән язарлар иде. Тукайлар кайтса, сине танымаслар иде. Җәлилләр кайтса рәнҗерләр иде безгә. Әле дә ярый алар күрми, әле дә ярый бабаларыбыз белми бу дөньяда безнең ниләр белән шөгыльләнеп ятканыбызны. Югыйсә күпме ләгънәт сүзләре ишеткән булыр идек...

Телләр күп ул бу дөньяда, әмма синең кебеге булмас. Минем өчен синнән дә затлысы, синнән дә татлысы табылмас. Булса да, анысы барыбер чит-ят, үги тел булыр. Башка телгә минем ата-бабамнарның моңы, аларның ачы газабы, өмет-хыяллары сеңмәгән. Фәкать син генә минем туган телем!

Газиз телем, алай да син исән әле. Шөкер, бөтенләй үк бетмәдең әле. Сине саклаучылар булмады түгел, булды. Үзебез синнән йөз

чөергәндә дә, чит мәмләкәтләрдә яшәүче туганнарыбыз саклады сине. Без язарга курыкканда да, Башкортстанның олуг шагыйре Нажар ага Нәҗми яклап чыкты сине. Галимнәребез, әдипләребез саклады. Татар авыллары алып калды».

«Туган тел бәйрәме»ндә сөйләдем мин әлеге сүзләремне. «Ватан» җәмгыяте оештырган бу бәйрәм туган телебезгә, аның язмышына багышланган иде. «Туган тел» кичәләрендә, әдәби-музыкаль бәйрәмнәрдә еш катнашканым бар югыйсә. Казан мәктәпләрендә, аерым сыйныфларда, район күләмендәге фестиваль-смотрларда... Әмма мондыенда катнашканым юк иде әле. Үзенең зурлыгы белән, мөһимлеге, актуальлеге белән башка бәйрәмнәрдән аерылып торды ул. Үзе концерт та, митинг та, кичә дә, үзе бик җитди мәҗлес тә, үзе олы бер милли бәйрәм дә иде Академия театры мәйданында.

Илебезнең төрле төбәкләреннән, җиребезнең төрле илләреннән килгән милләттәшләребез дә бизәп җибәрде бәйрәмне. Туган телебезне Төркия, Япония, Финляндия, Австралия, Көнбатыш Германия кебек ерак илләрдән җыелган татарлар авызыннан ишетү бигрәк тә тәэсирле булды. Чыннан да, ул илләрдә дә яши икән, яңгырый икән бит безнең телебез. Әйе, әйе, митингта да алар безне татар телен саклап калырга чакырып сөйләделәр. Югыйсә туган телнең кирәклеген хәзер үзебез дә аңлый башладык бугай инде. Шулай булмаганда, туган тел бәйрәменә меңләгән кеше җыелмас иде!

*1990*

## БАЛАЛАР КИТАБЫ — ТУГАН ТЕЛ АЧКЫЧЫ

Мин «Мәгариф» нәшриятының соңгы берничә ел эчендә аякка басуына, әйбәт кенә эшләп килүенә чын күңелдән шатланам. Әлбәттә, аның чоры да шундый туры килде. Авыр, ләкин яңалыкка омтылу, уяну чоры бу. Хәер, бөтен дөнья кузгалганда да йоклап калырга мөмкин. «Мәгариф» нәшрияты шул дәвердә бик күп җитди, кыю адымнар ясарга өлгерде. Мин өр-яңа дәреслекләрне, бигрәк тә тел һәм әдәбият дәреслекләрен күз алдында тотам. Нәниләр өчен бик кызыклы кулланмалар, сүзлекләр, әлифбалар чыкты. Бу китапларның төс-сурәтләре дә, эчтәлекләре дә Мәскәү дәрәҗәсендә дияр идем. Безгә шушы дәрәҗәгә ирешү кирәк иде.

Индус ага Таһиров кызыклы фикер әйтте: чыннан да, «адәм баласы гомере буена мәктәп елларында алган белем-мәгълүмат белән яши. Нигезе шунда». Шуңа күрә безнең әдәбият дәреслекләре бик яхшы булырга, аларга хәзинәдәге иң асыл җәүһәрләр сайлап алынырга тиеш. Татар баласы үз халкының бай әдәби мирасыннан, бүгенге әдәбият һәм мәдәният казанышларыннан мәхрүм ителгән хәлдә калса, бу — милләтнең киләчәгенә юлны кисү, аның тамырына балта чабу булыр иде.

Без үз әдәбиятыбыз белән генә чикләнмичә, рус һәм чит ил классикасын да, нигездә, татар телендә укырга тиешбез. Үзебезнең казаныбызда гына кайнау — балаларыбызның дөньяны танып белүен чикләү дигән сүз. Мәктәптә дөнья әдәбияты фәнен дә татар телендә өйрәтә башларга вакыт. Нигә без аны рус теле, рус әдәбияты аша гына кабул итәргә, ягъни «куян шулпасының шулпасы» белән генә канәгатьләнеп калырга тиеш, ди.

Әлбәттә, «Мәгариф» нәшрияты — дәреслекләр чыгаручы нәшрият. Ләкин коры дәреслек белән генә без берничек тә тулы канлы, рухы һәм зиһене бай татар баласы тәрбияли алмыйбыз. Дәреслек янына ел саен 15—20 өстәмә китап — матур әдәбият, фәнни-популяр әдәбият булырга тиеш. Әлеге китапларны чыгару — нәкъ менә «Мәгариф» нәшриятының вазифасы. Бу — бик җитди төстә куелырга тиешле мәсьәлә, һәм моны дәүләт үз карамагына алырга тиеш. Шул чакта гына без чын мәгънәсендә дөньяны татарча аңлауга ирешә алабыз, татар теленә хөрмәт уята, аны өйрәтә алабыз.

«Мәгариф» җитәкчелегендә моны аңлау да, теләк тә бар. Дәреслектән тыш та күзгә күркәм, зиһенгә тәэсирле байтак китап чыккан. Ләкин күбрәк иганәчеләр ярдәмендә генә чыга әле китапларыбыз. Шуңа күрә хәтта Татарстанның халык шагыйре Шәүкәт Галиев тә юка гына бер китап та чыгара алмый йөри. Югыйсә Ш.Галиевтән башка бүгенге татар балалар әдәбиятын күз алдына да китереп булмый. Юньле дәреслекләр дә аның иҗатыннан үрнәк-мисалларсыз гына чыга алмый. «Мәгариф» нәшрияты, дүрт-биш табаклы гына китабын бастырып бирсә дә, шагыйрьгә бурычын беркадәр кайтара алыр иде... Мөмкинлек чикләнгәч, коры теләк белән генә булмый шул. Бу мәсьәләне хәл

итү юлын әлегә кадәр таба алганыбыз юк. Кирәклеген таныйбыз, сөйләшәбез, ә бюджетка килеп терәлгәч, бөтенесе юкка чыга да куя. Хәтта билгеләнгән акчаның да яртысыннан артыгын биреп җиткерә алмау — дәреслекләр, балалар китабын чыгару мәсьәләсен өстенлекле, мөһим бер эш-юнәлеш итеп карамау нәтиҗәсе ул. Милләтнең киләчәген тәрбияләү буенча эзлекле җитди сәясәт булганда гына үзеңне мәгърифәтле илдә яшим дип санарга була.

*1995*

## ФЕДЕРАЛИЗМ И ЯЗЫКИ НАЦИОНАЛЬНЫХ МЕНЬШИНСТВ — СОСТОЯНИЕ И ПЕРСПЕКТИВЫ НА ПРИМЕРЕ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Когда мы говорим о федерализме, о федеративном устройстве Российской державы, как правило, забываем о языковом факторе. Между тем опыт различных регионов России и СНГ показывает, что языковая проблема в любой момент может стать мощным катализатором межнациональных противоречий. Об этом говорит, в частности, горький опыт Прибалтики и Молдовы. Языковые проблемы обострили взаимоотношения коренного населения Средней Азии с русскоязычным населением.

Понимая и учитывая все это, Верховный Совет нашей республики в Декларацию о государственном суверенитете, которая была принята 30 августа 1990 года, записал следующие слова: «В Татарской ССР гарантируется равноправное функционирование татарского и русского языков в качестве государственных, сохранение и развитие языков других национальностей». Затем мы приняли Закон «О языках народов Республики Татарстан», в котором сказано, что на территории Республики Татарстан каждому народу и каждому человеку государством создаются условия для сохранения и всестороннего развития родного языка, обеспечивается свобода выбора в использовании языка общения.

Два года назад Верховный Совет принял Государственную программу по сохранению и развитию языков народов республики, и

этим мы, с одной стороны, сняли возможность обострения межнациональных отношений, с другой — предъявили особые требования к развитию двуязычия. Все это определенным образом сняло напряжение в обществе вокруг татарского языка, создав возможности для перевода в практическое русло решения проблем повышения его статуса как государственного.

Обучение в школах сегодня ведется у нас на шести языках: татарском, русском, чувашском, марийском, удмуртском, мордовском. Есть школы с 2—3 языками обучения. В ряде городов открыты воскресные чувашские, еврейские, азербайджанские, армянские, украинские школы и классы. В 143 школах Татарстана 21 процент детей чувашей обучаются на чувашском языке и 44 процента изучают родной язык; в 39 школах 23 процента детей удмуртов обучаются на удмуртском языке и 63 процента изучают родной язык; в 19 школах 22 процента марийских детей обучаются на марийском языке и 42 процента изучают родной язык.

В Татарстане во всех школах, начиная с 1 класса, введено обязательное изучение татарского языка. Если сравнивать с прошедшими годами, это очень большое достижение. Но это только начало.

Все благодарны великому русскому языку за то, что он открыл татарскому народу путь к европейской цивилизации, мировой культуре. Но мой народ хочет, чтобы и татарский язык был полноценным государственным языком. К великому сожалению, до последнего времени он являлся чисто бытовым языком. Определенная часть татар перестала говорить на родном языке.

За несколько лет сделано немало. Но реализация закона и программы идет очень медленно и болезненно. Законотворческий процесс, делопроизводство, судопроизводство осуществляются только на русском языке.

Неравноправное положение русского и татарского языков видно на каждом шагу. Если без знания русского языка полнокровной жизнью жить в Татарстане невозможно, то без знания татарского языка можно жить и здравствовать без особых проблем.

Нам необходимо создать такую общественную атмосферу, когда введение двуязычия велось бы не насильственно, а обучение второму языку было бы привлекательным и желанным занятием.

Еще одна проблема — это сохранение и развитие языка татар, проживающих за пределами нашей республики. В России и странах СНГ живут более пяти миллионов татар.

Мы должны честно признаться, что на сегодняшний день республика не в состоянии полностью обеспечить их учебниками, методическими пособиями, татарской литературой, национальными кадрами. К тому же для развития языка нужны не только школы, нужна благоприятная среда. А наши соотечественники изолированы от татарского мира. Они находятся в информационной блокаде. Татарское телевидение не смотрят, татарское радио не слушают, татарские газеты и журналы не выписывают. И наши книги до них не доходят. Во многих татарских селениях обучение идет только на русском языке. Очень редко встречаются школы, где татарский язык и литература преподаются как предмет.

Говорить об этом очень больно, но есть все основания считать, что за пределами республики татарский язык постепенно идет к вымиранию.

Единственное исключение — это Республика Башкортостан, где проживает полтора миллиона татар, которым удалось сохранить родной язык.

Я глубоко убежден, что эта проблема должна беспокоить российское руководство. Оно должно вплотную заниматься вопросами языков национальных меньшинств. Я запомнил слова Президента Казахстана Назарбаева, который сказал, что татары, проживающие в Казахстане,— это его татары. И Президент Российской Федерации должен сказать также: «Российские татары — это мои татары». Но признаться в этом, наверное, нелегко, так как о своих татарах придется по-отечески заботиться.

До сих пор почему-то не выходит общероссийская газета на татарском языке, нет радио и телеканала для национальных республик. Почему в Москве, где проживает полмиллиона татар, нет ни одного татарского театра, ни одной солидной газеты, ни одной школы?

Российское правительство в ближайшее время должно решить такие вопросы, как открытие татарских отделений в вузах ряда городов России, восстановление татарских учебных заведений и библиотек за пределами Татарстана. Мы готовы содействовать в решении этих вопросов.

*1996*

## ТАТАР ТЕЛЕНӘ ИХТЫЯҖ...

Татар халкы яңадан үзенең дәүләтчелеген торгызырга омтыла. Цивилизацияле, демократик дәүләтләр исә үз законнары белән яшәргә тиеш. Элекке Югары Советның, бүгенге Дәүләт Советының эшчәнлеге, бу җәһәттән, әйтеп бетергесез әһәмияткә ия. Ул кабул иткән законнар, аерым алганда, дәүләт суверенлыгы турындагы Декларация, Татарстан Конституциясе мөстәкыйльлегебезнең нигез ташлары булды. «Татарстан Республикасы халыклары телләре турында»гы Законны да мин иң мөһим законнарның берсе дияр идем. Халкыбызның рухи күтәрелеше чорында аның роле, һичшиксез, зур булды. Анда акка кара белән «Татарстан Республикасында тигез хокуклы ике дәүләт теле: татар һәм рус телләре кулланылышта йөри» дип язылган. Димәк, бу Закон татар телен үстерү өчен бөтен мөмкинлекләрне дә бирә. Шул мөмкинлекләрдән файдалана белергә генә кирәк. Файдаланабызмы, файдалана беләбезме соң?

Телләр турындагы Законны тормышка ашыруның беренче этабы, дөресрәге, әзерлек чоры төгәлләнеп килә дияргә мөмкин. Моннан ике ел элек «Татарстан халыкларының телләрен саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Дәүләт программасы» кабул ителгән иде. Аның күп кенә өлеше тормышка ашып бара. Саный китсәк, мисалларны күпләп китерергә мөмкин булыр иде. Моннан биш-алты ел элекке белән бүгенгене чагыштырып карасаң, әлбәттә, аерма җир белән күк арасы. Казанда, башка шәһәрләрдә татар мәктәпләре, татар гимназияләре, лицейлары күпләп ачыла. Техник вузларда да татар төркемнәре ачар өчен мөмкинлекләр арта. Мәктәпләр һәм вузлар өчен шактый гына яңа дәреслекләр язылды, сүзлекләр, лексик минимумнар басылып чыкты. Радио-телевидениедән татар теле

дәресләре бара. Бик күп дәүләт оешмаларында татар теленә өйрәнү түгәрәкләре эшли. Балалар бакчаларында татар төркемнәре, хәтта аерым татар балалар бакчалары да бар бездә хәзер. Хөкүмәтнең дә, министрлыкларның да, район җитәкчеләренең дә татар теленә булган мөнәсәбәтләре, акрынлап булса да, әйбәт якка үзгәрә дияр идем. Министрлар Кабинетында, мәсәлән, телләр турындагы Законны тормышка ашыру комитеты төзелде. Шундый ук комитетлар соңгы вакытта һәрбер районда, һәрбер шәһәрдә оеша башлады. Һәрхәлдә, бүгенге яшь буынга татар телен өйрәнсен өчен бик күп мөмкинлекләр тудырылган. Һәм алар киләчәктә үз телләрендә иркенләп укырлар, белем алырлар, үзара рәхәтләнеп сөйләшерләр, аралашырлар, татар телен дәүләт теле сыйфатында файдаланырлар дип ышанам мин.

Әмма шушындый мөмкинлекләр, шушындый зур үзгәрешләр булуга да карамастан, татар теле дәүләт теле дәрәҗәсенә күтәрелүдән шактый ерак тора әле. Моның, әлбәттә, һәм объектив, һәм субъектив сәбәпләре бардыр. Дөресен әйтергә кирәк, бүгенге көндә татар телен гамәлгә кертүнең, гомумән, икетеллелекнең фәнни концепциясе бездә әле бөтенләй эшләнмәгән. Программабыз да бүгенге көн күзлегеннән караганда гади эш планын гына хәтерләтә. Фәлән әйберне фәлән вакытка эшләргә генә диелгән анда. Ә менә ул бурычларны ничек итеп тормышка ашырырга? Ул хакта ләм-мим. Әйтик, Финляндиядә яисә Бельгиядә ике-өч тел — дәүләт теле. Беларусьта белорус һәм рус телләре икесе дә — дәүләт теле. Казахстанда казах теле — дәүләт теле, ә рус теле — аралашу теле генә. Аларның эш тәҗрибәләре белән беребез дә таныш түгел. Тырыша-тырыша «велосипед уйлап табарга» җыенабыз. Үзара татарча сөйләшеп йөрү ул әле бер хәл. Анысына акрынлап булса да күнегербез, өйрәнербез. Әмма дәүләт оешмаларында бөтен эшне дә ике телдә дә алып бармый торып, татар теле, чын мәгънәсендә, дәүләт теле була алмаячак. Мәсәлән, шул ук Финляндиядә рәсми документлар фин телендә генә языламы, әллә инде ике телдәме? Рәсми җыелышлар нинди телдә бара? Ике телдәме, түгелме? Швед белән фин үзара нинди телдә сөйләшәләр? Анда ике телне белү мәҗбүриме? Боларның барысын да белергә кирәк бит безгә. Башкаларның тәҗрибәсен өйрәнергә,

эшебездә файдаланырга кирәк! Ә иң мөһиме, татар теленә ихтыяҗ тудырырга тиешбез һәм тудырырбыз дигән ышанычым бар. «Башлаган эш — беткән эш», — ди бит халкыбыз.

*1996*

## ӘЛЕ МАМАДЫШКА ГЫНА ИЛТӘ

Телләр турындагы Законның әһәмиятен аңлатулар, аның кирәклеген дәлилләргә тырышулар кирәксез бер эштер. Ул Законның, Дәүләт программасының мөстәкыйльлегебез белән, моннан нәкъ 5 ел элек кабул ителгән Конституциябез белән турыдан-туры бәйле икәнен кат-кат кабатлау да кирәк булыр микән?!

Кем-кем, әмма без барыбыз да боларның барысын да, ниһаять, аңладык бугай инде.

Моннан ел ярым элек булып узган шушындый уртак комиссия утырышында сөйләнгән сүзләр, чыгышлар минем бүген дә хәтеремдә. Анда күбрәк җан ачысы белән әйтелгән сүзләр, фикерләр, зарлану, эшләнмәгән эшләрне акча юклыкка сылтарга тырышу, күңел төшенкелеге өстенлек иткән иде. Инде менә Министрлар Кабинеты тәкъдим иткән мәгълүматны карап чыкканнан соң, белешмәләр, отчетлар белән танышканнан соң, эчкә бераз җылы керде, күңелдә аз гына өмет уянды. Нәрсә генә дисәк тә, ничек кенә зарлансак та, азмы-күпме алга китеш сизелә, нәтиҗә бар, кулга тотып карарлык китаплар, дәреслекләр бар. Хәтта күптән хыялланган тел турындагы журналның да беренче саны чыкты. Шунысы гыйбрәтле: бер мәгълүм тел галимебез матбугат битләрендә: «Тел турында журнал кирәк», — дип зарланып язган көнне икенче бер галимебез миңа шул журналны кулыма тоттырды. Күрәсез, берәүләр һаман зарлана, елый, икенчеләр җиң сызганып эшләргә тырыша. Сүз уңаеннан шуны да әйтим: Казан шәһәр Советы сессиясенең чираттагы утырышында телләр турындагы Законны тормышка ашыру буенча программа каралды. Анда хакимият башлыгы урынбасары Фаил Әхмәдиев доклад белән чыкты һәм әлеге журнал турында да әйтеп китте, шул ук вакытта матди ярдәм күрсәтергә, елга дүрт тапкыр чыгарырга кирәк дигән фикерне әйтте.

Сүземне отчетлардан башлаган идем. Гомумән, аларга ышансаң, эшләр бездә элек тә әйбәт бара иде, хәзер дә шәп бара. Әмма шунысын да онытмыйк: отчетлар, гадәттә, еш кына алдаучан була. Без аларның ничек язылганын, саннарның кайлардан алынганын, ул саннарның ничә кул аша узганын яхшы беләбез һәм шуңа күрә ул отчетларга өлешчә генә ышанырга мәҗбүрбез. Мин инде монда белешмәләрдә китерелгән мисалларга тукталып тормыйм. Алар күп, алар әйбәт, алар күңелне тынычландырырлык. Мин кайбер уйлануларымны, теләкләремне генә сезгә җиткермәкче булам. Югары уку йортлары элек-электән үзләренең интеллектуаль көчләре, гыйльми, хәтта сәяси, иҗтимагый потенциаллары белән аерылып тордылар, җәмгыятьне әйдәп баручылар рәтендә булдылар. Тарихтан бик күп мисаллар китерергә мөмкин булыр иде. Әмма, ни гаҗәп, үзгәртеп коруның беренче чорында бераз гына активлык күренсә дә, икетеллелек мәсьәләсенә килеп терәлгәч, вузлар инициативаны үз кулларына ала алмадылар. Мин биредә бигрәк тә әлеге проблемага фәнни яктан якын килүне, теоретик хезмәтләрне, яңа идеяләрне күз алдында тотам. Әгәр дә бу өлкәдә азмы-күпме эш эшләнгән икән, аларның барысы да диярлек, нигездә, аерым фидакарьләрнең, энтузиастларның тырышлыгы белән генә булдырылды. Минем аларга ихластан рәхмәтемне җиткерәсем килә. Тагын шунысы бераз гаҗәпкә калдыра: андый энтузиастлар күбрәк техник вузлардан. Мәсьәләне аңларга тырышу, Законны тормышка ашыруның кирәклеген аңлау, төрле фәнни-практик эзләнүләр шул вузларда ныграк сизелә. Алар яңа дәреслекләр язалар, тәрҗемә итәләр, методик кулланмалар бастыралар, татар төркемнәре булдырырга тырышалар. Сыйфатлары нindирәктер, анысы икенче мәсьәлә. Гуманитар вузларның шактыенда сәер тынлык хөкем сөрә. «Әйдәгез, фәлән белгечләр буенча кафедра, бүлек, факультет ачыйк!» — дигән тәкъдимнәр белән чыгучылар әлегә кадәр күренми. Югыйсә инде бүген үк республикабызга ике телдә эшләрлек югары белем алган бик күп төрле белгечләр кирәк. Авыл хуҗалыгы белгечләрен әйтеп тә тормыйм.

Бездә бүген ике телдә дә бердәй эшләүче юристлар юк. Закон-

нар язучылар гына түгел, юрист-практиклар да. Судларның күбесе татарча алып барылсын, дигән таләпләр көннән-көн ешрак яңгырый. Ике телле компьютер белгечләре, икътисадчылар кирәк, һәрбер җитди оешмага, министрлыкларга эш кәгазьләрен тәрҗемә итү өчен тәрҗемәчеләр таләп ителә. Синхрон тәрҗемәчеләр әлегә фәкать Дәүләт Советында гына. Әмма иманым камил, озакламый алар барлык оешмаларда да булачак. Әлегә төрле конгрессларда, кунаклар килгәндә, авылдагы туйдан туйга йөргән бердәнбер гармунчы кебек, Казандагы бердәнбер дежур тәрҗемәче Тәлгат Бариев йөри. Кызганыч, андый тәрҗемәчеләрне бер вузда да әзерләмиләр. Телевидениедә ни өчен сәяси тапшырулар татарча алып барылмый? Җитәкчеләрнең җавабы әзер: татар телен белүче сәясәтчеләр юк. Аларны, ягъни татар телле политологларны кем әзерләргә тиеш? Әлбәттә, гуманитар вузлар. Әмма без мәҗбүр иткәнне, өстән кушканны көтеп ятабыз.

Гомумән, бик күп вузларның җитәкчеләре телләр турындагы Законны тормышка ашыруда бүгенге ситуациядә гафу ителмәслек дәрәҗәдә озын-озак пауза ясадылар. 5—6 ел вакыт узса да, мәсьәләгә йөз белән борыла алмадылар. Мин аларны аңлыйм да шикелле. Аларның куллары Мәскәүгә сузылган. Шуңа күрә дә алар үзләрен мәгариф буенча Мәскәү наместниклары итеп хис итәләр. Ләкин без Татарстан җирендә яшибез, Татарстан балаларына белем бирәбез, үзебездә эшлисе белгечләр тәрбиялибез. Безнең вузлар — Россия вузлары түгел, ә бәлки Россия белән килешү нигезендә эшләүче вузлар. Мәскәүдән акча алсалар да, Татарстан салымнары хисабына яшәүче вузлар. Шуны онытмаска кирәк. Аннары вуз җитәкчеләре — дәүләт кешеләре. Алар суверенлыгыбызның локомотивы ролен үтәргә тиешләр. Кызганычка каршы, аларны кузгату бик авыр бер эш булып чыкты. Күп вузларда әлегә кадәр, урамдагы эленмә такталарны исәпкә алмаганда, татар телендәге язуларны таба алмыйсың. Яртылаш татар егетләре-кызлары укыса да, аларда татар рухы, татар дөньясы сизелми. Пензада да, Рязаньда да шул ук вуз, Казанда да шул ук вуз... Әлбәттә, моның объектив сәбәпләре дә җитәрлектер. Алар ике арада кысылып калганнар: ни ычкына алмыйлар, ни кычкыра алмыйлар. Алар

бездә беркемгә дә кирәкми дигән тәэсир кала. Сораучы да юк, сораучы булмагач, җавап бирүче дә юк.

Мәгариф министрлыгы мәктәпләр белән генә шөгыльләнә. Ярый әле Министрлар Кабинетында аларга күз-колак булучы бер референт бар. Нәрсә эшләргә соң? Беренчедән, Россия белән ике арадагы килешүне эшләтергә кирәк. Икенчедән, вузларның эшләрен координацияләүче бер үзәк булырга тиеш. Департаментмы ул, комитетмы ул, белмим. Бәлки, Мәгариф министрлыгына структур үзгәрешләр кертергә, статусын үзгәртергә, кайбер вәкаләтләрне аңа тапшырырга кирәктер. Бу хакта безнең депутатларыбыз берничә тапкыр тәкъдимнәр белән чыкканнар иде инде. Колак салучы гына булмады...

Сүз уңаеннан шуны да әйтергә кирәк саныйм: без, вузлар белән мавыгып, махсус урта белем бирүче техникумнарны, училищеларны бөтенләй күз уңыннан ычкындырдык. Аларның кайберләре белән генә министрлык шөгыльләнә. Ә менә республикадагы 30—40 техникум бөтенләй безнең контрольдә түгел. Аларның күбесе Мәскәү министрлыкларына карый. Ягъни ведомственный уку йортлары. Аларда татарча укыту — нуль! Әйтерсең лә анда безнең балалар укымый.

Нәрсә ул Татарстан шартларында югары милли уку йорты, нәрсә ул икетелле уку йорты? Югары уку йортында укучылар татар телен ни дәрәҗәдә белергә тиешләр? Әлбәттә, вузларыбыз төрле, максатлары да, укыту процесслары да, программалары да төрле. Шуңа күрә аларның һәрберсенең икетеллелек буенча үзләренең концепциясе булырга тиештер. Әйтик, медицина академиясен тәмамлаган табиб татар телен ничек белергә тиеш? Авиация институтындагы студент ни дәрәҗәдә белергә тиеш? Физматта ничек укытырга? Галимнәрнең әлегә кадәр уртак бер фикергә килә алганнары юк. Берәүләр: «Беренче курстан ук татарча укытырга кирәк», — диләр. Икенчеләр: «Русча гына укытсаң да ярый», — дигән караштa тора. Өченчеләр: «2—3 курс татарча укыткач, русчага күчәргә кирәк», — ди. Кем хаклы? Безгә калса, һәр вузның үз концепциясе булган очракта, шуларны бергә туплап, уртак бер концепция төзергә мөмкин булыр иде. Бу хакта вузара фәнни-гамәли конференция уздырырга

да вакыт җиткәндер. Әлегә без сукыр килеш кенә капшанып барабыз. Әллә инде без, яратып карый торган сериалдагы Аугусто кебек, күргән килеш тә күрмәмешкә салышып йөрибезме? Андыйларыбыз да бар шикелле.

Әлбәттә, беребезгә дә җиңел түгел. Күчеш чорлары беркайчан да җиңел генә булмаган. Мин татар мәктәпләрен тәмамлаган ата-аналарның да хәлләрен аңлыйм. Алар, балаларыбыз вузларга керә алмаслар, дип куркалар. Алар да хаклы. Без исә: «Менә без дә татар мәктәбен бетердек. Барыбер кеше булдык. Академик та, инженер да, шагыйрь дә булдык», — дибез. Президентны да мисалга китерәбез. Без дә хаклы. Болар барысы да тел культурасының, телләргә өйрәнү культурасының, гомумән, интеллектуаль дәрәҗәбезнең түбән булуы турында сөйли. Әгәр дә безнең туган телебез бетү дәрәҗәсенә җитмәгән булса, урта мәктәпләрне шәп итеп тәмамласак, шул ук вакытта русчаны да туган тел кебек яхшы белсәк, без бүген бу мәсьәләне көн тәртибенә кертеп тә тормас идек, сессия саен: «Безгә татар университеты кирәк!»— дип кабатламас идек. Кем белә, бәлки, ул көннәр дә килер әле. Дөньяда бит башка процесслар да бара. Төркиягә йөрүче иптәшләребез безгә, нишләптер, барысын да сөйләп бетермәскә тырышалар. Андагы җитди вузларның күбесендә төгәл фәннәр күптән инде инглиз телендә укытыла. Андый практика башка илләрдә дә җитәрлек. Болары, билгеле, киләчәк эше. Шулай да мине бер әйбер борчый: олы түрәләр, байлар, зыялылар үз балаларын бер дә татар мәктәбенә дә, вузларның татар төркемнәренә дә бирмиләр. Киресенчә, әнә шул чит илләргә җибәрергә тырышалар. Татар мәктәпләре, татар вузлары һаман да шул ярлы-ябагайлар өчен генә булып калмас микән? Шулай булмасын өчен безгә мәгарифнең авторитетын айһай нык күтәрәсе бар әле.

Мин тагын бер тапкыр вуз җитәкчеләренә мөрәҗәгать итәм. Евг. Евтушенконың мәгълүм бер шигырь юлы бар: «Поэт в России больше, чем поэт»,— ди ул. Җәмгыятебезнең бүгенге үсеш этабында югары уку йорты җитәкчеләре, әйткәнемчә, гади җитәкчеләр генә түгел, ә бәлки, акыллы сәяси эшлеклеләр дә булырга тиеш. Кемдер телиме-юкмы, барыбер бүген республиканың киләчәге ике-

теллелек белән бәйләнгән. Ул — вакытлы кампания генә түгел, ул — дәүләт сәясәтенең аерылгысыз бер компоненты. Әмма күп вузларның телләр турындагы Законга моңа кадәрге мөнәсәбәте дәүләт сәясәте белән туры килмәде. Алар Законны ныклап үтәмәделәр дә, Закон кирәкми дә димәделәр. Мондый хәйләкәр позиция, әлбәттә, озакка бара алмый. Барыбер үзгәрергә кирәк булачак. Ә инде кемдер киресен уйлый икән, икетеллелекне вузларга кертеп булмый, дип әйтә икән, Закон үтәлерлек түгел, ди икән, рәхим итеп дәлилләсен, безне ышандырсын. Иманым камил, андыйлар табылмас.

Без, билгеле, мәсьәләнең җитдилеген барыбыз да яхшы аңлыйбыз. Реаль икетеллелекнең иртәгә генә дә булмасын беләбез. Әмма без инде беренче чорны, башлангыч чорны, иң авыр чорны үттек дип уйлыйм. Үзешчәнлектән дәүләт күләмендә фикер йөртергә, эшләргә, җавап бирергә, ниһаять, үзебезнең законнарга таянып яшәргә вакыт җитте. Без озын-озак, ерак юлга чыктык. Тел Римга илтә, диләр. Кайсы тел турында сүз барадыр, белмим. Безнең татар теле әлегә Мамадышка гына илтә ала әле. Тел, туган тел безне киләчәккә илтергә тиеш!

*1997*

## ТЕЛЛӘР ТУРЫНДАГЫ ЗАКОН — ИГЪТИБАР ҮЗӘГЕНДӘ

1992 елның 8 июлендә Татарстан Республикасы Югары Советы «Татарстан Республикасы халыклары телләре турында» Закон кабул итте. Бу Законны кабул итү Татарстан Республикасы дәүләт статусы турында бөтен халык тавыш бирүен (референдумны) һәм Татарстан Республикасының Дәүләт суверенлыгы статусы турында Декларацияне гамәлгә ашыру юлында иң төп вакыйгаларның берсе булды. Әлеге Законны этаплап тормышка ашыру өчен, Дәүләт программасын әзерләү һәм кабул итү зарур иде. 1993—1994 елларда Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасы Югары Советының Мәдәният һәм милли мәсьәләләр комиссиясе белән берлектә, Татарстан Республикасы халыклары

телләрен саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт программасын әзерләү белән шөгыльләнде. Документны әзерләү барышында министрлыкларның, ведомстволарның, фәнни оешмаларның, мәдәният һәм мәгариф учреждениеләренең, нәшриятларның, массакүләм мәгълүмат чараларының, Татарстан Республикасы шәһәр һәм район хакимиятләренең, галимнәрнең, язучылар, журналистларның һәм халык депутатларының тәкъдимнәре файдаланылды.

Дәүләт программасы проекты Татарстан Республикасы Югары Советының Мәдәният һәм милли мәсьәләләр, Мәгариф, фән һәм тәрбия, Законлылык, хокук тәртибе, кеше хокуклары һәм өстенлекләр комиссияләре утырышларында каралды. 1994 елның 20 июлендә Татарстан Республикасы халыклары телләрен саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт программасы Татарстан Республикасы Югары Советы карары белән расланды.

Дәүләт Советы һәм даими комиссияләр 1992 елдан башлап Татарстан Республикасы Законын тормышка ашыруны тикшереп торалар. 1992 елның 27 октябрендә һәм 23 декабрендә Мәдәният һәм милли мәсьәләләр буенча даими комиссия утырышында «Татарстан Республикасы халыклары телләре турында» Татарстан Республикасы Законын тормышка ашыруның барышы хакында»гы мәсьәлә каралды. Даими комиссиянең карары нигезендә «Татарстан Республикасы халыклары телләре турында» Татарстан Республикасы Законын үтәү буенча беренчел гамәлләр хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карар кабул итте.

1993—1996 елларда Мәдәният һәм милли мәсьәләләр комиссиясе, Социаль мәсьәләләр һәм яшьләр эшләре комиссиясе Чаллы, Бөгелмә, Зеленодол шәһәрләрендә «Телләр турында Закон һәм Татарстан халыклары телләрен саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Дәүләт программасы турында» дигән көн тәртибе белән үз утырышларын уздырды. Читтә уздырылучы утырышларны әзерләгәндә, шәһәр һәм район хакимиятләре һәм комиссияләр закон статьяларының һәм Дәүләт программасы пунктларының оешмаларда, предприятиеләрдә, учреждениеләрдә, колхозларда һәм совхозларда

гамәлгә ашырылу тәҗрибәсен өйрәнделәр. Бу утырышларга шушы район һәм шәһәр округларыннан сайланган Татарстан Республикасы халык депутатлары, шәһәр, район һәм берләштерелгән Советлар депутатлары, мәгариф, мәдәният, сәламәтлек саклау буенча Советлар депутатлары, мәгариф, мәдәният, сәламәтлек саклау, сәүдә, транспорт, элемтә һәм халыкка хезмәт күрсәтүче башка учреждениеләр, предприятиеләр хезмәткәрләре чакырылган иде. Мәдәният һәм милли мәсьәләләр комиссиясенең Чаллы шәһәрендә уздырылган утырышының йомгаклары Татарстан Республикасы Югары Советы Президиумы утырышында да каралды.

Телләр турында Законның һәм Дәүләт программасының үтәлеше барышын өйрәнү йөзеннән, «Татарстан Республикасы китап продукциясен нәшер итүнең халәте турында» (1995 елның 22 ноябре) һәм «Электрон массакүләм мәгълүмат чараларының эше турында» (1997 елның 20 феврале) дигән темаларга парламент тыңлаулары оештырылды. «Татарстан халыклары телләре турында»гы Законны һәм Дәүләт программасын гамәлгә ашыру кысаларында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы инициативасы белән татарча терминологияне камилләштерү, унификацияләү һәм стандартлаштыру проблемалары буенча фәнни-гамәли конференция һәм «Республикам минем» темасына иң яхшы иншага республика конкурсы уздырылды. Шул ук максатларда Дәүләт Советы «Татарстан Республикасы халыклары телләре турында» Татарстан Республикасы Законының һәм Татарстан Республикасы халыклары телләрен саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Дәүләт программасының текстлары белән Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә дә брошюралар һәм «Матбугатта аеруча еш кулланылучы кайбер терминнарның, сүзләрнең һәм сүзтезмәләрнең русча-татарча сүзлеге» бастырып чыгарылды.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1996 елның 28 мартындагы сессиясендә «Татарстан Республикасы халыклары телләре турында» Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру хакында»гы мәсьәлә каралды. Сессия тиешле карар кабул итте. Әлеге карарның төп нигезләмәләре үтәлде дияргә мөмкин.

«Татарстан Республикасы халыклары телләре турында»гы

Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» (1996 елның 28 мартындагы) һәм «Татар алфавитын тәртипкә китерү турында» (1997 елның 20 гыйнварындагы) дигән законнар кабул итү дә «Татарстан Республикасы халыклары телләре турында» Законны һәм Дәүләт программасын гамәлгә ашыру эшендә мөһим бер этап булды.

Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнары, министрлыклары, ведомстволары, оешмалары һәм учреждениеләре, шәһәрләрнең һәм районнарның хакимият башлыклары тарафыннан башкарылган гамәлләр нәтиҗәсендә Татарстан Республикасы халыклары телләрен саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Дәүләт программасында каралган гамәлләрнең шактый өлеше үтәлде, озак вакытка билгеләнгән гамәлләрне башкару әле дә дәвам итә.

Шулай да Дәүләт программасының барлык дәүләт учреждениеләрендә һәм оешмаларында эшләрне ике дәүләт телендә алып баруга кагылышлы түбәндәге бүлекләрен һәм пунктларын тормышка ашыру бик акрын бара. Мәсәлән, торак пунктларының, урамнарның хакыйкый, тарихи яктан акланган исемнәрен торгызу; бүгенге көн күзлегеннән чыгып, колхозлар һәм совхозларның, предприятиеләрнең исемнәрен алмаштыру; урамнарның, торак пунктларының, юл күрсәткечләренең исемнәрен билгеләгәндә, предприятиеләрнең һәм оешмаларның, географик атамаларның исемнәрен күрсәткәндә катгый рәвештә ике дәүләт телен дә куллану; Татарстан Республикасында чыга торган барлык төр продукцияләрне дәүләт телләрендәге этикеткалар, ярлыклар, инструкцияләр белән тәэмин итү; республиканың барлык ведомстволарын, учреждениеләрен, фәнни-тикшеренү институтларын, урта мәктәпләрен, югары уку йортларын һәм зур китапханәләрен компьютерлар һәм дәүләт телләрендәге программалар белән тәэмин итү; татар теле лексикасы һәм грамматикасының генераль машина фондын төзү; әкренләп латин графикасына күчү буенча тәкъдимнәр эшләү; Татарстан Республикасы турында татарча белешмә әсбаплар, карталар, атлас, юл күрсәткечләре чыгару һәм җир шары глобусын әзерләү; «Татарстан» дәүләт телерадиокомпаниясе каналларының куәтен арттыру һәм кыска дулкынлы радио-

станцияләр төзү, татарча телеграммалар кабул итеп алу пунктларын татар шрифтлы телеграф аппаратлары белән тәэмин итү.

«Татарстан Республикасы халыклары телләре турында» Татарстан Республикасы Законын тормышка ашыру гамәлләрен оештыру барышыннан әлеге Законда аны бозган өчен җаваплылыкка тарту механизмы эшләнмәгән булуы һәм дәүләткә карамаган оешмаларның ике дәүләт телен дә куллану бурычлары җитәрлек күрсәтелмәгән булуы да ачыкланды.

«Татарстан Республикасы халыклары телләре турында» Татарстан Республикасы Законын киләчәктә камилләштерү, әлеге Законны бозган өчен җаваплылык механизмын әзерләү һәм Татарстан Республикасы халыклары телләрен саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Дәүләт программасын гамәлгә ашыруны активлаштыру максатларында «Татарстан Республикасы халыклары телләре турында»гы Татарстан Республикасы Законын бозган өчен административ җаваплылык хакында» Татарстан Республикасы Законы проектын әзерләргә һәм кабул итәргә, «1997 елга бюджет системасы турында» Татарстан Республикасы Законы нигезендә «Татарстан Республикасы халыклары телләре турында»гы Татарстан Республикасы Законын һәм Татарстан Республикасы халыклары телләрен саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Дәүләт программасын гамәлгә ашыру чараларын тотрыклы финансларга, «Татарстан Республикасы халыклары телләре турында» Татарстан Республикасы Законын һәм Татарстан Республикасы халыклары телләрен саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Дәүләт программасын гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты структурасында аерым бүлек яисә Дәүләт комитеты төзергә кирәк.

1998 елны Президент тарафыннан «Татар теле елы» дип игълан итү дә муафыйк булыр иде. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, тиешле финанс чараларын күрсәтеп, латин алфавитына нигезләнгән графикага әкренләп күчү гамәлләренең фәнни дәлилләнгән планын әзерләргә һәм расларга; хезмәт хакларына 15% өстәмә билгеләү өчен, ике дәүләт телен дә белергә һәм гамәлдә кулланырга тиешле дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнары,

шулай ук Татарстан Республикасы халык хуҗалыгы тармаклары хезмәткәрләренең һөнәрләре һәм хезмәт урыннары исемлеген әзерләүне тизләтергә тиеш.

Шушы елның 22 маенда Дәүләт Советының пленар сессиясе нәкъ менә шушы мәсьәләләрне карады. Көн тәртибендә бер генә мәсьәлә — «Татарстан Республикасы халыклары телләре турында» Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыруның барышы һәм Татарстан Республикасы халыклары телләрен саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт программасының үтәлеше хакында» иде. Халык депутатлары, нигездә, татар теленең язмышы турында борчылып, ачынып сөйләделәр, үзләренең тәкъдимнәрен, киңәшләрен әйттеләр. Аларның чыгышлары радио һәм телевидение буенча яңгырады, сессиянең эше көндәлек матбугатта да шактый тулы яктыртылды. Һәм, әйтергә кирәк, җәмәгатьчелектә киң яклау тапты.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәдәният һәм милли мәсьәләләр даими комиссиясе «Татарстан Республикасы халыклары телләре турында» Татарстан Республикасы Законының һәм Татарстан Республикасы халыклары телләрен саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Дәүләт программасының һәм әлеге мәсьәлә буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы кабул иткән карарларның үтәлешен тикшереп торуны тагын да көчәйтер дип ышанам.

*1997*

## «ПОТОМКИ СКАЖУТ НАМ СПАСИБО...»

В 1992 году в нашей республике принят Закон «О языках народов Республики Татарстан». С тех пор утекло немало воды. Еще больше лилось всевозможных речей по поводу сохранения родного языка. Но как выполняется этот закон на практике? Что делается и, главное, что еще предстоит сделать для повышения статуса родного языка? Об этом наш разговор с председателем Комиссии по культуре и национальным вопросам Государственного Совета РТ поэтом Робертом Миннуллиным.*

* Беседовал писатель Рафаэль Мустафин.

*— Роберт Мугаллимович! Прежде всего, разрешите поздравить Вас со славным полувековым юбилеем! А разговор наш, думаю, пойдет вовсе не по юбилейному руслу. Как Вам с вашей довольно высокой «кочки» на одном из высших постов законодательной власти видится Закон «О языках народов РТ»?*

— Спасибо за поздравления! Что же касается закона... Видите ли, язык, как и все в этом мире, развивается по своим естественным законам. Но для меня, как для депутата, родной язык — не просто филологическое явление. Он напрямую зависит от социальной и национальной политики. Поэтому мы вправе говорить о ЯЗЫКОВОЙ ПОЛИТИКЕ. Посредством законов, постановлений, указов можно и нужно непосредственно влиять на развитие языка, на активное применение его в жизни.

*— Но это во всем мире так...*

— Да... Но разница все-таки есть. Скажем, евреи, рассеянные по всем уголкам земного шара, не считают язык основным фактором национальной принадлежности, не абсолютизируют его. Белорусы и украинцы, несмотря на то, что живут теперь в самостоятельных государствах, и сегодня в большинстве случаев предпочитают общаться на русском, особенно в городах (я имею в виду Восточную Украину). В Индии до сих пор государственным языком является и английский... Примеры такого рода можно бы продолжить...

Но для татар языковой вопрос — это вопрос жизни и смерти. Будет жить язык — будет на планете Земля и мой народ. Умрет язык — и народ исчезнет. Именно так. Третьего не дано.

*— Когда-то представителям татарской научной и творческой интеллигенции казалось, что статус языка полностью зависит от одного закона. Достаточно, мол, объявить татарский язык одним из государственных, и все будет хорошо, по-детски наивно верили мы. Но вот такой закон принят. С этого момента прошло уже шесть лет. А что изменилось? По-прежнему гордо заявляем, что татарский язык входит в число 14 великих языков мира, что, зная его, можно свободно общаться со всеми тюркоязычными народами планеты. А на деле... Даже в семье предпочитаем разговаривать на русском...*

*Кстати, откуда пошло это утверждение? Ссылаются на какие-то исследования ООН. Но я лично их не встречал...*

— Действительно ли наш язык входит в число 14 великих языков мира? Да, об этом часто твердят наши ученые-лингвисты, но и я не помню, чтобы где-либо указывали источник. Конечно, хотелось бы верить в это.

Как бы там ни было, я твердо верю в одно: язык — зеркало души народа. Каков дух народа, таков и его язык. А положение нашего народа пока что незавидное. Вернее, в его судьбе все перепутано: хорошее и плохое, величие и слабость. Сколько бы мы ни спорили, как бы ни старались найти виновников извне, судьбу татарского языка, а значит, и судьбу нашего народа решать нам самим.

Этого не добиться одними жалобами, стенаниями и руганью. Кричать на всех перекрестках: «Язык умирает, татары исчезают!» — мало чести. Да и просто не к лицу интеллигентному человеку. Если уж мы такие смелые, надо было кричать об этом лет 25—30 тому назад. А сейчас остается один-единственный путь: заниматься делом. Если каждый, считающий себя татарином, сохранит язык в своем сердце, в семье, передаст его детям, будет пользоваться им и на рабочем месте, язык будет жить...

— *Но вернемся к Закону о языках... Насколько он согласуется с мировой практикой?*

— Интересное совпадение: в 1992 году, то есть как раз тогда, когда мы приняли свой Закон о языках, была принята «Европейская хартия о региональных языках и языках малых народов». Многие положения этой хартии прекрасно согласуются, а иногда и совпадают с нашим, а также российским законами о языках. Так что в смысле легитимности законов — все в порядке.

На основании этого закона нашим парламентом принята Государственная программа по выполнению Закона о языках. На ее основе позднее разработана и утверждена мэрией Казани своя городская программа претворения этого закона в жизнь. Помнится, во время обсуждения этой программы вы писали, что она получилась более конкретной, более продуманной и реаль-

ной, чем республиканская программа. И тут я полностью с вами согласен.

Короче, за законодателями дело не стало. Есть закон, есть программа. Надо только претворять их в жизнь. Это уже не дело парламента.

— *Вы хотите сказать, что в законодательном плане сделано все для сохранения и развития языков народов Татарстана?*

— Нет, конечно. Пока что заложены лишь законодательные основы языковой политики. Что еще предстоит сделать? Во-первых, нужен специальный республиканский орган государственной власти по исполнению Закона «О языках народов Республики Татарстан» и Государственной программы по сохранению, изучению и развитию языков народов РТ. Понимаю, что поднимать вопрос о создании нового государственного органа в то время, когда идет тотальное сокращение штатов государственного аппарата, может показаться безумной затеей. Но ведь кому-то надо этим заниматься постоянно, изо дня в день. А если выполнять эту работу на общественных началах, далеко не уедешь...

Во-вторых, как можно скорее надо подготовить и принять законопроект «Об административной ответственности за нарушение Закона „О языках народов РТ"». Вот, скажем, уже после принятия Закона о языках открыт парк Победы. Дело доброе! Но почему надпись у входа — крупными золотыми буквами — только на одном, на русском языке?

А главное, почему никто не понес за это никакого наказания? Вот если бы администратор любого уровня заранее знал, что так легко ему не отделаться, что нарушение закона грозит крупным штрафом, выговором, снятием с работы, а то и уголовной ответственностью, он бы десять раз подумал, прежде чем нарушать закон...

Полагаю, что парламенту надо объявить ближайший год, может, 1999-й, может, 2000-й, Годом татарского языка. Почему только год? Надо заниматься этим всегда? Согласен. Но, как известно, труднее всего сдвинуть воз с места. Год татарского языка как раз и нужен для того, чтобы сдвинуть этот нелегкий воз... А там пойдет легче, само покатится...

*— И тогда никто не сможет сказать, как сейчас нередко повторяют: а воз и ныне там...*

— Да... Но и это еще не все. Принято решение о финансировании этой программы. Но пока что не всегда хорошо с целенаправленным выделением денег... Действует прежний «остаточный принцип». В программе есть статья о 15-процентной надбавке за знание и применение двух государственных языков. Но не выработан четкий перечень профессий и отраслей, дающих право на эту надбавку. Сами понимаете, в этом деле не должно быть никакого ущемления прав других народов. И в то же время знание языков, если это и в самом деле необходимо по характеру труда или профессии, надо поощрять.

*— Приближается 30 августа — День республики. Как, по-вашему, произошли ли за последние годы какие-то принципиальные изменения в статусе татарского языка и других языков народов РТ?*

— Безусловно! Законы и программы не просто приняты, они заработали... Конечно, проблемы остаются. Но они будут всегда — таков закон жизни. Главное — не опускать руки, а работать, действовать. И тогда — я уверен — потомки скажут нам спасибо за то, что мы не сидели сложа руки, а сделали все, чтобы сохранить бесценное богатство народа, его живую душу.

*1998*

## ТЕЛЕ БАРНЫҢ — ИЛЕ БАР

*— Роберт әфәнде, сезнең комиссия күчмә утырышларны еш үткәрә. Әле күптән түгел генә сез күчмә утырышны Минзәлә районында уздырдыгыз. Күчмә утырышлар уздыру комиссиягә нәрсә бирә?**

— Мин үзебезнең тәҗрибәдән чыгып шуны әйтә алам: күчмә утырышлар алар бермә-бер нәтиҗәлерәк. Депутатлар тикшерелә торган мәсьәлә белән урында ныклап танышалар, һәрнәрсәне үз күзләре белән күрәләр. Татар тотып карамый ышанмый, диләр бит.

---

* Әңгәмәдәш — журналист Әгъзам Фәйзрахманов.

Икенчедән, әзерлек мәсьәләсе. Әйтик, район яки шәһәр ярты ел дәвамында депутатларны кабул итү өчен әзерлек алып бара. Шул вакыт эчендә барысы да тәртипкә китерелә. Моңарчы кул җитмәгән байтак эшләр башкарыла. Планнар, эш кәгазьләре тиешле тәртипкә салына. Без көн тәртибенә керткән мәсьәлә буенча ул районда, гадәттә, ныклап әзерләнәләр.

Шулай итеп, күчмә утырышлар район һәм шәһәрләрне бераз эшләтү максатын да куя. Бигрәк тә «Татарстан Республикасы халыклары телләре турында»гы Законның үтәлеше авыр барган районнарда, шәһәрләрдә. Зеленодолга, Чаллыга бардык. Аннары Бөгелмә, Алабуга шәһәрләрендә, Спас, Питрәч районнарында булдык. Ә менә Актанышка барып, татар телен ничек өйрәнүләрен тикшереп йөрүнең кирәге юк бит инде. Киресенчә, анда рус телен өйрәнүнең торышы белән танышу отышлырак булыр.

— *Ә шулай да Минзәләдә булдыгыз...*

— Без Минзәләне беренче карашка гына татар районы дип исәплибез. Баксаң, Минзәлә — яртылаш диярлек рус районы. Чуваш, мари авыллары да бар. Кызыксына торгач, Минзәлә интернациональ район булып чыкты. Элек-электән биредә руслар үзләренең диннәрен дә, гореф-гадәтләрен дә нык саклаганнар. Чиркәүләр бер вакытта да эшләүдән туктамаган, ябылмаган.

— *Сезнең күзлектән караганда, комиссиянең Минзәләгә барып күчмә утырыш үткәрүе үзен акладымы?*

— Аклады, дип уйлыйм. Чөнки, ничек кенә булса да, проблемалар әле барыбер бар иде. Бездә барысы да яхшы, телне өйрәнәсе юк, дип, эш кайвакытта үз агымына да куела. Шуңа күрә без параллель рәвештә көн тәртибенә кертелгән икенче мәсьәләне дә карадык — халык депутатларының Минзәлә берләштерелгән Советының хокук саклау, милли һәм социаль-мәдәни мәсьәләләр комиссиясенең эш тәҗрибәсе белән таныштык. Аның эш кәгазьләрен, планнарын карап чыктык, үзебезнең киңәшләребезне бирдек.

Кызганыч ки, моңарчы Минзәлә районында «Татарстан Республикасы халыклары телләре турында»гы Законны гамәлгә

ашыру өчен комитет та соңгы вакытта гына төзелгән булган. Һәрхәлдә, безнең комиссиянең Минзәләгә баруы нәтиҗәле булды, дип исәплим. Чөнки мәдәниятнең торышы турында уңай яктан да, тискәре яктан да бик күп сүзләр ишеттек. Мәсәлән, район газетасы мөхәрриренең сүзләре әле дә хәтеремдә. Ул әлеге төбәктә Татарстан радиосының тәүлеккә берничә генә сәгать эшләвенә канәгатьсезлек белдерде. Башкортстан радиосы исә иртәнге җидедән төнге уникегә кадәр эшли икән. Шуның 5—6 сәгате татар телендәге программа. Башкортстан радиосы яшәгәндә, Минзәлә татарлары үлмәячәк, дип шаяртты ул. Үзебезнең республика өчен безгә бик уңайсыз булып куйды.

Минзәлә халкы шигъри җанлы, җыр яратучан. Без аларның концертларын да карадык. Аларның концертлары очсыз эстрада программаларыннан аерыла иде, фәкать моңга корылган, күпчелеге — халык җырлары. Минзәләдә хәзер яңа хакимият башлыгы — Николай Михайлович Владимиров. Ул шәһәрне эчтән дә, тыштан да караган, тәртипкә китергән. Без килгәндә, районда өч концерт төркеме эшли иде. Китапханәләрдә булдык, татар гимназиясендә. Һәрхәлдә, безнең депутатлар Минзәләдән канәгать кайттылар.

— *Роберт әфәнде, сез халык депутатларының Минзәлә берләштерелгән Советының хокук саклау, милли һәм социаль-мәдәни мәсьәләләр комиссиясенең эш тәҗрибәсе белән таныштык, дидегез. Биредә башка районнарда кулланырлык нинди тәҗрибә бар?*

— Карар проектында комиссиянең эш тәҗрибәсен башка районнарга да күчерергә диелгән иде. Ләкин комиссиянең эш нәтиҗәләре белән танышкач, безнең депутатлар ул пунктны төшереп калдырырга тәкъдим иттеләр. Минзәлә халкы эшли, әйбәт эшли. Башка районнар да тик ятмый, аларның да эш нәтиҗәләре күренә.

— *Мин хакимият башлыгы Николай Владимировның сезнең комиссиянең күчмә утырышында ясаган докладлары белән танышып чыктым. Анда кайбер бик гадәти нәрсәләр дә зур казаныш итеп күрсәтелә кебек. Мәсәлән, хакимият башлыгы: «Телләр турындагы Закон кабул*

*ителгәннән соң, татар балаларын үз телләрендә укыту 47 дән 55,6 процентка тикле артты», — ди. Бик аз түгелме соң бу? Мондый темп белән барсак, татар баласы Минзәләдә һаман да русча укыячак бит.*

— Бу санга безнең депутатлар да игътибар итте. Татар балаларының туган телләрендә уку күрсәткечләре бик акрын үсә. Моны инде алар ата-аналарның мөнәсәбәте белән бәйлиләр, әлбәттә. Моның өчен без минзәләлеләрне тәнкыйть иттек. Хәзергә саннар, нигездә, авыл мәктәпләре исәбенә арткан. Шуңа күрә үзләре дә аңладылар, монда эш күп әле. Алар ныклабрак эшләргә булдылар.

*— Мин тагын бер фактка игътибар иттем: районда татар теле һәм әдәбиятын укытучы 90 кешенең 36 сы махсус югары белемле, 5 се читтән торып укый. Минзәлә районы укытучыларының яртысыннан артыгының тиешле белеме юк булып чыга бит. Минзәлә районында очраклы кешеләр дә укытып йөрми микән дигән шик туа. Андый белгечләр балаларга тиешле белем бирә дә алмыйлар.*

— Фактлардан беркая китә алмыйсың. Саннар шуны раслый. Ләкин мәсьәләнең икенче ягын да онытмаска кирәк. Минзәләләдә бик зур тарихы, абруе булган педагогика көллияте бар. Аны тәмамлаучылар югары белемлеләрдән ким түгел. Бәлки, укытучыларның күпчелеге шушы көллиятне тәмамлаучылардыр.

*— Мин тагын бер нәрсәгә игътибар иттем: Минзәлә — күпмилләтле район. Аның татары, русы, чувашы, марие бар. Әлбәттә, татар телен дәүләт теленә әверелдерү өчен күп эшлисе бар әле. Законда барлык халыкларның мәдәниятен, гореф-гадәтләрен, тел мәсьәләләрен кайгырту зарурлыгы белдерелә. Минзәләдә башка милләтләр мәнфәгатен кайгырту сизеләме?*

— Теләгән балаларның барысы да ана телләрендә белем ала. Чувашлар, марилар да дәреслекләр белән тәэмин ителгәннәр. Руслар турында әйтеп тә тормыйм инде. Шулай да башка милләт вәкилләренең руслар ягына тартылуы нык сизелә. Аларны инде кайчакта үз ана телләрендә укырга мәҗбүр итәргә туры киләдер.

Безнең белән Минзәләгә Спас районы хакимияте башлыгы Камил Нугаев та барды. Ул да безнең даими комиссия әгъзасы. Нугаев кызыклы мисал китерде. Спас районында да шундый ук

проблема бар икән. «Бездә дә чуваш авылы бар. Җыелыш саен мин аларга, башлангыч булса да, чуваш мәктәбе ачарга тәкъдим итәм, ә алар, безгә болай да рәхәт, дип җавап кайтаралар», — дип сөйләде ул. Без әйттек инде, хәер, аны Нугаев үзе дә белә, бу очракта ата-аналар рөхсәтен сорап та тормаска мөмкин. Чувашларның үз республикаларында да проблемалары күп. Алар башлангыч сыйныфларда гына чувашча укыйлар.

*— Әлбәттә, укыту өчен дәреслекләр, методик кулланмалар кирәк. Мин монда чуваш, мари, мордва мәктәпләрен күздә тотам. Милли республикалар арасында бу юнәлештә бәйләнешләр бармы?*

— Мәгариф министрлыгы һәм укытучыларның белемен күтәрү институты аша бәйләнешләр бар. Мин министр Ф. Харисов белән сөйләштем, ул Мәгариф министрлыгында чуваш мәктәпләре өчен бер инспектор булдырырга вәгъдә бирде. Элек бит Ульянов булган. Мари, мордва мәктәпләре буенча да кирәк. Удмурт мәктәпләре буенча да. Министр, аларын быел ел дәвамында эшләргә тырышырбыз, диде. Әгәр башка республикалар белән бер кеше махсус шөгыльләнсә, эш нәтиҗәлерәк булачак.

*— Комиссия утырышында тәнкыйть фикерләре дә әйтелгәндер, мактап кына утырып булмый бит инде. Министрлыкларга, республика оешмаларына нинди тәкъдимнәр булды?*

— Утырышта комиссия тарафыннан алдан әзерләнгән карар проекты каралды. Фикер алышу барышында тәкъдимнәр күп булды. Депутатлар утырышка чакырылган башка кешеләргә, Мәгариф һәм Мәдәният министрлыкларына һәм, әлбәттә инде, Дәүләт Советына тәкъдимнәр ясадылар. Мәсәлән, «Татарстан Республикасы халыклары телләре турында»гы Законны финанслауны бюджетка аерым юл итеп кертеп, аның үтәлешен мәҗбүри куярга дигән тәкъдим бар. Чөнки беренче ярты елда Законны финанслау бары 12 процентка гына башкарылды. Бу — 6 миллиард сумның бары 12 проценты. Шуңа күрә без гарантияле финанслау мәсьәләсен комиссиянең карарына кертеп куйдык.

*— «Татарстан Республикасы халыклары телләре турында»гы Законны үтәү буенча сез Минзәлә районында иң төп кимчелек дип*

*нәрсәне саныйсыз? Минзәләдәге кимчелекләр башка районнарга да хасмы?*

— Кимчелекләр күпчелек районнарда бер чама инде алар. Мәсәлән, Минзәләдә әлегә кадәр урам исемнәре бары рус телендә генә язылган. Без бу хакта җае чыкканда да сөйлибез, җае чыкмаганда да. Моның өчен махсус карар да кабул итеп торасы юк, чыгымнар да әллә ни зур түгел. Бары тик башкаларны тәнкыйтьләгәндә бездә дә шулай түгелме икән дип, үзеңне кат-кат тикшереп тору зарур. Эшне күренеп торган әйберләрдән башларга кирәк. Без урам исемнәре турында минзәләлеләргә тәнкыйть буларак әйттек. Аннары эш кәгазьләрен ике телдә алып баруны мәҗбүри куярга кирәк, бигрәк тә Минзәлә кебек районнарда. Әйткәнемчә, һәрбер районда, хакимият каршындамы ул, Советлардамы, Законны гамәлгә ашыру буенча комиссия булырга тиеш. Аны хакимият башлыгы яки аның урынбасары җитәкләсен. Барлык эш шушы комиссиягә тапшырыла, ул инде планлы төстә барысын да үтәргә тиеш. План буенча эшләгәндә, аз-азлап кына булса да, алга барыла. Бу хакта да без минзәләлеләргә әйтми булдыра алмадык.

— *Мөгаен, декабрьдә сайлаулар булыр, заман шуңа бара кебек. Законны тормышка ашыру буенча декабрьгә кадәр комиссиянең эш планында нинди чаралар карала?*

— Планнар бар. Бүгенге көндә безнең комиссия, белгечләр белән берлектә, ике закон эшли. Топонимика буенча. Урамнарга кешеләр исемнәрен бирү буенча административ җаваплылык турында. Икенчесе — географик атамалар хакында. Аларның проектлары экспертизага җибәрелде инде. Тиздән алар комиссиягә әйләнеп кайтырга тиеш. Әлбәттә, бу проектларны тикшерү бик бәхәсле булачак. Без бу законнарны кабул итә алмадык инде, аны алдагы чакырылыш төгәлләр. Башкортлар инде, авыл исемнәрен үзгәртмичә, тәрҗемәсез язып куя башладылар. Бездә дә шундый тәртип булырга тиеш. Әлеге адымны мактарга гына кирәк. Мондый чаралар, әлбәттә, Россия законнары, Конституциясе белән бәйләнгән. Ләкин әле безнең үзебезнең дә хокукларыбыз бар. Алардан да тиешенчә файдаланырга була.

Бу чакырылыш Дәүләт Советының вәкаләтләре тәгәлләнгәнче «Латин графикасына нигезләнгән татар алфавитын кайтару турында»гы Законны тулысынча кабул итәсе иде. Соңгы пленар сессиядә без аны икенче укылышта карадык. Минзәләдә үткәрелгән күчмә утырышта шундый карарга килгән идек.

«Вөҗдан иреге һәм дини берләшмәләр турында»гы Законны да мөмкин кадәр тизрәк эшләп бетерергә тырыштык. Чөнки республиканың дини оешмаларына бәйле вазгыять бик нык үзгәрә. Гаугалы, ызгыш-талашлы хәлләр дә килеп чыга тора. Гомумән, бөтен мөселман республикаларында да дин әһелләренең нииндидер бер зур көчкә әйләнеп китүе мөмкин. Законны икенче укылышка караганда берничә пунктны уздырып булмаган иде. Өченче укылышка аларны яхшылап әзерләдек. «Вөҗдан иреге һәм дини берләшмәләр турында»гы Закон күптән түгел сессиядә кабул ителде. Президентның аңа кул куеп, Законның тиздән гамәлгә керүенә өметләнәбез. Менә шушы эшләр тәгәлләнгәч, комиссия үз бурычын башкарып чыккан дип санарга булыр.

— *Дин дәүләттән аерылган булса да, без барыбыз бергә, бер җәмгыятьтә яшибез. Минемчә, тәрбия чарасы буларак, хәзергә диннең җәмгыятькә йогынтысы һич тә җитәрлек түгел кебек.*

— Бу аңлашыла да. Дин әһелләренең моңарчы тәрбия өлкәсендә тәҗрибәләре азрак иде. Хәзерге муллаларның күбесен өйрәнчек дияргә була, яңа гына оештырылган мәдрәсәләрне тәмамлаучылар, үзлегеннән белем алучылар да бар. Белемнәре җитәрлек түгел, шунлыктан, тәрбия эшен начар үткәрәсез, дип, аларны да гаепләп булмый.

Араларында бик гыйлемле егетләр дә бар. Алар нык аерылып торалар, вәгазьләре дә икенче. Ләкин вәгазьләрен тыңлаганда бер әйбергә игътибар итәсең, дин әһелләре күбрәк динне пропагандалау белән шөгыльләнәләр. Кешенең күңеленә сеңдерү өчен, моныcы да кирәктер инде, ләкин кешеләрне төрле бозыклыкларга барудан арындырасы иде. Дин дәүләттән аерылган, дибез. Аерылган, билгеле. Ләкин бер җәмгыятьтә яшәгәч, аннан беркая да китеп булмый. Алар үзләре дә дөньяви эшләрдә турыдан-туры катна-

шырга исәплиләр. Шуңа күрә безгә дин эшләре буенча комитетмы, башкамы, кыскасы, зур бер оешма кирәк булачак. Мин бу хакта Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин белән дә сөйләштем. Бүген дин инде зур көчкә әверелде. Татарстан — ике дини конфессияле республика. Башка диннәр дә бездә тамыр җибәрергә ниятлиләр. Аларның һәрберсе белән ныклап эшләргә кирәк. Без шундый тәкъдим керттек.

*1999*

## БЕР-БЕРЕБЕЗДӘН ТЕЛ ЯШЕРМИК!

Башкортстандагы телләр вазгыяте турында кайбер фикерләрем белән уртаклашмакчы булам. Әлбәттә, күңелемдәгенең барысын да әйтеп тә бетерә алмам. Чөнки ул уйларымның очына үземнең дә чыга алганым юк әле. Аннары хакыйкатьнең асылына төшенеп тә җителмәгән. Мин шуны гына беләм: тел белән шаярырга ярамый. Дөньядагы халыкара, милләтара катаклизмнарның күбесе нәкъ менә шул тел аркасында килеп туганын беләбез. Тел — олы сәясәт ул. Шуңа күрә дә бу мәсьәләне аек акыл, салкын баш белән хәл итәргә кирәк.

Татарның акылы төштән соң, дибез. Бу хакта Нәҗар ага Нәҗминең бер шигыре дә бар. «Татар акылы төштән соң, кайчан төш җитәр икән?» — ди ул. Күрәсез, төшебез һаман да җитмәгән әле. Башкортстандагы телләр мәсьәләсе бер бүген генә килеп туган хәл түгел бит. Бер карасаң, анда хәлләр, чыннан да, катлаулы. Икенче карасаң, гап-гади генә ул. Мәсьәләнең катлаулылыгы да әнә шул гадилектән — ике тугандаш телнең үтә дә якынлыгыннан, охшашлыгыннан килеп чыга. Әгәр дә бу ике тел бер-берсенә бөтенләй аңлашылмаса, бу ике халык бер-берсенең телләрен бөтенләй белмәсә, бер-берсенең җырларын җырламаса, белмим, бу хәл килеп чыгар идеме икән? Мөгаен, килеп чыкмас иде. Һәркайсы үз дөньясы белән яшәр иде, бүлешәсе телләре дә, моңнары да булмас иде... Бөтен ямьсезлекләр әйбер, мал бүлешкәндә килеп чыга бит. Бер гаиләдә генә түгел, халыклар, илләр арасында да. Уртаклыкның, яхшы яклары белән бергә, уңайсызлыклары да була икән шул.

Башкаларны өйрәтү җиңел ул. Үзеңә килеп терәлсә генә авырга туры килә. Шул ук икетеллелекне алыйк. Үзебезнең Татарстанда әле һаман да шул икетеллелекне тормышка ашыра алганыбыз юк. Тырышабыз, тырмашабыз, нидер эшләгән булабыз. Ә нәтиҗә юк дәрәҗәсендә. Чөнки сукырлар шикелле капшанып кына барабыз. Татарстанда икетеллелекнең киләчәге нинди булыр? Беркем дә әйтә алмый. Чөнки теоретик яктан, фәнни яктан бу мәсьәләне ныклап өйрәнгәнебез юк. Бер генә кандидатлык яисә докторлык диссертациясе дә якланмаган. Социологик эзләнүләребез дә күренми. Гомумән, телләрнең яшәү рәвешен, үсешен, үзара мөнәсәбәтләрен, үзара сыешып яши алу мөмкинлекләрен өйрәнү белән беркем дә шөгыльләнми. Мәсьәлә күтәргәндә дә без фактларны күктән генә алып сөйләшергә яратабыз. Финляндиядә — өч тел, Швециядә ике тел дәүләт теле икән, дибез. Ләкин кайсыбыз барып өйрәнгән андагы вазгыятьне? Чыннан да, бу мәсьәлә ул илләрдә тулысы белән хәл ителгәнме? Ишетеп белүебезчә, анда да билингвизм проблемасы кискен тора. Квебек, дибез. Менә 35 ел инде анда француз телен дәүләт теле итәргә ниятлиләр, төрле законнар, карарлар кабул итәләр. Ә проблемалар һаман чишелеп бетмәгән. Гәрчә француз теле дә, инглиз теле дә — бөек телләр. Һәркайсының Франция, Англия, АКШ кебек арка терәр илләре бар. Тик алар да оригиналь бер рецепт таба алмый интегәләр.

Башкортстанда исә сүз өчтеллелек турында бара. Шуңа күрә андагы хәлләр катлаулы гына түгел, ә бик тә четерекле. Биредә җавапларга караганда сораулар күбрәк. Әмма ни генә булса да, Башкортстанда башкорт теленә өстенлек зуррак булырга тиеш. Шуңа күрә «башкорт теленә дәүләт теле статусы биргәннәр, татарга бирмәгәннәр» диюне мин берьяклырак фикер йөртү дияр идем. Без үзебез дә бит «татар теле фәкать Татарстанда гына ныклап үсеш ала ала» дибез. Башкорт теле белән дә шул ук хәл түгелме соң? Әлбәттә, шулай. Һәм ул Башкортстанда дәүләт теле булырга тиеш. Моның белән бәхәсләшүче дә юктыр. Хәер, ул инде бүгенге көндә дә, рәсми рәвештә законлаштырылмаган булса да, рус теле белән беррәттән, дәүләт теле буларак файдаланыла. Аннары шунысын да онытмыйк: башкорт теле татар теленә караганда да

ярдәмгә ныграк мохтаҗ. Аның тарихы, яшәеше, үсеше башкарак. Ул әдәби тел буларак соңрак формалашкан...

Шулай да ни өчен Башкортстанда татар теленә дәүләт теле бирәселәре килми соң? Моның бит сәбәпләре булырга тиеш. Ул сәбәпләр, әлбәттә, бар. Һәм берәү генә дә түгел. Иң киң таралган карашларның берсе — башкорт телен татар теле йотып бетерер дип курку. Моның белән күпмедер дәрәҗәдә килешми дә мөмкин түгел. Татар теленең тәэсире һәрвакыт көчле булган. Ул инде бик элекке заманнардан ук килә... Кыскасы, аларның үз кайгылары, үз проблемалары. Ләкин күпме генә парадокс булып яңгырамасын, бүген башкорт телен фәкать татар теле ярдәмендә генә үстереп, саклап калып буладыр. Һәм, әлбәттә, киресенчә: башкорт теленең аякка басуы, үсеше, чын мәгънәсендә дәүләт теле булып күтәрелүе татар теленә дә уңай йогынты ясаячак. Күрәсез, монда үзара бәйләнеш шулкадәр көчле, бу ике телне бер-берсеннән аерып карау һич тә мөмкин эш түгел. Әгәр дә Башкортстанда татар теленә кимсетүле мөнәсәбәт булса, башкорт теленең үсешенә дә ул кире йогынтыга әвереләчәк. Шушы факторны гына искә алганда да татар теленең статусын барыбер хәл итәргә туры килер иде. Һәм ул иң акыллы, алдан күрүчән бер адым булыр иде. Әгәр дә инде татар теленә бернинди дә статус бирелмәсә, татар теленең сакланышына, үсешенә бернинди дә гарантия булмый, республика тормышында татар теленең роле бөтенләй юкка чыга дигән сүз. Бернинди дә дәүләт статусы булмаган очракта татар теле, әлбәттә, үсештән туктаячак, кулланылыш сфералары тараячак. Иң элек татар мәктәпләре зыян күрәчәк. Аларда инде болай да күп предметлар русча укытыла. Ул процесс тагын да көчәячәк. Башкортстан татарларын руслаштыру башкортның үзе өчен дә файдага булмаячак. Мәктәпләр акрынлап русчага күчеп бетсә, газета-журнал укучылары калмаса, редакцияләр дә үзеннән-үзе ябылырга мөмкин. Булмас димәгез, булды инде тарихыбызда андый хәлләр. Без инде болай да күпме кысылулар, кимсетелүләр күргән халык, безне болай да инде өлкән абзый кешегә санамады. Әгәр дә бер-беребезне дә кимсетә башласак, ахыры хәерле булмаячак. Элек тә, бүген дә татар белән башкорт бер-берсенә таяныч, терәк булды. Моннан соң да шулай булсын иде, дим.

Моның өчен нишләргә соң? Иң элек ике арадагы дистә еллар дәвамында килгән кайбер проблемаларны, каршылыкларны кичекмәстән чишәргә кирәк. Алар — тарихи, этнографик, лингвистик проблемалар. Башкортстанның төньяк-көнбатыш өлешендә яшәүчеләрнең милләтенә кагылышлы мәсьәләләр, андагы татар-башкортларның телләренә мөнәсәбәтле каршылыклар, Башкортстан татарларының тарихы... Казаннан чыкмыйча гына «бу — татар теленең Минзәлә сөйләше, болар — татарлар» яисә Уфадан торып кына «болар — башкорт теленең диалекты» дип кенә катлаулы бу мәсьәләне хәл итеп булмас. Башкортстандагы хәлләр миңа бик тә таныш. Илеш мисалыннан да кайбер фактлар китерә алам. Анда бөтен кеше дә татарча сөйләшә. Билгеле инде, Казан татарлары кебек «белмим, килмим» дип түгел, ә «белмәем, килмәем» дип әйтәләр. Бер Илеш кенә түгел, Актаныш та, Минзәлә дә шулай сөйләшә. Дөресрәге, сүләшә. Алайга китсә, мишәрләр дә «сүләшә» дип сүли. Районда татарча газета чыга. «Кызыл таң»ны, «Өмет»не укый. Казан матбугатын да алдыра. Шуңа да карамастан Илешнең яртысыннан күбрәге «башкорт» язылган. Бер гаиләдә башкорты да, татары да җитәрлек. Бик күп авылларда мишәр ягы, типтәр очы, башкорт ягы, татар урамы дигән атамалар әлегә кадәр сакланган. Татарлармы соң алар, татарлашкан башкортлармы, типтәрләрме, мишәрләрме? Барысы да буталып, укмашып, берләшеп, бүгенге Илеш кешесе булып формалашып беткән... Бу инде — тарихи бер күренеш, сирәк очрый торган феномен. Мин генә төзәтә ала торган әйбер түгел. Биредә шулай ук галимнәр дә уртак бер фикергә килергә тиешләр. Югыйсә һәрберебезнең кулында тарихи чыганаклар, документлар, кулъязмалар... Аларны һәрберебез үзенчә укый, үзенчә аңлатма бирә, үзенчә нәтиҗә чыгара. Кичекмәстән бер өстәл янына утырырга кирәк, уртак тел табарга кирәк. Бер-беребездән тел яшереп яшәмик, бер-беребез белән качышлы уйнамыйк, дөнья гел шулай үз көенә барыр әле дип тә өметләнмик. Аның барыбер очы бер чыгарга мөмкин. Иң мөһиме, киләчәк буынга үзебезнең проблемаларны калдырмасак яхшы булыр иде.

Башкорт белән татарны «игезәкләр» дибез. Бу чыннан да шу-

лай. Игезәкләр турында кайдадыр укыганым бар иде. Ике игезәк туган үскәннәр. Үсеп җиткәч, бер-берсеннән бик еракта яши башлаганнар. Көннәрдән бер көнне игезәкләрнең берсе көтмәгәндә генә үлеп китә. Һәм, ни гаҗәп, икенчесе дә, әле туганының үлгәнен ишеткәнче үк, икенче көнне үк вафат була. Игезәкләрне нинди тылсымлы җепләр бәйлидер, белмим. Әмма безне дә, татар белән башкортны да, ниндидер илаһи бер көч берләштереп тора. Шулай булгач, безгә бер-беребезнең кадерен белеп, бер-беребезне саклап, яклап яшәргә кирәк. Ә бу бер дә җиңел түгел: кайчакларда бер-береңә юл да куя белергә, иң мөһиме, киләчәкне уйлап эш итәргә, бер-беребезгә «өлкән абзый» булырга тырышмыйча яшәргә кирәк. Андый мисалларны күп кичердек бит инде. Киләчәктә дә безнең кебек халыкларга җиңел булмаячак. Суверенлык алу белән генә түгел әле ул. Россиядә иртәгә ниләр буласын беребез дә белми.

Ә инде Башкортстанда татар теленә статус, һичшиксез, бирелер, дип уйлыйм мин. Законның беренче укылышында татар теленең булмавы ул, бәлки, сәяси бер «ход» кынадыр. Кемнәрнедер тынычландыру өчендер, андагы татарларның үзләрен сынап карау өчендер, җәмәгатьчелекнең фикерен ачыклау өчендер... Закон кабул итүнең нюанслары, хәйләләре күп бит аның. Беренче укылыштан соң күп законнар танымаслык хәлгә килә. Бу юлы да шулай булыр дип ышанам.

*1999*

## ЛАТИНГА КҮЧҮДӘН РОССИЯ ИМИНЛЕГЕНӘ КУРКЫНЫЧ ЯНЫЙМЫ?

*— Роберт Мөгаллимович, Татарстанның латинга күчүе хакында Россия матбугатының шулхәтле шау-шу күтәрүе төбендә, Сезнең карашка, нәрсәләр ята?**

— Латинга күчү мәсьәләсендә Россия матбугатында шау-шу бара икән, димәк, без дөрес юлдан барабыз, дип әйтер идем. Икенчедән, Россия хакимиятендәге үзгәрешләрне, законнарны

* Әңгәмәдәш — журналист Заһир Хәсәнов.

тәңгәлләштерү һәм законнар диктатурасы кебек мәсьәләләрнең бөтенесен бергә җыеп карагач, бер нәрсә күзгә ташлана: батырлар күбәя, Татарстанны тезләндермәкче булалар. Ә латин графикасына күчү — моның өчен бик шәп сәбәп булып тора. Кызганычка каршы, бер Россия матбугатында гына түгел, үзебезнекендә дә шуңа охшашлы шау-шу күтәрергә омтылышлар бар. Ә аларның авторлары бүгенге вазгыятьне яхшы аңлыйлар, андыйларның сиземләү сәләте көчле һәм алар үзләренә сәяси капитал туплауны төп максат итеп куялар. Мәзәктә дә бит, үләргә җыенган арысланга куян да тибеп китә. Мин моны, проблема юк җирдә шау-шу кузгату, дип уйлыйм. Беренчедән, латин имласына күчү — Татарстанның һәм татар халкының рухи үсеше ул. Әгәр без шуны телибез, шуны үзебезгә максат итеп куйганбыз икән — монда башкаларның катнашы булмаска тиеш. Аның уңай ягы булса да, авырлыгы булса да, ул үзебез күтәрәсе әйбер һәм без аны үзебез теләп алдык. Россия матбугаты татар халкын кызганып, җәлләп: «Аларга бик авыр булачак бу, нишләрләр инде, бу проблеманы ничек итеп ерып чыга алырлар икән», — дип борчылмый. Алар үзләре өчен ныграк борчылалар. Латин графикасына килгәндә исә, бу закон шактый күптән кабул ителде һәм Президент та аңа кул куйды. Закон эшләргә тиеш. Дәүләт структурасы да, барлык структуралар да законны үтәргә бурычлы. Әгәр ул кемгәдер ошамый икән, аның законны үтисе килми икән — андый кеше эшләмәсен, рәхим итеп урынын башкаларга калдырып китсен.

Латин графикасына күчүне мин табигый бер зарурлык дип исәплим. Соңгы ун елда зур бәхәсләр нәтиҗәсендә шундый уртак фикергә килгәнбез икән, бу юкка түгел. Бу — бер иҗат интеллигенциясе һәм галимнәр күтәргән мәсьәлә генә дә түгел. Бу — бөтен халык фикере. Әгәр латинга күчеп, эшләребез уңай барса, иманым камил, аны башкалар да күтәреп алачак. Россия үзе дә егерме-илле елдан, бөтен дөнья цивилизациясенә кушыласы килсә, латин графикасына күчәчәк.

Монда уңай яклар белән беррәттән, әлбәттә, авырлары да булыр. Бер генә реформа да җиңел генә узмый. Минем үземне (һәм башкаларны да) Татарстаннан читтә яшәүче милләттәшләребез

язмышы борчый. Алар нишләрләр? Әмма латинга күчү аларга да ул кадәр авырлык китермәс, дип уйлыйм. Әгәр диаспораларның ничек итеп татар телен өйрәнүләрен күз алдына китерсәк (Башкортстанны исәпкә алмаганда), нигездә, татар мәктәпләре дип исемләнгән бөтен мәктәпләр татарча фәкать татар теле һәм әдәбиятын гына укый. Калган бөтен фәннәр рус телендә кириллица ярдәмендә өйрәнелә. Без аны үзгәртә алмабыз, мөгаен. Ул киләчәктә дә шулай булып кала бирер. Монысына да бик шөкер. Моңа кадәр без аларны дәреслекләр, укытучылар белән тәэмин иткәнбез икән, киләчәктә дә шулай дәвам итәчәкбез. Алар һәрвакыт безнең кайгыртучанлыкта булачак, без моны яхшы аңлыйбыз.

Аннары «60—70 ел язылган хәзинәбез — китапларыбыз белән журналларыбыз нишләр?» дигән сорау туа. Китапның гомер озынлыгы күп дигәндә 20—30 ел. Шуннан соң ул китапханәләрдә, архивларда саклана. Китапханәләрдәге иске китаплар белән, нигездә, белгечләр һәм китап сөючеләр эш итәләр. Без, әлбәттә, үзебезгә кирәк әдәбиятны латин хәрефләренә күчерергә тиеш булабыз. Ләкин бу — 60—70 ел дәвамында басылган китапларның бөтенесен дә күчерәбез дигән сүз түгел. Ул басмалар арасында макулатура да күп. Кирәкләрен сайлап ала белербез. Бу шулай ук бер ел, ун ел эчендә генә эшләнә торган эш түгел. Ул үз чираты белән барачак. Мине иң борчыганы — мәктәпләр өчен графика, әйбәт орфография һәм укытучыларның теләге, максаты булу.

— *Белгәнебезчә, Дәүләт Думасы депутатлары Казанда булып киттеләр. Комиссия әгъзалары нинди нәтиҗәгә килделәр һәм Татарстан Республикасының латин имласына күчүе Дәүләт Думасында яңадан каралырмы?*

— Бу инде башлаган сүзебезнең дәвамы. Мәсьәләне аерым бер депутатлар күтәргән икән, анысы — аларның эше. Дәүләт Думасын без менә ун елдан бирле күзәтәбез. Нинди генә депутатлар юк анда. Чехоев дигән депутат безнең өчен борчылып мәсьәлә күтәрмәгәндер. Регламент буенча күтәргәннәр икән, күтәрсеннәр, карасыннар. Нинди карар кабул итәләр икән — монысы да аларның эше.

Мәскәүдән килгән комиссия әгъзалары безнең эшебез белән

кызыксындылар, законнар белән таныштылар. Мәктәпләрдә, Фәннәр академиясендә булдылар, депутатларыбыз белән сөйләштеләр. Миңа калса, без аларга үзебезнең хак булуыбызны аңлатып бирә алдык. Нинди белешмә язарлар — анысын фараз итә алмыйм. Без аларга бөтен материалларны — законнарны һәм карарларны биреп җибәрдек. Бер эшне дә законсыз эшләмибез — һәрбер адымыбыз уйланып, закон тәртибендә эшләнә. Дәүләт Думасы ниндидер карар кабул итә икән, ул берничек тә безгә тәэсир итә алмый.

*— Бик күп укучыларның сорауларына карамастан, газетабыз якын һәм ерак чит илләргә тарала алмый, хәтта Россиянең үзендә дә каршылыкларга очрап тора. Интернетка чыгу өчен, анда безнең латин алфавитында кабул ителгән ә, ө, ң хәрефләре юк. Сез моңа ничек карыйсыз?*

— Яңалиф, яңа латин графикасының хәрефләре турында, билгеле, бәхәсләр бик күп булды. Шул исәптән, «төрекләштерелгән» дигән яманат алган вариант турында да. Ләкин күпчелек кабул ителгән вариантны яклады. Чөнки аны галимнәр тәкъдим итте һәм без шул вариантка тукталдык. Безнең Фәннәр академиясенә ышанмаска хакыбыз юк.

Перспективага килгәндә исә, кайбер мәктәпләрдә экспериментлар бара. Орфография төзеп бирдек. Кызганыч ки, беренче вариант бик начар булып чыкты. Без аны яңадан эшләттек һәм шушы вариант буенча экспериментлар башладык. Ул ничек булыр, укучылар ничек өйрәнерләр (тизме, озакмы) — без шуңа карап тиешле нәтиҗәләр ясарбыз. Әгәр язарга уңайсыз һәм укырга авыр булса, кайбер хәрефләрне үзгәртү дә бик мөмкин.

*2001*

## ТЕЛСЕЗ ХАЛЫК ТА, РЕСПУБЛИКА ДА БУЛА АЛМЫЙ

*(Дәүләт Советы сессиясендә ясалган чыгыш)*

Менә ун ел инде без телләр турындагы Закон белән яшибез. Дәүләт программасын тормышка ашыру белән шөгыльләнәбез. Үзенең бөеклеген югалта барган татар телен дәүләт теле дәрәҗәсенә

күтәрергә тырышабыз. Татарстандагы башка халыкларның телләрен дә игътибардан читтә калдырмыйбыз. Дөресен генә әйткәндә, шау-шуы, сүзе, ыгы-зыгысы күбрәк булды, эшләгән эшләребез тыйнаграк килеп чыкты, эшләребезнең, тырышлыкларыбызның нәтиҗәләре тагын да тыйнаграк. Зилә Рәхимьяновнаның тирән һәм эшлекле доклады боларның күбесенә җавап та бирде, республикабызда алып барылган телләр сәясәтен, тел проблемаларын күзалларга мөмкинлек тудырды. Эшләгән эшләребез, чыннан да бар, алар — күз алдыбызда, аларны берничек тә инкарь итеп булмый. Дәүләт программасы да, нигездә, үтәлде. Телләр турындагы Законны үтәү буенча без зур бер этапны уздык. Авыр, катлаулы, каршылыклы дәвер булды ул. Без анда барыбыз да турыдантуры катнаштык. Шуңа күрә ирешелгән уңышларыбыз да, эшләп җиткермәгәннәребез дә — уртак. Буласы булган инде, мин аларны санап та, анализлап та тормыйм.

Мин бары тик барыбызга да: үземә дә, сезгә дә кайбер сораулар гына куймакчы булам. Һәм киләчәктә ниләр эшләп була икәнен шәрехләп китмәкче булам.

Татарстанда ике дәүләт теле. Бер барыбыз да бөек рус теле карамагында яшибез. Безнең яклавыбызга ул кадәр мохтаҗ булмаса да, ул да Закон нигезендә яклана һәм саклана. Өстәвенә, ул — халыкара тел, РФнең дәүләт теле, ТРның да дәүләт теле. Рус телен белмәсәк, без беркем дә түгел. Без моны яхшы аңлыйбыз, шуңа күрә руслар үзләре генә түгел, татарлар да, башка халыклар да рус телен яхшылап үзләштерергә тырыша, тормышта, җәмгыятьтә тулысы белән файдалана. Татар теле дә — дәүләт теле. Һәрхәлдә, закон буенча дәүләт теле булырга тиеш. Ә закон үтәлергә тиеш. Закон буенча барыбыз да татар телен белергә тиешбез. Нәрсә соң ул дәүләт теле? Ул — дәүләт хакимиятенең, идарә органнарының халык белән аралашу, үзенең гражданнары белән сөйләшү теле. Ул телдә законнар, башка норматив-хокукый документлар, утырышларның беркетмәләре һәм стенограммалары басыла, дәүләт һәм идарә органнарының, судларның эше башкарыла. Бу — гражданның шәхесен раслаучы рәсми документларның, элмә такталар һәм белдерүләрнең, печать һәм штампларның, җитештерелә торган продукцияләрнең этикеткалары һәм ярлыкларының, то-

пографик билгеләмәләрнең һәм юл күрсәткечләренең, географик атамаларның, оешма һәм учреждениеләрнең исемнәрен билгеләү теле. Шулай ук бу — балалар бакчаларында, мәктәп һәм башка уку йортларында тәрбияләү һәм белем бирү, матбугат органнары, радио һәм телевидениедә өстенлекле булган, әлеге дәүләт гражданнары өйрәнергә һәм актив кулланырга тиешле тел.

Күрәсез, әлеге билгеләмәгә карасаң, татар теле дәүләт теле булсын өчен, шактый әйберләр эшләнә. Ләкин иң мөһиме эшләнеп җитми. Мин биредә «дәүләт теле — дәүләт хакимиятенең, идарә органнарының халык белән аралашу, үзенең гражданнары белән сөйләшү теле» дигән өлешен күздә тотам. Без башта ук стратегик хата җибәрдек. Әйе, гражданнар дәүләт телен белергә тиеш. Алар хакимият белән дәүләт телендә сөйләшергә тиеш. Әмма хакимият үзе дәүләт телен, нигездә, белми. Тел белмәгән чиновник белән ничек аралашмак кирәк? Шулай булгач, үзеннән-үзе икенче дәүләт теленә күчәргә туры килә. Без шуңа бик тә канәгать, чөнки монысына да закон каршы килми. Гражданнардан таләп итү җиңел ул. Трибунага чыгып, татар телен якларга, татар телен өйрәнмиләр дип зарланырга да була. Әмма үзеңә дә үрнәк күрсәтергә кирәктер бит? Әйтик, кайсыбызның баласы яисә оныгы татар мәктәбендә укый? Булса да бармак белән генә санарлыктыр. Инглиз мәктәбендә, пожалуйста! Махсус элитный мәктәпләрдә, пожалуйста! Төркиядә, Англиядә, АКШта, Мисырда, пожалуйста! Ә татар мәктәпләрендә — ярлы-ябагай баласы. Бу — хакыйкать! Мондый вазгыятьтә, әлбәттә, татар теле чын мәгънәсендә дәүләт теле едва ли булыр!

Билгеле инде, мин әйткәннән генә бөтенегез дә балаларыгызны татар мәктәбенә күчерә башламассыз һәм бу биредә утырган һәр кешегә кагылмый да. Мин гомумиләштереп әйтәм. Ике дәүләт телендә дә грамоталы итеп, матур итеп сөйләшүче, кайсы гына аудиториядә булса да җиренә җиткереп башта татарча, аннары рус телендә чыгыш ясаучы, халык белән һәрвакыт ике дәүләт телендә дә сөйләшүче, телләр турындагы Законны үтәүче һәм хөрмәт итүче бер зат бар арабызда. Ул — безнең Президентыбыз. Барыбыз да аннан үрнәк алырга тиешбез. Андыйлар да җитәрлек. Дәүләт Советы Рәисе белән Премьер-министр, шулай ук, ике дәүләт телен дә яхшы

белә, кирәк чакта үз эшләрендә оста итеп сөйләшә дә. Министрлар, башка җитәкчеләр арасында да андыйлар бар. Кызганычка каршы, бу үрнәк күмәк күренешкә әйләнә алмады. Җитәкчеләрнең урыннары түбәнрәк булган саен, аларның татарча белүләре дә түбәнрәк дәрәҗәдә. Аннары министрның ике телне дә белүе — бер хәл, ә менә үз министрлыгыңны татарча сөйләштерү — бөтенләй икенче әйбер. Мин әле бер генә министрлыкта да коллегияләрнең, утырышларның ике дәүләт телендә алып барылганын күргәнем юк. Дөрес, кайбер район һәм шәһәр Советларында, әгәр дә көн тәртибенә телләр мәсьәләсе керсә, алдан бик нык әзерләнеп, сессияне татарча алып барырга тырышалар. Ул, читтән карап торганда, бик кызык та һәм кызганыч та килеп чыга. Әмма анда да, икенче көн тәртибенә күчү белән, депутатлар шунда ук русчага күчәләр. Монысы инде күз буяу гына, әлбәттә. Безнең Дәүләт Советын да татар журналистлары, бигрәк тә галимнәр еш тәнкыйть утына тоталар. Янәсе, сессияләр рус телендә генә бара. Без әле ярый, ике телдә дә эшләргә тырышабыз. Әмма тәнкыйтьләүчеләрнең берсе дә, ни өчендер, башка министрлыкларны, оешмаларны тәнкыйтьләгәннәре юк. Аннары бит иң элек үзең эшләгән вузның яисә оешманың эшен күрергә кирәк. Үзең эшләгән коллективта киңәшмәләр, гыйльми советлар, профсоюз җыелышлары нинди телдә бара, эш кәгазьләре нинди телләрдә тутырыла? Ялга киткәндә яки матди ярдәм сораганда гаризаңны нинди телдә язасың? Русчамы, татарчамы? Бу мәсьәләләрне үз коллективыңда күтәргәнең бармы? Әгәр дә үзегездә тәртип икән, икетеллелек буенча закон эшли икән, чыннан да, теләсә кемне, теләсә кайсы югары оешманы рәхәтләнеп тәнкыйтьләргә була.

Докладта бик күп уңай саннар китерелде. Алар барысы да безнең эшебезне күрсәтеп тора. Фойедагы күргәзмәдә дә җитәрлек ул саннар. Аларга ышансаң, бездә, чыннан да, барысы да ал да гөл шикелле. Ләкин коры саннар минем үземә берни дә сөйләми. Әйтик, Татарстанда яшәүче мари балаларының 10 проценты үз ана телләрендә укый икән. Бу күрсәткеч бик әйбәт диләр. Әгәр дә 10 ел элек мари балалары үз телләрендә бөтенләй дә укымаган булсалар, чыннан да, 10 процент үсеш килеп чыга. Әгәр дә 7—8 процент бала

укыган булса, моның бернинди дә мактанырлыгы юк. Гомумән, ни өчен мари балаларының 10 проценты гына үз телләрендә укый. Ә 90 проценты нишләп укымый? Авыл балаларымы алар, шәһәрнекеме? Үзләре теләмиләрме, без ярдәм итмибезме? Укыган кадәресе беренчедән алып унберенчегә кадәр укыймы? Марий Эл Республикасы белән чагыштырганда ничегрәк? 10 елдан ничә процент мари баласы үз телендә укырга мөмкин? Аның өчен нишләргә кирәк? Чуваш, удмурт, мордва балаларының перспективасы ничек? Ни өчен үз телләрендә укучы татар балаларының саны акрын арта? Сәбәп нидә? Татар телен өйрәнүче рус телле балаларның проценты 99 га җиткән. Чын хәлме бу? Чыннан да, татарча беләләрме алар? Әгәр дә шулай икән, гомумән, бер проблемабыз да калмаган булып чыга түгелме соң? Ә ни өчен кайбер ата-аналар татар телен өйрәнмәс өчен судлашып йөриләр? Сораулар күп, сораулар артында проблемалар да җитәрлек.

Сүзлекләр, дәреслекләр проблемасы хәл ителде дияргә була. Һәрхәлдә, «сүзлек юк», дип зарланучылар юк хәзер. Киресенчә, аларның шактые сатылмыйча ята. Ни өчен? Бәлки, аларның сыйфатлары канәгатьләнерлек түгелдер? Чыннан да, моңа кадәр нәшриятлар кемнең нәрсәсе бар, кемнең кайда басылмыйча яткан кульязмалары бар, шуны гына чыгарып килделәр. Югыйсә нәшриятлар, Мәгариф министрлыгы җитәкчелегендә, аналитик Үзәк, яңа типтагы дәреслекләргә, сүзлекләргә үзләре заказ бирүчеләр булырга тиешләр иде. Ул гына да түгел, компетентсыз үзешчән нәшриятлар барлыкка килә. Алар чыгарган китапларның маңгайларына да «Мәгариф министрлыгы тәкъдиме белән басыла» дип язылган. Нәрсә бу? Дәүләт нәшриятларын санга сукмаумы, әллә башка сәбәпләре бармы?

Латинга киртә куйдылар. Ләкин латинга күчмәдек дип кенә дөнья бетмәде. Беренчедән, латин графикасына күчү өчен көрәшне туктатмаска кирәк, юлларын эзләргә кирәк. Аннары шунысын да әйтим: Мәскәүне генә гаепләү бик үк дөрес булмас иде. Гауганы үзебез башладык бит, үзебез уртак бер фикергә килә алмадык. Аннары Башкортстандагы татарлар һәм башкортлар белән сөйләшүләр алып барырга теләмәдек, РФ Мәгариф министрлыгы

белән элемтәгә кермәдек һәм тагын бик күп әйберләр эшләмәдек. Барсына да үзебез гаепле. Ә Мәскәүгә шул гына кирәк иде! Ленинның бер фикере дә искә килә. Аерым бер илдә революция ясап булмаган кебек, аерым бер республикада латинга да күчеп булмыйдыр, күрәсең.

Инде нишләргә? Дәүләт программасы үтәлде. Закон эшли. Аңа хәтта протест та килмәде. Әмма татар теле барыбер чын мәгънәсендә дәүләт теле була алмый. Дөресен әйтик, бу этапта ул, күпме генә теләсәк тә, барыбер дәүләт теле булып өлгерә алмас иде. Шуңа да карамастан, инде безгә телләр сәясәтен яңа бер баскычка күтәрергә кирәк. Телләр проблемасына үзешчән мөнәсәбәт булганда, безнең татар теле бервакытта да дәүләт теле була алмас кебек. Әгәр дә булсын дисәк, Фәннәр академиясе каршында Телләр стратегиясе үзәге һәм Татарстан халыклары телләренең аналитик үзәген булдыру зарур. Һәм үзәкнең үз Кудрявцевасы булырга тиеш! Анда югары квалификацияле тел белгечләре, социологлар, юристлар, тәрҗемәчеләр, галимнәр эшләргә тиеш. Тәрҗемә службасы турында да күп сөйләштек. Тик берни дә барып чыкмады. Югыйсә татар теле патша Россиясендә дә Көнчыгыш илләр белән аралашуда дипломатия теле булып хезмәт иткән. Шул чакның данын кире кайтарырга вакыт җитте. Татарга тылмач кирәкми дисәләр дә, киләчәктә кирәк булачак әле безгә тәрҗемәчеләр. Казан дәүләт университетының яшь ректорына да мөрәҗәгать итәсем килә. Анда соңгы елларда Востоковедение институтын ачу буенча шактый гына эшләр эшләнде. Аны, һичшиксез, төрки телләрнең, шулай ук күрше-тирә халыкларның телләрен дә өйрәнү үзәгенә әйләндерергә кирәк. Шулай ук тел галимнәренең XIX гасыр ахырында танылу алган Казан мәктәбенең данын яңадан кайтарырга вакыт. Бодуэн де Куртенэ, Хәлфин, Богородицкий, Радлов, Катанов, Казембек, Мәрҗани, Насыйри кебек бөек телчеләрне әйтәм мин. Бүген дә бар безнең күренекле галимнәребез. Әмма аларның һәрберсенең үз гамәле, аларны бергә туплаучы, уртак бер идеягә хезмәт иттерүче юк. Мәскәү белән сөйләшерлек, Мәскәү галимнәре санлашырлык исемнәр кирәк, Россия күләмендә, халыкара мәйданда сүз әйтерлек авторитетлар кирәк. Гомумән, алда безне

бик күп эшләр көтә. Латинга күчүне туктатып торган очракта да безгә татар телен барыбер реформалаштырырга туры киләчәк. Ул кириллицага да, орфографиягә дә, лексиконга да, терминологиягә дә кагыла. Узган гасырның 20—30 нчы елларында, Сталин идеологиясе басымы астында кабул ителгән татар теле кануннары бүгенгә, бигрәк тә глобальләшүгә йөз тоткан, интернетлы, компьютерлы киләчәккә туры килеп бетә микән? Себер, Әстерхан, Пенза, Башкортстан татарлары ни өчен бездән читләшәләр? Иң элек шул тел аркасында түгелме? Әгәр дә шулай икән, ни өчен аларның да теләкләрен искә алмыйбыз?

Кыскасы, эшебезне тагын да югары дәрәҗәдәрәк дәвам итәргә кирәк. Шуны онытмыйк: республикабызның язмышы турыдан-туры татар теленә дә бәйләнгән. Татар теле чын мәгънәсендә дәүләт теле булган очракта гына, Татарстан Республикасының киләчәге булыр! Телсез халык та, республика да була алмый!

*2002*

## ЗАБВЕНИЕ ИЛИ ИНТЕЛЛЕКТУАЛЬНАЯ ДЕГРАДАЦИЯ?

**Но главный вопрос в том — как сделать, чтобы этого не случилось...**

Сергей Михалков когда-то сравнил творчество этого поэта с мелодией курая — сладкоголосой свирели, вплетающей свою мелодию в богатую талантами татарскую поэзию.

Опытный журналист, видный общественный и государственный деятель, заслуженный деятель искусств Татарстана, заслуженный работник культуры Башкортостана, лауреат Государственной премии имени Габдуллы Тукая, член президиума Госсовета Татарстана, председатель комиссии по установлению идентичности текстов законов Республики Татарстан на татарском и русском языках — сразу и не перечислишь все регалии поэта Роберта Миннуллина. И, разумеется, его, как и многих неравнодушных к судьбе народа людей, серьезно волнует проблема развития родной речи, роли татарского языка в современной жизни Татарстана. О проблемах изучения языка, значении национального фактора

в жизни Российской Федерации, мировых тенденциях в развитии межнационального общения и пойдет речь в этой беседе.*

*— Роберт Мугаллимович, зачем Вам, поэту, хождение во власть? Не проще ли было отдаться целиком творчеству, ведь политика — вещь жесткая, требующая сильнейшей концентрации сил?*

— Такова уж психология нашего народа — он привык доверять знатокам слова. Слово писателя, поэта всегда пользовалось успехом. Мой приход в высшие эшелоны республиканской власти, в Государственный Совет, совпал с переменами, произошедшими в обществе в 1990 году. Тогда нельзя было остаться в стороне — решались важнейшие для нашего народа вопросы. За прошедшие четырнадцать с лишним лет я вместе с единомышленниками, то есть видными деятелями татарской литературы и искусства, отстаивал и отстаиваю интересы родного народа. Знаменательно то, что в нашем парламенте представлена творческая интеллигенция. Народ верит нам!

*— 26 апреля на Дне родного языка Вы прочли грустное стихотворение. Ваши собратья по перу были энергичнее, в их произведениях слышался призыв к борьбе, а Вы говорили о смерти, о том, что поэта невозможно убить, невозможно уничтожить его песню... Откуда этот пессимистичный настрой?*

— Ну не всем же быть буревестниками. Для меня ближе спокойные интонации, слова, задевающие тончайшие струны человеческой души. Поэт, по моему мнению, должен пробуждать в людях чистые, добрые, светлые мысли. Пессимистичного настроя нет, скорее реальное понимание происходящего, реальная оценка своих возможностей. По правде говоря, День родного языка оставил впечатление формального мероприятия. Этот праздник должен носить массовый характер, проходить по всей республике, во всех учреждениях. Не продумана форма проведения праздника, механизмы финансирования. Сабантуй же научились проводить — и спонсоров находят, и интересные конкурсы организуют.

---

* Беседовала журналист Эльвира Абдульманова.

День родного языка должен проходить так же весело и интересно, как сабантуй. Скажем, в магазинах, общественных местах в этот день надо вывесить объявления: «Сегодня разговариваем только на татарском языке». Не знающим выдавать небольшие распечатки-разговорники. Если проживающие в Татарстане русские сумеют выучить хотя бы сотню слов на татарском языке — это, безусловно, станет большим достижением.

— *Вы, как мастер слова, как никто другой ясно представляете себе его силу, возможности. Какова культура татарской речи в нынешнем обществе?*

— К сожалению, здесь все обстоит более чем плачевно. Послушав иных депутатов, крупных руководителей, выступающих в парламенте, так и хочется им сказать: ну, не можешь говорить — не говори! Не знаешь родной язык, говори на том, который тебе легче дается! Со школьной скамьи надо приучать к культуре речи. Порой такие несуразицы приходится слышать, что волосы дыбом встают. Мы должны защищать наш язык от подобного уродования. К счастью, у нас достаточно специалистов, прекрасно владеющих литературным татарским языком, любящих и уважающих родной язык. Нам необходимы общественные организации, которые смогли бы объединить энтузиастов, борющихся за чистоту речи. На сегодня лингвисты не пользуются должным авторитетом.

— *На одном энтузиазме вряд ли возможно поднять культуру речи...*

— Почему же на одном энтузиазме? В институтах, университетах, школах, техникумах и училищах — везде предусмотрено финансирование, выделены средства на обучение татарскому языку. Нередко приходится наблюдать такую картину — два учебных заведения находятся в равном положении по уровню финансирования, а качество обучения — небо и земля. Не верю, что нет денег — нет желания работать!

— *Есть немало стран, в которых несколько государственных языков. Оформление различного вида документации ведется одновре-*

*менно на двух-трех языках. Почему в Татарстане делопроизводство не переводится на татарский язык?*

— К сожалению, бытует мнение, что это напрасная трата времени и денег. Может быть, тогда вообще ничего не фиксировать на бумаге? Почему русскоязычные граждане могут получить информацию, а те, кто изъясняется только на татарском, обделены? Так не должно быть! Вот поэтому в Госсовете Республики Татарстан все законы принимаются в обязательном порядке на двух государственных языках. Этим мы показываем пример всем остальным. Уже готова специальная Программа, предусматривающая ведение документации на двух языках.

— *В нашумевшем «прокурорском» деле фигурировала видеозапись, где «человек, похожий на Скуратова» развлекался в обществе проституток. У одной из них он спросил, как ее зовут. Та назвала распространенное татарское имя. Заинтересовавшись, «клиент» попросил ее произнести пару фраз на татарском языке. Девица даже слова вспомнить не смогла. Поневоле напрашивается вывод, что, забыв родной язык, человек деградирует.*

— Насчет девицы скажу: «Ну и хорошо, что не вспомнила!» Дело не только в языке. Сначала теряется связь с родными местами, затем забывается язык. Разучившись мыслить на родном языке, человек теряет все. Теряет связь со своим родом. Татары, обрусев, даже меняют имена и фамилии, так как в их сознании рождается противоречие. Они еще помнят о своем происхождении, но уже не понимают языка. Происходит раздвоение личности, и, чтобы «восстановить гармонию», человек отказывается от своей национальности. Таких примеров очень много. Не зря же существует поговорка: «Копни любого русского, и ты найдешь в нем татарина».

— *Меня иногда спрашивают, зачем вообще необходимо деление на национальности? Не за горами день, когда вся планета будет говорить на одном языке, пользоваться одним алфавитом. Как бы Вы ответили на этот вопрос?*

— Не думаю, что так скоро произойдет «слияние» всех наций. К тому времени, когда придет такой день, человечество, возможно, и вовсе исчезнет. У каждого из нас есть душа, которая живет воспоминаниями. А воспоминания — это мать, отец, дедушка с бабушкой, родные места, ровесники, одноклассники, родная природа. Чем дольше я живу, тем чаще приходят на память события детства, юности. Вспоминаются слова друзей, песни, стихи. Незаметно для себя я перехожу на их стиль речи. Человек этим счастлив, этим защищается от жизненных невзгод. Понимание того, что ты не безроден, что за тобой поколения честных и порядочных людей, помогает переносить трудности, придает силы жить. Жизнь людей, обладающих памятью, более полнокровна и насыщенна, их чувства и эмоции ярче, красочнее. В противном случае человек превращается в робота, которому можно отдать любой приказ, и он, не задумываясь, выполнит его. Я этого страшусь. Один язык, одна национальность, одна идея на всех — это роботизация человечества. Люди и так все больше напоминают бездушные механизмы, особенно городские жители. Горожанину некогда присесть, задуматься о смысле жизни. Все его силы и время отнимают заботы о насущных потребностях. Причем улучшается качество жизни — растут запросы. Погоня за телевизором, кинокамерой, машиной, «лучшими, чем у соседа», ведет к самому краю пропасти — в ад.

Я — оптимист. Поэтому надеюсь, что день, когда мир превратится в громадный муравейник живых механизмов с убогой речью и жалкими эмоциями, никогда не наступит.

*— Огромное разнообразие языков заставляет задуматься о генетической природе языка.*

— Не исключено, что в процессе эволюции генетические особенности наложили отпечаток на тип мышления, а значит, и на речь. Но образ жизни, среда в первую очередь влияют на развитие речи. Если родной язык не впитан с молоком матери, достичь совершенства в нем очень трудно.

*— Любая попытка экспериментировать с Природой способна привести к катастрофе. Возможно, существование такого многообразия народов и наций — своеобразная лаборатория, с помощью которой увеличиваются шансы на выживание человечества. Не выживет один народ, не сумеет приспособиться к меняющейся действительности, значит, подымется другой. Дикие племена, в которых принято вступать в браки с родственниками, вырождаются. Нужна свежая кровь.*

— Тут не обошлось без божественной мудрости. Все созданное Аллахом несет здравое зерно, люди не всегда понимают это. Есть, пить, спать и заниматься сексом — таков круг интересов человека без прошлого. В этом он ничем не отличается от скотины.

*— В Татарстане время от времени раздаются голоса, призывающие сократить количество часов, отведенных на изучение татарского языка. Даже до суда дело довели. Почему русские не хотят учить татарский язык?*

— Меня тоже удивляет этот факт. Казалось бы, тебе предоставлена возможность обогатить свой интеллектуальный багаж, получить бесплатные знания. Тем более что и языковая среда есть. Нет же. Столетиями живут рядом с нами, на одной улице, в одном доме, ежедневно слышат татарскую речь и ленятся пару фраз выучить на «чужом» языке. Самый нашумевший пример — Прибалтика. Пикеты, митинги, демонстрации — на все идут из лени. Лишь бы не напрячь чуть-чуть мозги, лишь бы не узнать чего лишнего.

*— Какой мы народ?*

— В языковом отношении слишком мягкий, податливый. Полный зал народа. В зале сидит один «не татарин». И все татары, ломая, коверкая язык, говорят на русском. Ради одного единственного слушателя. Нет, чтобы перейти на родной язык и поговорить от души. Нет, понимаете ли, слишком «тактичны». Мы сами виноваты в пренебрежительном отношении к нам.

*2004*

## КУЗГАЛЫРГА ВАКЫТ!

Моннан берничә ел элек безнең Дәүләт Советы 26 апрельне Туган тел көне дип игълан иткән иде. Безнең бүгенге конференциябез дә шул мөнәсәбәттән оештырылды. Биредә шулай ук киң җәмәгатьчелекнең дә соравы исәпкә алынды. Әлбәттә, мондый туган тел көннәрен төрлечә уздырырга була. Соңгы берничә елда азмы-күпме җанлану да сизелә. Ул җанлылык, нигездә, безнең мәктәпләребездә, югары уку йортларында. Ләкин мин моны һич кенә дә канәгатьләнерлек түгел дип уйлыйм. Әгәр дә чын мәгънәсендә Туган тел көнен уздырырга җыенабыз икән, ул, һичшиксез, ике дәүләт теленең дә статусын күтәрергә ярдәм итәрлек булырга тиеш. Бу көнне дәүләт учреждениеләрендә, министрлыкларда, шулай ук Дәүләт Советында да махсус ике телдә, ике дәүләт телендә дә чаралар уздыру зарур. Бу башка оешмаларга да: кибетләргә, аптекаларга, шифаханәләргә, көнкүреш хезмәте күрсәтү комбинатларына, гомумән, халык белән эшли торган бөтен урыннарга да кагыла. Боларга ничек ирешергә соң? Теләк булганда, тырышканда, максат итеп куйганда эшләп булмаслык эшләр түгел, минемчә. Башлап җибәрергә, дәвам итәргә, традициягә әйләндерергә генә кирәк.

Конференцияне әзерләгәндә дә, бүгенге эш барышында да бер фикер ишетелде. Нигә кирәк бу конференция, аннан ни мәгънә, җыелабыз да сөйләшәбез, җыелабыз да сөйләшәбез, янәсе. Кызганычка каршы, сөйләшми генә бездә берни дә хәл итеп булмый. Башта сөйләшергә, фикер алышырга, бәхәсләшергә кирәк. Аннары инде конкрет эшкә дә тотынырга була. Менә бүген законнар турында сүз булды. Безнең татар теле закон буенча да, конституция буенча да дәүләт теле статусына ия. Без моны барыбыз да яхшы беләбез. Әмма татар теленең функциональ яктан әле һаман да чын мәгънәсендә дәүләт теле булып җитә алганы юк. Һәм иң кызганычы шул: татар теле әлегә кадәр законнар теле түгел. Моңа кадәр язылган, кабул ителгән йөзләгән Татарстан законының берсе дә татарча язылмаган. Без бу хакта борчылабыз, еш сөйлибез, ләкин бер дә алга китеш сизелми. Без кабул иткән законнар, закон

нигезендә, ике дәүләт телендә дә басылып чыга. Аңа кадәр русча язылган законнарны без татар теленә тәрҗемә итәргә мәҗбүрбез. Тәрҗемә исә нәкъ оригиналдагы кебек яңгырарга тиеш. Ә законнар, безнең депутатлар моны яхшы белә, бик тә авыр тел белән, гади халык бик үк аңламаслык итеп, «хәйләкәр» итеп языла. Аны бер кат уку белән генә ныклап аңлап та булмый. Шуңа күрә дә законнарны тәрҗемә итү бик тә югары профессиональлек таләп итә. Биредә бер генә хилафлык та, бер генә хата да, бер генә ике мәгънәлелек тә, бер генә юридик, лингвистик төгәлсезлек тә китмәскә тиеш. Чөнки аның нәтиҗәләре төрле күңелсезлекләргә китерүе мөмкин.

Безнең бармак белән генә санарлык тәрҗемәчеләребез менә унбиш ел инде шушы җитди тәрҗемә эше белән шөгыльләнәләр. Алар — үзлекләреннән өйрәнгән практиклар. Аларга авыр. Ә менә безнең галимнәребез соңгы елларда кабул ителгән йөзләгән законнарны һәм карарларны укып караганнары бар микән? Аларның безнең тәрҗемәләребезгә мөнәсәбәтләре нинди икән? Нинди киңәшләре, тәкъдимнәре, тәнкыйтьләре бар икән? Кызганычка каршы, без әле бу мәсьәләдә бер тапкыр да сөйләшкәнебез, фикер алышканыбыз юк. Монда гаеп атта да, тәртәдә дә бардыр. Миңа калса, безнең бу законнарыбыз нигезендә төрледән-төрле диплом эшләре, диссертацияләр, башка фәнни хезмәтләр язарга мөмкин булыр иде. Безнең тәрҗемәчеләребезне терминнар мәсьәләсе аеруча борчый. Көндәлек тормышка, әдәбият-сәнгатькә кагылган законнарны әле шактый җиңел тәрҗемә итеп була. Ә инде экология, икътисад, финанс, авыл хуҗалыгы яисә сәнәгать законнарын тәрҗемә итә башласаң, еш кына чарасызлыктан аптырашта каласың.

Биредә шундыйрак бер фикер ишетелде: тел үзенә кирәкле, үзенә ятышлы, ярашлы терминнарны үзе сайлап ала ул. Әлбәттә, шулай. Әмма моның өчен еллар кирәк. Без регламент буенча законнарны, ике атна эчендә тәрҗемә итеп, Президентка тапшырырга бурычлы. Яңа терминнарның адаптация узганын көтеп торырга безнең вакытыбыз юк. Аннары без тәрҗемә ителгән законның бер генә терминын да, бер генә сүзен дә Дәүләт Советы

карарыннан башка үзгәртә алмыйбыз. Бу мәсьәләдә безгә тагын бер тапкыр ныклап уйларга һәм ниндидер бер эшлекле нәтиҗәгә килергә кирәк.

Конференциянең бик җентекләп оештырылуы күренеп тора. Бик файдалы тәкъдимнәр, бик кызыклы фикерләр әйтелде. Миңа, мәсәлән, билгеле тел белгечебез Гафур Сөнгатовның чыгышы ошады. Терминнарның татар теле әйләнешенә ни өчен шулай авырлык белән керүен ул безгә яхшылап аңлатып бирде. Җәүдәт Сөләйманов исә компьютерларны татарчалаштыру турында бик җентекләп, яратып, мавыгып сөйләде. Дөрес, татарча компьютерның кирәклеген минем кебекләр бик аңлап та бетермәскә мөмкиннәр. Тәнәфескә чыккач, Туфан Миңнуллин да үзенең аңламавын әйтте. Ләкин ике Миңнуллин аңламый дип кенә бу эшне туктатырга кирәк дигән сүз түгел, билгеле. Татар теле, дәүләт теле буларак, тормыш-көнкүрешнең бөтен тармагында да тулысынча эшләсә генә чын дәүләт теле була ала. Берәр тармакта гына файдаланылмаса да ул инде берничек тә камил тел була алмый. Бәхеткә күрә, безнең шундый булдыклы егетләребез, әзерлекле кадрларыбыз бар. Аларга ярдәм итәргә генә кирәк.

Сөйләшү барышында шактый гына проблемалар күтәрелде. Аларны тудыручылар, нигездә, без үзебез. Бәс шулай икән, төзәтүчеләре дә үзебез булырга тиеш. Проблемаларның күбесе тел белгечләренең эшчәнлеге белән турыдан-туры бәйле. Алар — телне фәнни өйрәнеп, аерым сүзләрне, терминнарны билгеле бер тәртипкә китереп, практикага кертүчеләр, куллануга тәкъдим итүчеләр. Ә гади халык ул сүзләрне йә куллана, йә кулланмый. Ул читтән күзәтүче һәм файдаланучы гына. Шуңа күрә бу очракта аларны гаепләп тә, мәҗбүр итеп тә булмый.

Минем тагын бер фикерем бар. Безнең тел өлкәсендә эшләүчеләребез бихисап, телгә күпмедер мөнәсәбәте булганнар тагын да күбрәк. Фән докторлары һәм кандидатлары, академиклар — турыдан-туры тел гыйлеме белән шөгыльләнүчеләр, аннары татар теле укытучылары, шәкертләр, тәрҗемәчеләр, нәширләр, язучылар, шагыйрьләр, журналистлар... Барыбызның да эшчәнлеге тел белән бәйләнгән. Һәрберебез үз куышында, үз оешмасында, үз

кафедрасында казына, үз эшен эшли. Ләкин бу өлкәдә бернинди дә координация юк, үзара бәйләнеш, элемтә юк. Кемнең ни белән шөгыльләнгәнен белмибез. Шуңа күрә дә без шушындый мәҗлесләрдә башыбызга ни килә, шул хакта сөйләшәбез. Күп очракта элементар әйберләр турында сөйлибез, уртак бер фикергә килә алмыйбыз. Шушыларны истә тотып, безгә берләшергә кирәк. Әйтик, спортның бөтен төрләре буенча да үз федерацияләре бар. Язучыларның, композиторларның, рәссамнарның, журналистларның үз иҗат оешмалары бар. Ә телчеләрнең ни өчен булмаска тиеш? Миңа калса, татар телчеләренең үзләренең иҗтимагый оешмаларын булдырырга вакыт җитте. Ул, иң элек, шушылай бәхәсләшер-киңәшер өчен, дискуссияләр оештырыр өчен кирәк, билгеле бер фикергә килер өчен кирәк. Аннары аның башка республикаларда һәм өлкәләрдә дә бүлекләре булырга мөмкин. Ни өчен дисәң, татар теле белгечләре Татарстанда гына түгел, Башкортстанда да, башка төбәкләрдә дә җитәрлек. Менә шуларның барысын да бергә туплап эшләтә торган иҗади оешма кирәктер дип исәплим. Аннары Дәүләт Советы сессияләрендә дә республикада Лингвистика үзәге булдыруның зарурлыгы турында сүз булган иде. Ул элмә такталарга, эш кәгазьләренә, тәрҗемәләргә, терминология һәм  топонимика өлкәсендә экспертизалар уздырыр иде, кирәкле оешмаларга практик ярдәм күрсәтер иде. Аннары латин графикасына күчү тоткарлана икән, безгә барыбер кирилл графикасына да азмы-күпме реформа уздырырга кирәк булачак, дип уйлыйм. Татар теленең орфографиясенә, орфоэпиясенә, алынма сүзләрнең язылышына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе дә көн тәртибеннән төшеп бетмәгән. Бу проблемаларны хәл иткәндә дә төп сүзне әлеге Үзәк әйтер иде. Без инде үз чиратыбызда оештыру эшләрен башлап җибәрдек. Дәүләт Советы Рәисе исеменнән Татарстан Президентына хат язылды. Җавап та алдык. Президент, нигездә, каршы түгел. Калганы фәкать үзебезгә бәйләнгән. Галимнәр эшлисе бер генә эшне дә Президент яисә депутатлар килеп эшләмәс. Уйланырга, кузгалырга вакыт!

*2005*

## АВЫЛ ИСЕМНӘРЕ ТУРЫНДА

*(Дәүләт Советы сессиясендә ясалган чыгыш)*

Әгәр дә хәтерләсәгез, узган сессия утырышларында без муниципаль берәмлекләрнең һәм алар составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статуслары турындагы закон проектларын тикшердек. Закон проектлары бик шапшак һәм ашыгып эшләнгәнлектән, аларда бик күп хаталар киткәнлеге ачыкланды. Андый тупас хаталар закон проектларының русча һәм татарча вариантларында да җитәрлек иде. Сессия хөкүмәткә махсус комиссия төзергә тәкъдим итте. Президентның шушы хакта әйткән сүзләре дә беркетмәгә теркәлгән. Әлеге мәсьәләнең гади бер лингвистик чара гына түгел, ә җитди социаль-сәяси проблема икәнен без яхшы аңлыйбыз. Шуңа күрә дә Дәүләт Советында ашыгыч рәвештә эшче төркем төзелде. Анда Министрлар Кабинетының Телләрне үстерү бүлегеннән, Татар энциклопедиясе институтыннан, Тел, әдәбият һәм сәнгать институтыннан, Тарих институтыннан танылган галимнәр һәм үзебезнең тәрҗемәчеләр эшли. Без берничә атна эчендә иллеләп закон проектын карап чыктык. Эш барышында түбәндәгеләр ачыкланды.

1. Торак пунктларның статусларын билгеләр алдыннан аларга топонимик һәм административ экспертиза ясап чыгарга кирәк. Безнең Дәүләт Советы яшәүдән туктаган элекке авылларны гамәлдән чыгару турында вакыт-вакыт карарлар кабул итеп тора. Әмма андый үле авыллар бүгенге көндә дә исәптә йөри. Әйтик, Әгерҗе районында Холмовка, Зирекле Елга авыллары, Алексеевск районында Зотеевка, Кызыл Чишмә, Андреевка авыллары, Әлмәт районында Кызыл Кичү, Сәмәрканд, Хазовка поселоклары, Арча районында Абзабар, Кишмәт, Сарай-Чокырча авыллары, Биектауда Әсән, Таршна, Глухово авыллары күптән инде бер кешесез. Мондый авыллар бөтен районнарда да бар. Аларны кичекмәстән гамәлдән чыгарырга кирәк. Соңгы унъеллыкларда гына да республика буенча шушындый йөзләгән авылларыбыз юкка чыкты. Куйбышев, Түбән Кама сусаклагычлары аркасында

күпме гүзәл авылларыбыз таралышып бетте, күпме нигезләребез су астында калды. Рәсми рәвештә беткән кайбер авыллар бакчачылык ширкәтләренә әйләнделәр. Күбесенең урынында хәзер — чүплек, яхшы дигәндә дә — басу. Минем бер теләгем бар: элекке авыл урынына истәлек билгеләре куясы иде. Ә бит алар — гасырлар дәвамында безнең туганнарыбыз, якташларыбыз туып-үскән, яшәгән, гомер иткән урыннар. Югыйсә алар Җир йөзеннән дә, тарихыбыздан да бөтенләй юкка чыгалар. «Бу урында фәләненче елларда Туктар авылы булган» дип язып кую ул кадәр чыгым сорамас. Узган гасырда юкка чыккан авылларның «Кызыл китабы»н булдырырга да вакыт җиткәндер.

2. Бер-берсенә якын урнашкан кайбер авыллар, поселоклар күптән инде бергә кушылган, бер авылга әйләнгәннәр. Мәсәлән, Зеленодол районында Кече Йорт Карамалы тау авылына, Булатово поселогы Норлат авылына кушылган. Мондый хәл башка районнарга да хас. Боларны рәсми рәвештә берләштерергә вакыт. Тагын бер кызык факт. Кайбыч районындагы Афанасьевка авылы 1952 елда ук ТАССР Югары Советы карары нигезендә исәптән төшерелгән. Ләкин, бәхеткә күрәме, авыл яңадан яши башлаган. Ул әле дә бар. Әмма ул һаман да Дәүләт Советы тарафыннан рәсми рәвештә яңадан кайтарылмаган. Халык исәбен алу мөнәсәбәтеннән чыгарылган китапта да ул юк. Ә киләчәктә һәр авылга закон буенча финанс номерлары бирелергә тиеш. Булмаган авылга аны ничек бирәсең? Бу хакта безгә комитет утырышында юстиция министры Мидхәт Курманов хәбәр итте.

3. Кайбер торак пунктларның исемнәре, гомумән, тузга язмаган. Аларга вакытында нормаль, матур авыл исемнәре кушарга беркемнең дә башына килмәгән. Менә берничә мисал. *Поселок Каратунского Хлебоприемного пункта, поселок железнодорожного разъезда Чурилино, поселок Первой Бригады Совхоза, поселок Третьей Бригады Совхоза, поселок Татарской Зональной Опытной станции, поселок фермы № 2 совхоза «Мамадышский»* һ.б. Алар — зур-зур авыллар. Соңгысында, мәсәлән, 266 кеше яши. Биредә, әлбәттә, иң элек шушы авылларда яшәүче халык үзе борчылырга һәм туган авылларына матур бер исем кушарга тиеш.

4. Аннары бүгенге көндә нибары унлап кына пенсионер яшендәгеләр яши торган перспективасыз авыллар саны да 70—80 гә җитә. Алар белән нишләргә? Иртәгә, иртәгә булмаса, берсекөнгә бетәчәкләр бит алар. Ә бүген ничек яши андагы кешеләребез? Бу проблемалы авыллар хакимиятне, һичшиксез, борчыйдыр, нидер эшләргә җыеналардыр.

5. Авылларның статусларын яңартырга да вакыт җитте. Чөнки 5-6 кеше яши торган *село*лар, 1000 кеше яши торган *поселок*лар, *деревня*лар күбәйде. Гасыр башында боларны, һичшиксез, яңадан карап чыгарга, ниндидер положение эшләп, аларны билгеле бер тәртипкә китерергә кирәк.

Болар барысы да алдагы көннәрдә ашыгыч рәвештә эшләнергә тиешле эшләр. Кем, кайсы оешма эшләргә тиеш? Әлегә эшлим дип торучылар күренми.

Инде турыдан-туры авыл исемнәренә күчик.

Иң элек шуны әйтәсем килә. Авыл исемнәренең дөрес язылышы белән моңа кадәр беркем дә беркайчан да җитди рәвештә шөгыльләнмәгән. Дөресрәге, шөгыльләнгәннәр, әмма уртак фикергә килмәгәннәр, законлаштырмаганнар. Без бик күп чыганакларны, шул исәптән төрле-төрле сүзлекләрне, республиканың административ-территориаль бүленеш басмаларын, халык санын алуда файдаланылган яңа басманы өйрәнеп чыктык. 2002 елда беренче тапкыр «Татар энциклопедия сүзлеге» исемле фундаменталь хезмәт басылып чыкты. Ләкин аларның берсе дә юридик көчкә ия түгел. Безне гаҗәпләндергәне шул булды: анда авыл исемнәре кем ничек тели, кем ничек булдыра, кем ничек уйлый шулай язылган. Бернинди дә принципка корылмаган. Ә телләрнең — татар теленең дә, рус теленең дә — үз законнары, үз нормалары бар. Аларны, һичшиксез, үтәргә кирәк. Әнә шул нормалар үтәлмәгәнгә күрә дә авыл исемнәре белән төрле казуслар, аңлашылмаучылыклар, хаталар килеп чыга. Без эш барышында районнар белән дә тыгыз элемтәдә булдык. Дөресен генә әйткәндә, алар үзләре дә буталып беттеләр. Моннан ун еллар элек алар инде «Татар энциклопедиясе» өчен материаллар җибәргән булганнар. Печатьләре басылган, куллары куелган. Ләкин безгә

җибәргәннәрендә бөтенләй башка язылыш, башка исемнәр дә бар. Ул гына да түгел, шушы бер ай эчендә ул исемнәрне районнардан берничә тапкыр үзгәртеп тә җибәрделәр, үзләре дә кат-кат килделәр. Димәк, урындагы хакимият тә мондый мәсьәләләргә битараф түгел. Алар да борчыла, уйлана. Бу, минемчә, әйбәт фал. Ә хәл итәсе әйберләр җитәрлек. Мәсәлән, Чаллы шәһәре. Рәсми исеменең русчасы — Набережные Челны, татарчасы — Яр Чаллы. Татар энциклопедиясендә — Чаллы гына. Хәтта Конституциягә дә Чаллы гына булып кереп киткән. Халык та Чаллы дип кенә йөртә. Ә рәсми эш кәгазьләрендә — Яр Чаллы. Хакимиятнең, әлбәттә инде, аны Яр Чаллы килеш калдырасы килә. Икенче мисал. Зеленодольский районының татарчасын халыкта хәзер Яшел Үзән дип йөртәләр. Татар матбугатында да шулай кереп китте. Татар энциклопедиясендә дә — Яшел Үзән. Ә фактта исә Яшел Үзән дигән шәһәр юк, андый район да юк. Зеленодол гына бар. Конституциядә дә шулай. Ә менә Чүпрәле — Дрожжаное заманында рәсмиләштерелгән булган, халык та өйрәнгән, әмма ул да, асылда, тәрҗемә ителмәскә тиеш иде.

Тагын бер күренеш. Шактый гына авыллар халыкта икенче исем белән дә йөртелә. Мәсәлән, сессия утырышында депутат Туфан Миңнуллин искә алган Торна авылы. Ул — Кама Тамагы районындагы Малаевка авылының халыкта йөргән татарча исеме. Рәсми документларда Торна авылы беркайда да теркәлмәгән. Административ-территориаль бүленеш китабыннан да, татар энциклопедиясеннән дә андый исемне табып булмады. Торнаташ авылы, Торнаяз авылы бар, Торна юк. Кама Тамагы районында фәкать Малаевка дигән авыл гына бар. Халыкта хәтта өч исем белән йөргән авыллар да очрый, әмма аларның берсе генә рәсми кулланылышта йөри. Без башта икенче исемнәрне беренчесе белән бергә җәяләр эченә теркәргә дә уйлаган идек, әмма юристлар әлегә ашыкмаска куштылар. Монысын да хәл итәргә кирәк булачак.

Башта ук әйтеп куярга тиешмен: без рус исемнәренә әлегә кагылмадык. Гәрчә сорауларыбыз күп булса да. Чөнки ул федераль хакимияттән рөхсәт алу белән бәйләнгән. Волокитасы күп, вакыты да күп кирәк булачак. Без моңа берничек тә өлгерә алмыйбыз.

Әмма якын арада безгә бу мәсьәләләрне карау өчен, барыбер яңадан әйләнеп кайтырга туры киләчәк. Татарча авыл исемнәренең билгеле бер өлешенә үзгәрешләр керде. Аларның кайберсен район хакимиятләре үзләре үзгәртте, кайберләренә «Татар энциклопедиясе» вариантын алдык, кайберләре буенча компромиссларга барган очраклар да булды. Әмма болар исем үзгәртү түгел, ә авылларның яңача, татарча транскрипциясе генә. Моның өчен без берничә пункттан торган тәкъдимнәр дә эшләдек. Иң элек, татарча авыл исемнәре урыннарда кабул ителгән, традицион аталышта, әмма әдәби тел нормалары нигезендә язылырга тиеш. Чөнки авыл исемнәре — халкыбызның рухи хәзинәсе, һәм алар дәүләт тарафыннан сакланырга бурычлы. Болай да инде үзгәртеп язулар һәм руслаштырулар аркасында, ничек ишетелсә, шулай яза-яза бик күп авылларыбызның беренчел исемнәре югалып беткән яисә бөтенләй аңлашылмаслык дәрәҗәгә килгән. Шунлыктан аларның күбесенең этимологиясен төгәл генә ачыклап та булмый.

Әйткәнемчә, рус авылларының исемнәре татарчага тәрҗемә ителми. Әмма төп исемгә кушылган олы, кече, югары, түбән кебек аергычлар тәрҗемә ителә һәм аерым языла. Мәсәлән: Мокрые Курнали — Юеш Кернәле, Большой Куюк — Олы Көек, Малая Кульга — Кече Кульга. Русча эквивалентта кушылып язылган *ново-* элементы да мөстәкыйль сүз итеп тәрҗемәләнә. Мәсәлән: Новоникольск — Яңа Никольск, Новотроицкое — Яңа Троицк. Рус фамилияләренә нигезләнгән авылларның *-ово* кушымчалары исә кыскартып языла. Село Сумароково — Сумароков авылы, село Анненково — Анненков авылы.

Калган үзгәрешләр, нигездә, татарча авыл исемнәренең баш хәрефтән язылуына, кушылып яки аерым язылуына, сызыкча аша яисә сызыкчасыз язылуына кайтып кала.

Йомгаклап шуны әйтәсе килә: вакыт кыска булу сәбәпле, без бөтен проблемаларга да кагыла алмадык. Бу — физик яктан мөмкин түгел эш иде. Мин инде кабул иткәннән соң регламент буенча ике атна вакытыбыз бар, кайбер калган кимчелекләрне шунда карап чыгарбыз дип уйлаган идем. Ишетүемчә, законнарны иртәгә үк Президентка кул куярга җибәрергә кирәк икән.

Безнең комиссия моңа берничек тә өлгерә алмый, әлбәттә. Андый җаваплылыкны мин үз өстемә ала алмыйм.

Тагын берничә тәкъдимем бар. Бу — безнең олы эшебезнең башы гына. Киләчәктә әлеге проблемаларга барыбер әйләнеп кайтырга туры киләчәк. Безнең ут күршеләребез моны 90 нчы елларда ук эшләп куйдылар инде. Аларда хәзер русча Асяново да, Куккуяново да, Суккулово да юк, ә Асян, Куккуян, Суккул гына бар. Безгә дә шулай эшләргә кирәк. Аннары, кичекмәстән, һәр авылның паспортын булдыру шарт. Анда авылның рәсми исеме дә, татарча һәм русча исемнәре дә, халыкта йөргән исемнәр дә булырга тиеш. Тарихи исемнәребезнең берсе дә югалмаска тиеш. Закон кабул иткән саен, халыктан сорашып йөрү бер дә килешми. Шулай ук безгә бу өлкәдә шактый гына хокукый-норматив документлар да кабул итү мәслихәт булачак. Иң элек йә Президент каршында, йә Дәүләт Советында Татарстан Республикасының административ-территориаль төзелеше буенча комиссия төзергә кирәк булыр. Әгәр дә андый комиссия төзибез икән, административ-территориаль төзелешкә кагылышлы мәсьәләләрне карау һәм хәл итүнең тәртибе турында Положение эшләү сорала. Ләкин бу комиссия җәмәгатьчелек тәртибендә генә берни дә эшли алмаячак. Шуңа күрә комиссиянең бөтен кара эшен, фәнни-гамәли вазифаларын башкаручы бер үзәк — Татарстан Республикасының Топонимик үзәге яисә Лингвистик службасы булырга тиеш.

Бөтен булган проблемаларны тормышка ашыру өчен безгә тагын ике закон кабул итү шарт. Беренчесе — Татарстан Республикасында физик-географик объектларның атамалары турындагы закон, икенчесе — Татарстан Республикасында административ-территориаль берәмлекләргә, торак пунктларга, урамнарга, мәйданнарга исем бирү һәм аларның исемнәрен үзгәртү тәртибе турындагы закон. Шушы законнарны эшләп, кабул итмәсәк, без һаман үзешчәнлек дәрәҗәсендә калачакбыз. Аннары шуны да онытмыйк: мин әле монда республикадагы бөтен муниципаль берәмлекләрнең дә яңа картографик тасвирламаларын төзү турында сүз кузгатмадым. Анда инде авыл исемнәре генә түгел, ә һәрбер елга, инеш, тау, чокыр исеме ике телдә дә дөрес, грамоталы

язылырга тиеш. Һәм без аны 2007 елга кадәр эшләп бетерергә бурычлыбыз.

Инде соңгы сүзем. Депутатларга да, район вәкилләренә дә шуны әйтәсем килә: без тәкъдим иткән вариантлар белән килешик. Кемгәдер нәрсәдер ошамаса, аннан фаҗига ясамыйк. Без барыбер бу мәсьәләгә әйләнеп кайтачакбыз, барыбер ахырына кадәр җиткерәчәкбез.

*2005*

## «ПОДУМАЕШЬ, АВЫЛ ИСЕМНӘРЕ!»

*(Дәүләт Советы сессиясендә ясалган чыгыш)*

Без нишләптер бөтен эшне дә ашык-пошык эшләргә яратабыз: килеп терәлгәч кенә кыймылдый башлыйбыз, иртәнге эшебез кичкә ярамый. Татар акылы төштән соң диюләре хактыр, күрәсең. Күренекле шагыйрь Наҗар Нәҗминең «Татар акылы төштән соң, Кайчан төш җитәр икән?» дигән шигырь юлларын да өстисе килә. Булачак муниципаль берәмлекләр һәм аларның территориаль чикләрен билгеләү турындагы закон проектлары белән дә шулайрак килеп чыкты. Закон проектларын бер бирәбез, бер алабыз. Законнарны бер кабул итәбез, бер юкка чыгарабыз. Бер сессиядә бер төрле сүз сөйлибез, икенче сессиядә — бөтенләй киресен...

Мин бүген әлеге законнарның сәяси әһәмияте турында, аларның мөһимлеге, ашыгыч рәвештә кабул ителергә тиешлекләре турында сөйләп тормыйм. Аларын барыбыз да белеп, күреп тора. Ни өчен шулай ашыкканлыгыбыз да мәгълүм. Хәзер кагылачак проблемалар, беренче карашка, бик тә гади. Һәм аларның дәүләткүләм әһәмияте ул кадәр юк та шикелле. Кайберәүләрнең: «Подумаешь, авыл исемнәре!» — диюләре дә бар. Әмма юкка гына. Мәсьәләләр бик тә җитди һәм аларны ничек булса да кичекмәстән хәл итәргә кирәк.

Беренче проблема. Авылларның статуслары яисә аталышлары турында. Хикмәт шунда ки, рус телендә авыл атамаларының берничә төре бар. *Село, деревня, поселок, поселение, хутор, слобода* һәм башкалар. Әйдәгез, сүзлекләргә мөрәҗәгать итеп карыйк. Ожегов сүзлегендә болай диелгән:

*Село* — большое крестьянское селение. *Деревня* — крестьянское селение. *Деревенька, деревушка* дигән сүзләре дә бар. *Поселок* — поселение городского типа. *Хутор* — 1.Обособленный земельный участок с усадьбой владельца. 2. Крестьянский поселок, обычно небольшой. *Поселение* — 1. Населенный пункт, а также вообще место, где кто-нибудь живет, обитает. 2. Принудительное водворение на жительство на отдаленном месте наказание за что-нибудь.

Даль сүзлегендә: *село* — обустроенное и заселенное крестьянами место, в коем есть церковь. *Деревня* — крестьянское селенье, в котором нет церкви. *Хутор* — усадьба, отдельный дом, со скотом и сельским хозяйством. *Поселок* — небольшая деревенька, деревушка.

«Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә: *авыл* — авыл хуҗалыгы белән шөгыльләнүче халык яши торган урын, торак пункт. Анда да пункт сүзенең татарчасын эзләп маташмаганнар. *Хутор* — 1. чәчүлек җире, йорт-каралтылары белән бергә аерым бер хуҗага караган крестьян хуҗалыгы. 2. Россиянең көньягында һәм Украинада кечкенә авыл. *Поселок* — гадәттә шәһәр яки зуррак авыл тирәсендә урнашкан, шәһәр тибындагы зур авыл. Монысы, гомумән, бернинди кысаларга да сыя торган түгел. Зуррак авыл тирәсенә урнашкан зур авыл килеп чыккан.

Күрәсез, сүзлекләрнең үзләрендә дә бертөрлелек юк. Без тикшерә торган документлар белән танышып чыкканнан соң да бик күп сораулар туа. Әгәр дә чиркәүле яисә мәчетле авылларны *село* дип санасак, без элекке *деревня*ларны да рәсми рәвештә *село*-га әйләндерергә тиеш булабыз. Ни өчен дисәң, соңгы ун-унбиш елда гына да меңләгән авыллар чиркәүле һәм мәчетле булды. Һәм, киресенчә, элекке мәчетле һәм чиркәүле бик күп авыллар кечерәеп беттеләр, бетеп баручы авыллар рәтенә күчтеләр. Күп авылларда китапханәләр, медицина пунктлары бетерелде. Аларны нәрсә дип атарга? Берничә генә хуҗалыгы калган авыллар бар. Алар белән нишләргә? Тагын әллә күпме аңлашылмаучылыкларны санарга булыр иде. Кыскасы, күп документларда *село, деревня* һәм *поселок* төшенчәләре шактый очракта чынбарлыкка туры килми. Үзем белгән Актаныш районы буенча гына да шактый гына мисаллар китерергә мөмкин булыр иде. Әйтик, Сөн буенда Кәзкәй, Аеш,

Тыңламас авыллары бар. Зурлыклары буенча өчесе дә бер чама. Шуңа да карамастан Аеш белән Кәзкәй — село, ә Тыңламас — деревня. 46 хуҗалыгы булган, 153 кеше яшәгән Чишмә авылы — село, ә 72 хуҗалыгы, 268 кешесе булган Меңнәр, киресенчә, деревня гына икән. 22 хуҗалыклы, 68 кешеле Михайловка да — поселок, 354 хуҗалыклы, 1033 кешеле Киров та — поселок. Ә Киров авылының документлардагы тулы рәсми язылышы менә болай: «поселок совхоза имени Кирова». Комитет утырышында шушы мәсьәләне карaганда депутат В.Н.Бударин да аптырап утырган иде. «Вообще-то я родился и вырос в деревне Гильдеево Пестречинского района, но в проекте закона написано почему-то село Гильдеево» дип сорау да биргән иде. Әмма ул үзенең соравына аңлаешлы җавап ала алмады. Закон проектларын эшләүчеләр бөтен мәгълүматларны да Статистика буенча Дәүләт комитетыннан алуларын әйтәләр. Статкомитет, үз чиратында, «Татарстан Республикасының административ-территориаль бүленеше» (1992) исемле китаптан алган. Ул исә күптән инде искергән, аны, һичшиксез, үзгәртергә вакыт. Әмма бу үтә дә катлаулы һәм вакыт сорый торган проблема. Биредә мин җитәкләгән Татарстан законнарының татар һәм рус телләрендәге текстларын тәңгәлләштерү комиссиясе турында сүз чыкты. Без авыл исемнәренең үз белдегебез белән бер генә хәрефенә дә кагыла алмыйбыз. Без русча язылган, русча кабул ителгән законнарның татар телендәгеләре белән тәңгәллеген генә тикшерәбез. Әгәр авылларының исемнәре ошамый икән, йә булмаса бозып языла дип исәплиләр икән, үзгәртәселәре килә икән, иң элек, авыл халкы үзе бер фикергә килергә, ягъни референдум уздырырга, җыен җыярга тиеш. Аннары гына район советы карар кабул итә. Ул документлар Дәүләт Советына килеп керә. Иң мөһиме, боларның барысына да федераль хакимиятнең рөхсәте кирәк булачак. Анысы инде үзе бер озын-озакка сузыла торган тарих. Ә инде үзгәртергә керешсәк, һичшиксез, архив документларына мөрәҗәгать итәргә тиеш булачакбыз. Иманым камил, ул бозылган исемнәр белән әлеге авыллар гасыр буе яшиләр. Аннары шул бозып язылган авыл исемнәре меңләгән кешеләрнең документларында — туу турындагы таныклыкларында, паспортларында, хәрби билетларында,

пенсия кенәгәләрендә теркәлгән. Аларын ничек итеп үзгәртеп бетерергә? Бу бит әллә күпме көч, вакыт, әллә күпме уңайсызлыклар тудыра торган әйбер. Күрәсез, хәтта үзгәрешләр кертелгән очракта да, аның тискәре нәтиҗәләре булмый калмас, дип уйлыйм.

Комитет утырышында чыгыш ясаганда юстиция министры М. М. Курманов республика авыл-шәһәрләренең исемнәренә, аларның язылышларына ревизия ясау турында сүз кузгаткан иде. Алда санап киткән кыенлыкларга да карамастан, мин аның белән тулысынча килешәм. Бу өлкәдә реформа ясамыйча һич тә ярамый. *Село* нинди, *авыл* нинди булырга тиеш? Кайсысында чама белән күпме кеше булырга тиеш? Мәктәп, клуб, кибет, китапханә, җирле үзидарә, почта, медицина пункты кебек оешмалар да булу шартмы? Кыскасы, ниндидер бер положение яисә закон кабул иткәндә дә начар булмас иде.

Икенче проблема татар авылларының татарча әйтелешләренә, язылышларына кагыла. Без бу хакта беләбез, борчылабыз, зарланабыз. Әмма шуннан ары киткәнебез юк. Мин биредә бигрәк тә гап-гади татар авылларын русча язганда *-ово*, *-ево* кушымчаларын өстәү турында әйтәм. Татар авылларының бер өлеше русча язылганда үзгәрешсез языла. Әйтик, Актаныш, Мамадыш... Ә менә кайберләре рус транскрипциясе белән язылганда, ни өчендер, үзгәрә дә куя. Мәсәлән, Кайбыч — Кайбицы, Питрәч — Пестрецы, Кукмара — Кукмор... Аларын да карап чыгарга кирәк. Мәсәлән, Актанышта зур Пучы авылы бар. Аның русчасы ни өчендер Поисево дип атала. Һич югы Пучино яисә Пучеево да димәгәннәр. Нәрсәгә таянып шулай бозганнар аны? Беркем белми. Руслар Пучы дип әйтә алмыйлармы? Әйтә алалар, әлбәттә. Һәрхәлдә, бу тәрҗемә рус грамматикасына нигезләнеп эшләнгәндер дип уйламыйм. Киресенчә, аны заманында берәр надан писарь шулай дип язган яисә Таҗи Гыйззәтнең «Ташкыннар» спектаклендәге русча белмәүче старостаның «эше» бу. Шулай булмаса, Балтачны бер районда Балтаси дип, икенчесендә Балтачево дип, Аккүзне бер төбәктә Аккузево дип, икенче бер җирдә Аккузино дип тәрҗемә итмәсләр иде. Кайбер авылларның татарча исемнәрен, гомумән, русчага тәрҗемә иткәнбез: Биектау — Высокая Гора, Чүпрәле —

Дрожжаное, Балык Бистәсе — Рыбная Слобода... Шунысы кызык: авыл исемнәрен руслаштыру фәкать безнең Татарстанда гына икән. Марий Элга чыгасың, юл күрсәткечләренә мари авыллары бер бозылмыйча марича язылган, чувашларга чыгасың, шул ук хәл. Хәтта күрше Башкортстанда да, бәлки, игътибар итүчеләр бардыр, хәзер татар, башкорт авылларын койрыксыз яза башлаганнар. Мин махсус Удмурт Республикасының картасы белән танышып чыктым. Удмурт авылларының һәммәсе дә үзләренчә язылган. Можга, Сарапул, Алнаши, Кизнер, Якшур Бодья, Какмош... Бары тик татар һәм рус авыллары гына биредә дә койрыклы: Троеглазово, Атабаево, Данилово, Сабанчино һ.б. Моның белән кем дә булса шөгыльләнергә тиештер бит? Лингвистлар, тел галимнәре...Әмма без телгә кагылышлы мәсьәләгә килеп кагылсак, уттан курыккан кебек куркабыз.

Өченчесе — тәрҗемә проблемасы. Закон проектларында *авыл — сала* дип бирелгән. Дөрес, татарда андый сүз бар. Әмма ул иске сүз, ул сирәк кенә, элекке әдәби текстларда гына кулланылган. Бу, миңа калса, бәхәсле тәрҗемә. Алай гына да түгел, ул русның *село*сын *сала* дип бозып кына әйтү. Бездә авыл сүзе генә бар. Безнең татарда, ни өчендер, село да, деревняда да, хутор да, поселок та авыл дип кенә йөртелә. Без бүген карый торган әлеге закон проектларына өр-яңа төшенчә — *поселение* сүзе килеп керә. Монысы инде гади авыл гына түгел, ә административ-территория берәмлеге. Кайберәүләр татарча да *поселение* булып калсын диләр. Миңа калса, бу сүзне, һичшиксез, татарчага тәрҗемә итәргә кирәк. Бәлки, элекке төрки телдә яисә хәзерге берәр башка төрки телдә бардыр аның матур тәрҗемәсе? Эзләргә, табарга, һич югы уйлап чыгарырга кирәк. Әгәр дә таба алмыйбыз икән, законнарның татарчасында, аннары инде кулланылышта да *поселение* булып китәчәк.

Мондый очракта әлеге җитди проблемаларны тәрҗемәчеләр җилкәсенә генә аударып калдыру, шулай ук, дөрес булмас иде. Гомумән, бездә татар терминологиясе бөтенләй эшләнмәгән дигән тәэсир кала. Кем ничек булдыра ала, шулай тәрҗемә итә. Шуңа күрә төрлелек килеп чыга. Кичекмәстән республикада термино-

логия комиссиясен оештырырга, яисә ниндидер даими эшләүче лингвистик үзәк булдырырга вакыт. Аның карарларын Министрлар Кабинетындамы, Дәүләт Советындамы раслау да мәҗбүри булырга тиеш дип уйлыйм.

Кемнәрдер минем әлеге тәкъдимнәремә кул гына селтәргә мөмкин. Янәсе, ярар, моңа кадәр яшәдек бит әле, берни дә булмады. Янәсе, өйрәндек, күнектек бит инде. Шулай, без бик күп әйберләргә күнеккәнбез. Дәүләтсез яшәргә дә күнектек, телсез яшәргә дә күнектек. Тагын бик күп әйберләргә күнегеп киләбез. Күнекмәскә кирәк! Күнегү — куркыныч әйбер!

*2005*

## ЯҢА ДӘРЕСЛЕКЛӘР КИРӘК!

Моннан берничә ел элек Бауман урамындагы китап кибетендә бер сәер китап кулыма килеп эләкте. 10—11 сыйныфлар өчен «Татар әдәбияты» иде ул. Авторы — А.Ж.Җәлалова. Маңгаена «Рус телендә урта гомуми белем бирүче мәктәпнең 10—11 нче сыйныфлары өчен хрестоматия» дип язылган. Җәяләр эченә «рус телендә сөйләшүче балалар өчен» дип тә өстәлгән. Ниндидер яңа дәреслек бу! Татар әдәбияты буенча мондый китапны күргән юк иде әле. Аяк өсте генә актарып чыктым, эчтәлегенә игътибар иттем. 78 биткә әллә күпме автор кертелгән, хәтта бер роман, берничә повесть, ике пьеса, исәпсез-сансыз поэма-шигырьләр сыйган. Күренеп тора, гади китап кына түгел бу. Үземнең исем-фамилиямне дә күргәч, 37 сумымны кызганмыйча сатып алдым мин моны. Өйгә кайткач, иркенләбрәк, җентекләбрәк укый башладым. Күзләрем маңгаема менде дисәм, бик үк дөрес булмас. Әмма гаҗәпләнүемнең иге-чиге булмады. Начар дәреслекләрне, уку китапларын күп күргәнем булды, әмма мондыен ук очратканым юк иде әле.

Беренчедән, анда орфографик, стилистик хаталар тулып ята. Нокта, өтерләрне әйтеп тә торыйм. Алары — бихисап. Язучылар, шагыйрьләр турындагы белешмәләр билгеле бер системага салынмаган, бәяләр дөрес бирелмәгән, титуллары, дәрәҗәләре, бүләкләре буталып беткән. Мәсәлән, Муса Җәлилнең Советлар Союзы Ге-

рое булуы бөтенләй искә алынмаган, Шәүкәт Галиевнең Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, Андерсен исемендәге Халыкара бүләк иясе булуы да, Татарстанның халык шагыйре икәнлеге дә әйтелмәгән. Ә менә Хәсән Туфан, киресенчә, Татарстанның халык шагыйре диелгән. Гәрчә Хәсән Туфан бу мактаулы исемгә бик тә лаек булса да, ул исән чакта әлеге исем рәсми рәвештә бирелми иде әле. Әмирхан Еники сатира-юмор остасы дигән бәяләмә дә хакыйкатькә туры килеп бетми. Бер урында «татар халкының классик шагыйре», икенчесендә — «татар әдәбиятының классик язучысы»... «Татар әдәбиятының классик шагыйре Һади Хәйрулла улы Такташев» дип әйтү дә бик үк күңелгә ятышлы түгел. Беркем дә алай дип сөйләшми. Шагыйрь Һади Такташ бар. Ә инде аның тулы исем-фамилиясен башка урында, башкачарак аңлатырга кирәк иде. Кайбер язучы-шагыйрьләргә, мәсәлән, Мирсәй Әмиргә, Фатих Әмирханга, Илдар Юзеевка, Габдрахман Әпсәләмовка, Каюм Насыйрига, Абдулла Алишка биографик белешмәләр бөтенләй бирелмәгән. Китапка тик торганнан ике тәрҗемә шигырь кертелгән: берсе — Илгиз Кәлимуллинныкы, икенчесе — чуваш шагыйре Василий Давыдов-Анатриныкы. Ни максат белән бирелгәнлеге аңлашылып бетми, тәрҗемәчесе дә күрсәтелмәгән. Әсәрдән соң бирелгән сүзлекләрнең дә ата-анасы юк... Кыскасы, бу бернинди кысаларга да сыймый торган бер халтура.

Мин бу хакта заманында Мәгариф министрына да хат яздым. «Корректорларның гаебе белән кайбер хаталар киткән шул» дигәнрәк җавап та алдым. Күрәсезме, мескен шул корректорларда икән бит бөтен хикмәт. Автор да гаепле түгел, министрлык та, нәшрият та, нәшриятта эшләүче мөхәррирләр дә... Мондый җавапсызлыкны минем күргәнем юк иде әле. Ә бит китапның тышына зур хәрефләр белән «Эксперимент» дип язылган. Эчке биттә исә татарча «Татарстан Республикасы Мәгариф министрлыгы рөхсәте белән сынап карау өчен бастырыла» дип, ә китапның ахырында рус телендә «Экспериментальное пособие-хрестоматия для 10—11 классов средней общеобразовательной школы с русским языком обучения (для русскоязычных учашихся)» дип тә акка кара белән язылып куелган. Рус телле балаларга ярамаган тагы,

алар барыбер татарча белмиләр, дип уйлаганнардыр ахры, министрлыктагы иптәшләр. Бу сериядән башка сыйныфлар өчен дә китаплар чыккан. Мин инде аларын, бөтенләй кәеф китмәсен дип, укып та тормадым.

Юк, мондый экспериментлар безгә кирәкми. Гомумән, «Хәтер» нәшрияты мондый халтураларны шактый еш чыгара. Әмма сүз әйтүче күренми. Бәлки, без белмәгән берәр сәбәбе бардыр? Гомумән, укучылар белән мондый экспериментлар уздыру, әхлаксызлык. Бу — әдәбиятыбызны, тарихыбызны, халкыбызны санга сукмау дигән сүз.

Бөтен бәла, минемчә, мәктәп программаларыннан башлана. Аларның авторлары — билгесез. Аларны, мөгаен, белемсез, әдәбиятны аңламаган, әйбәт язучыны уртакулдан аера белмәгән чиновниклар төзидер дигән тәэсир кала. Шулай булмаса, программаларга талантлы әдипләр белән беррәттән, үз сүзе, үз йөзе булмаган талантсызлар да килеп кермәс иде, хәтта классик язучыларыбызның да бик үк уңышлы булмаган әсәрләре кереп китмәс иде. Ә дәреслекләр фәкать әзер программа буенча гына языла. Бу — дәреслек авторларына иҗади эшләргә мөмкинлек бирми. Дәреслекләрне, уку китапларын, хрестоматияләрне теләсә кем язарга тиеш түгел.

Аннары тагын бер куркыныч әйбер бар. Ул да булса, төбәкләрдә дәреслекләр чыгару белән шөгыльләнү. Бу бигрәк тә Чаллыда киң таралган. Хәзер Уфада татар теле һәм әдәбияты буенча яңа дәреслекләр чыгару башланды. Себердә дә шундый ук хәл күзәтелә. Бу, беренче карашка, хупланырга гына тиеш кебек. Ни дисәң дә, белгечләр җәлеп ителә, тәҗрибә туплана, яңа методикалар, яңа алымнар сынап карала. Әмма да ләкин әдәби материалның сыйфаты югала, шул төбәкләрдә яшәүче язучы-шагыйрьләрнең иҗатына ныграк басым ясала, төбәкчелек тенденцияләре өстенлек итә башлый. Нәтиҗәдә шактый гына классик әдипләребезнең, бүгенге күренекле язучы-шагыйрьләребезнең иҗатлары бер читтәрәк кала. Мин, әлбәттә, укытучыларыбызның төбәкчелек хисен яхшы аңлыйм. Алар үз төбәкләренең әдипләрен яраталар, иҗатларын үз дәресләрендә яратып файдаланалар. Ләкин ул әдипләрнең

иҗатларын, күбесенчә, дәрестән тыш та өйрәнеп булыр иде. Күп укытучылар шулай эшли дә.

Мине бигрәк тә нык борчыганы — рус мәктәпләре өчен чыгарылган китаплар. Дөресен әйтим, аларның күбесе рус мәктәпләрендә укучы, татар телен начар белүче балаларны истә тотып язылмаган. Укытучыларның бөтенесе дә диярлек «бу дәреслекләр белән балаларны укытып булмый» дип зар елыйлар. Чыннан да, хәзер инде яңа караш, яңа укыту методикасы кирәк.

Нишләргә соң? Иң элек, дәреслекләр язуны, аларны бастырып чыгаруны җайга салу буенча, кичекмәстән, ниндидер яңа бер комиссия төзергә, ул комиссиягә абруйлы педагогларны, галимнәрне, әдипләрне сайлап алырга кирәк. Башта булган дәреслекләргә төпле анализ ясарга, аннары мәктәп программаларын карап чыгарга, яңа дәреслекләр төзүнең яңа методикасын, механизмнарын уйларга кирәк. Шунсыз безнең бер эшебез дә барып чыкмаячак.

*2006*

## НИ ХӘЛДӘ СИН, ТУГАН ТЕЛ?..

Туган телнең тәме китте, бәясе төште, кадере бетте. Милләтләрнең, бигрәк тә татарның, туган теленә исе китми башлады. Бу куркыныч күренеш күптән күзәтелә инде: совет чорыннан ук. Үз туган телен санга сукмаучы, аңа төкереп карауучы, аның бар икәнен дә белмәүче берничә буын үсте. Туган телне куллану даирәсе кечерәйгәннән-кечерәя. Татар теле — урам теле, кухня теле, диярга яратабыз. Гаилә теле, урам теле булса ярар иде әле ул. Ни кызганыч, хәзер инде өйдә дә башка чит телдә сөйләшү гадәти бер күренешкә әйләнеп бара. Мин аның хәтта нинди тел икәнен дә әйтә алмыйм. Әгәр дә радио-телевидение тапшыруларын игътибар беләнрәк тыңласаң, җитәкче иптәшләрнең чыгышларына колак салсаң, гаҗәп «ачышлар»га тап буласың. Ниндидер бер җыелма телдә сөйләшергә күнегеп барабыз икән бит. Казан тапшыруларында, нигездә, берьюлы татарча-русча сөйләшү гадәти бер күренеш төсен алды. Мисаллар китерә башласаң, колакларың үрә торырлык! Өстәвенә әле чит телләрдән кергән яңа терминнар

да кушып җибәрсәләр, бөтенләй кишмиш тел килеп чыга. Менә болар инде телләр турындагы законны үтиләр дә үтиләр. Берьюлы ике дәүләт телендә сиптерәләр. Уфа тапшыруларын карaганда да шул ук хәлгә тап буласың. Биредә инде рус-татар теленә башкорт телен дә китереп кушалар. Әйбәт кенә татарча башлап җибәрәләр, берничә җөмләдән башкортча сүзләр кыстырып куялар, аннары рус сүзләре белән «бизәкләп» дәвам итәләр. Бу гади авыл яки шәһәр халкына гына карамый. Күбебез шушы корама телдә сөйләшәбез. Чыгарма буларак, татар теле һәм әдәбияты укытучыларын мисалга китерергә буладыр, мөгаен. Бигрәк тә өлкән буын укытучылары дөрес, матур, бай әдәби телдә сөйли торганнар иде. Калганнарыбыз барыбыз да диярлек бер иш.

Безнең сөйләм культурабыз бетеп бара. Өйдә өйрәтмиләр, мәктәптә, вузда укытмыйлар. Хәтта актёрлар әзерләүче махсус уку йортларыннан да ниндидер бер ясалма интонация белән, татар теленә ят бер шәһәр акценты белән сөйләргә өйрәнеп чыгалар. Ялган пафос ярылып ята, табигыйлек, авыл сөйләшенә хас сыгылмалылык, ягымлылык җитми. Радио-телевидение дикторларын юри генә тыңлап карагыз әле: дөрес итеп җөмлә дә төзи белмиләр, кирәк урынга басым да куя алмый интегәләр. Мин моннан ун-унбиш еллар элек Казан телевидениесеннән «Ихлас» исемле тапшырулар циклы алып барган идем. Тапшыруымда күренекле дәүләт эшлеклеләре, генераль директорлар, аксакал язучыларыбыз катнашты. Бик мактадылар. «Кара әле, безнең җитәкчеләребез ничек матур итеп татарча сөйләшәләр икән»,— дип сокландылар. Шактый еллар узганнан соң, мин ул сөйләшүләрне, матбугатка бирермен дип, кәгазьгә төшерергә булдым. Һәм исләрем китте. Ә.Еники белән Г.Бәшировны искә алмаганда, әңгәмәләрнең берсен дә болай гына матбугатта бастырырлык түгел иде. Бер генә төзек, бөтен җөмлә дә тапмассың, татарчаларының ата-анасы юк...

Телебезнең аһәңе, ана сөте белән кергән моңы эреп юкка чыга бара. Хәзер авылларда да, элекке кебек, сүзнең тәмен тоеп, әйтемнәр-мәкальләр кушып сөйләшүче аксакаллар, акъәбиләр бетеп бара. Газета теле белән, информация теле белән аңлаша башладык. Әлбәттә, бик матур итеп, җиренә җиткереп сөйләшүчеләр

дә бар. Әмма әлеге сүзем алар хакында түгел, тел белмәүчеләр, сөйләшә белмәүчеләр хакында.

Элекке райком, партком секретарьларын, колхоз рәисләрен, бригадирларны, белгечләрне искә төшерегез. Ике җөмләне кушып әйтә алмый торганнар иде аларның күбесе. Хәзер дә шулай. Үзләре акыллы гына, фикерле генә кешеләр. Ә менә сөйләү куәләре ташка үлчим генә. Халык алдында сөйли белү юк, халык белән сөйләшә белү осталыгы җитми. Ни өчен безнең милләттән сәясәтчеләр, милләтчеләр, җәмәгать эшлеклеләре арасыннан ялкынланып чыгыш ясый алучы ораторлар сирәк? Моның төп сәбәбе,— әлбәттә, аларның телне белмәүләрендә, сөйли белмәүләрендә, фикерләрен кешеләргә матур итеп җиткерә белмәүләрендә. Русчалары да юк, татарчалары да. Икесен бергә кушып сөйләсәләр дә юк. Аларның сөйләгәннәрен тыңлаганда, җир тишегенә кереп китәрдәй буласың. Җан кебек газиз телебезне вата-сындыра нидер әйтә башласалар, күңелне гарьләнү хисе биләп ала. Хәтта язып бирелгән текстларны да матур итеп, саф татарча итеп укый алмыйлар. Югыйсә күзгә-күз карап әңгәмәләшкәндә, табын артында дөнья хәлләре турында гәп корганда ярыйсы гына сөйләшәләр төсле үзләре...

Аннары уйлап та куясың: бүгенгеләре, күпме генә сүксәк тә, ярый әле. Дөресме-түгелме, әйбәтме-начармы, сөйләргә тырышалар. Ә бит хәзер хакимияткә, сәясәткә, тормышның башка тармакларына татар мәктәпләрендә бөтенләй укымаган, татар әдәбиятын тамчы да белмәгән, белергә дә теләмәгән, бүген чыга торган татарча матбугатны кулына да тотып карамаган, күңелендә татарлыкның эзе дә булмаган «милләттәшләр» килә. Алар татарча вата-җимерә дә сөйләшә алмыйлар, аларның гаилә теле дә, эш теле дә, аралашу теле дә, сүгенү теле дә — рус теле. Бәлки, шулай әйбәтрәктер дә әле? Ичмасам, телебезне, санга сукмасалар да, гарипләндермиләр, ботарламыйлар, рәнҗетмиләр. Мин бу сүзләрне аптыраганнан гына әйтәм, билгеле...

* * *

Татар әдәби теле күбрәк Казан арты сөйләшенә нигезләнгән. Хәзер инде ул барыбызга да аңлашыла. Бүгенге әдәбиятыбыз

да, үзара аралашуларыбыз да, уку-язуыбыз да билгеле бер әдәби кысаларга көйләнгән. Ләкин күпгасырлык бай тарихы булган, меңьеллык әдәбияты, әдәби ядкәрләре булган, әле кайчан гына бөтен төрки телләр дә җиңел аңлый алырлык китап, матбугат теле булган бөек татар телен, билгеле инде, әдәби тел кысаларына гына сыйдырып булмый. Төрле төбәкләрдә чәчелеп яшәүче татарларның һәркайсы көндәлек тормышта үзара үз төбәгенең телендә сөйләшә. Татар теленең һәр диалекты, һәр сөйләше үзенчә матур. Андагы кабатланмас сүз байлыгының иге-чиге юк, андагы күңелгә якын интонацияләр — төрледән-төрле, серледән-серле. Алар — буыннан-буынга күчеп килгән энҗе бөртекләре. Аларның берсе дә эзсез югалмаска, телебездән җуелмаска тиеш. Әмма шуны онытмыйк: йөргән таш кына шомарган шикелле, сөйләнгән сүз генә, хәрәкәттәге, әйләнештәге сүз генә яши. Шуңа күрә дә, әдәби тел түгел дип, үз төбәгеңнең телендә сөйләшүдән оялмаска кирәк. Әбибабаң, әти-әниең, туган-тумачаларың, авылдашларың сөйләшкән тел бит ул. Бала чагың теле, туган авылың теле! Мин үзем дә, әдәби телдә сөйләшергә өйрәнсәм дә, әдәби телне бөтен нечкәлекләре белән үзләштерсәм дә, үзебезнең як сөйләшен бер генә минутка да онытканым юк. Тырышсаң да онытып булмыйдыр аны. Ул безнең каныбызга, аңыбызга, җаныбызга сеңгән. Шуңа күрә, кая гына барсам да, авызымны ачу белән: «Әллә син Актаныш ягыннанмы?» — дип сорыйлар. Димәк, авыллык, үзебезнең як сөйләше барыбер калган, барыбер чыгып бетмәгән. Хәер, туган җирдән, якташлардан, аның теленнән аерылган да юк бит. Җитмәсә, җәмәгатем дә үзебезнең якныкы. Ул, гомумән, әлегә кадәр өйдә генә түгел, кеше арасында да Илешчә генә сөйләшә. Өйгә кайтып керү белән икебез дә үзебезчәгә күчәбез. Азмы-күпме авыл тәрбиясе алган балаларыбыз да безгә кушылып китә. Хәтта мишәр киленебез дә үзара сөйләшкәндә «нәмә», «кирәкмәй», «белмәем»гә күчеп бара. Үзебезчә сөйләшкәндә авыл сагындыра, кемнең ничек сөйләве, кемнең нинди гыйбарәләр, әйтем-мәкальләр әйтүе искә төшә. Чөнки безнең авылда гына кулланыла торган, Әнкәй генә әйтә торган әллә нинди серле дә, тапкыр да сүзләр, әйтемнәр бар бит алар арасында. Әгәр безне читтән тыңлап торсалар апты-

рарлар иде бугай. Авылга кайтсам да шулай. Әдәби телебез ни өчендер үзеннән-үзе онытыла да куя. Әнкәй белән, авылдашлар белән арчалар кебек «миңга», «синга» дип, «әчкеч», «и тушыны» дип сөйләшеп утыра алмыйм бит инде. Студент чакларда Казанча да сөйләшкән булды анысы. Соңыннан: «Гөлҗәүһәрнең олы малае кылтаеп сөйләшергә өйрәнгән», — дип сөйләп йөргәннәр.

Гомумән, телнең диалектларын ничек кенә булса да саклап калырга кирәк. Бу өлкәдә күпмедер эш эшләнә дә инде. Әйтик, күп кенә әдипләребез диалекталь сүзләрне үз әсәрләрендә киң файдаланырга тырыша, журналистларыбыз да урындагы сүзләрне киң куллана. Галимнәребез фәнни эзләнү эшләре алып бара: фәнни экспедицияләр оештырыла, симпозиумнар үткәрелә, хезмәтләр языла, сүзлекләр чыга. Сүз дә юк, боларның һәммәсе дә бик мөһим. Әмма, минемчә, иң мөһиме: һәрбер диалект сөйләм теле булудан туктамаска тиеш. Әгәр дә мишәрләр дә, Әстерхан, Себер, Башкортстан татарлары да үз сөйләм телләрен югалтсалар, фәкать китапча гына сөйләшә башласалар, бөек татар теле шунда ук саегачак, сыегаячак, үзенең бөеклеген югалтачак.

Шөкер, әлегә һәркем үзенчә сөйләшә. Корылтайларга җыелганда дөньяның төрле кыйтгаларыннан килгән төрледән-төрле татарларыбызның гәпләшкәннәрен, чыгыш ясаганнарын тыңлап торасың да исләрең китә. Нинди генә аһәңнәр, нинди генә сүзләр, нинди генә сөйләмнәр ишетмисең анда. Барысы да якын, барысы да аңлашыла, барысы да үзебезнеке!

* * *

Әмма икенче бер процесс та үзен нык сиздерә: татар кайсы халык арасында яшәсә, шуның теленә күнегә, шул халык теленең тәэсиренә бирешә. Сөйләшкәндә, үзе дә сизмәстән, туган телен шул тел белән бутап сөйли башлый. Рус сүзләре кушып сөйләшүне мин инде әйтеп тә тормыйм. Беренче очракны җирле халык белән аралашу, аңлашу мохтаҗлыгыннан дип аңлатырга була. Бу — чыннан да шулай. Бигрәк тә төрки халыклар белән аралашканда. Рус теленең тәэсирен дә читкә кагып булмый. Гади сөйләм телендә без аны әйткәннәребезнең тәэсир итү көчен арттыру өчен, уенын-

чынын бергә кушып, юри генә шаяртып та кертеп җибәрәбез. Әйтик, Атнабай үзенең шигырьләрендә махсус шундый рустан кергән халыкчан сүзләрне бик оста итеп файдалана иде. Ә.Еники сөйләшкәндә «значит» сүзен еш куллана иде, А.Гыйләҗев башкалар белән әңгәмәләшкәндә «парин» дип кабатларга ярата иде. «Пожалысты», «что син», «так что», «конечно», «обязательно» кебек рус сүзләренең татарчалаштырылган вариантларын барыбыз да диярлек куллана. Тел очына килеп торалар бит, чукындырасыңмыни аларны. Рус сүзләре драматурглар, юмористлар өчен бигрәк тә хәзинә инде ул бездә. Рәхәтләнәләр генә русча сүзләр кыстырып.

Күптән түгел Алматы шәһәрендә булырга туры килде. Анда яшәүче өлкән яшьтәге татарларыбызның телләре шактый казахлашкан икән: күп очракта ярымтатарча-ярымказахча сөйләшәләр. Кытайдан кайткан татарларда исә уйгур теленең тәэсире бик нык сизелә, ә кайберләрендә элекке әдәби тел сакланып калган. Төркиядә яшәүче милләттәшләребезнең хәлләре дә шундый ук: аларның күбесе үзара төрекләшкән татар телендә аралашалар. Үзбәкстан, Кыргызстан, Азәрбайҗан мәмләкәтләрендә гомер кичерүчеләрдә дә шул ук хәл.

Күренә ки, төрки телләрнең охшаш булулары кайчагында тискәре роль дә уйнап куя. Башкортстанда яшәүче татарларыбызның сөйләшенә дә башкорт сүзләре кушып сөйләшү, сүзләрне башкортчалаштырыбрак әйтү гадәткә кергән. Ул гына да түгел, хәтта журналистларыбыз, әдипләребез дә башкорт сүзләрен бик яратып файдаланалар, һәм бу соңгы елларда кагыйдәгә әйләнеп китте.

Телебездә әнә шундый үзгәрешләр бара. Тел өлкәсендәге кызык та, кызганыч та бу күренешләрнең асылы киләчәктә фәнни яктан, һичшиксез, өйрәнелергә, җитди фәнни анализ ясалырга тиештер дип беләм.

* * *

Безнең ата-бабаларыбыз укымышлы булган, китап укыган, телләр белгән. Әмма, ни кызганыч, телләр өйрәнү, телләр белү хәзер зур проблемага әверелде. Совет чоры мәктәпләре күпме генә алга киткән булмасын, анда телләрне өйрәтү үз агышына куел-

ган иде. Авыл мәктәпләрендә безне рус теленә дә юньләп өйрәтүче булмады. Чит телләрне дә укыган булдык, тик бер авыз сүз дә әйтергә өйрәнә алмадык. Динебездән читләтелгәнлектән, Коръән телен дә белмичә үстек. Әллә кирәге булмаганга телләргә өйрәнеп булмады, әллә укытулары шул чама гына булган? Һәрхәлдә, татар телен өйрәтүнең прогрессив методикасы әлегә кадәр эшләнмәгән. Мәсәлән, рус мәктәпләрендә татар теленә өйрәтә торган дәреслекләрне кулга да тотарлык түгел. Ул дәреслекләр ярдәмендә татарчага өйрәнеп булмый, киресенчә, гайрәтең генә чигәргә мөмкин...

Шулай да, ничек кенә аяныч булмасын, тормыш үз көенә бара. Халыкларга барыбер аралашырга, аңлашырга кирәк. Телләрне белү ул — тормыш таләбе. Бергә аралашып яшәгән мари, чуваш, удмурт халыклары белән, әйтик, безнең бернинди дә проблемабыз юк. Катнаш авылларда, мәктәпләрдә бер-беребезнең телен яхшы аңлыйбыз, хәтта сөйләшә дә беләбез. Бигрәк тә өлкән буын вәкилләре шундый иде. Ә инде башкорт теле Башкортстан татарлары өчен үз телләре шикелле. Татарга да, башкортка да тылмач кирәкми. Мин менә бер класс башкортча укымаган килеш тә рәхәтләнеп башкорт телендәге китапларны, газета-журналларны кечкенәдән укып үстем. Теләсәм, сөйләшә беләм, теләсәм, яза да алам. Иң мөһиме, башкорт теленең аһәңе, моңы, мелодиясе якын миңа. Кайчакта хәтта башкортча шигырь дә язып карыйсы килә. Минем кебекләр Башкортстанда бихисап күп. Хәзер инде өлкән яшьтәге бер шагыйрьнең: «Башкорт телен мин, Роберт энем, башкортларның үзләреннән дә шәбрәк итеп өйрәндем!» — дигәне әле дә исемдә. Шулай булырга тиеш тә. Әгәр дә башка халык әдәбиятына хезмәт итәргә алынгансың икән, синең башка чараң юк. Тугандаш халыкларның телләрен белүче әдипләребезнең мин белгәннәре дә җитәрлек. Заманында үземнең дә чувашларның халык шагыйре Яков Ухсай белән берничә тапкыр саф татар телендә сөйләшеп торганым булды. Таһир ага Таһировның чувашча бик яхшы сөйләшкәнен беләбез. Чувашчаны безнең Ренат Харис белән Кави Латыйп су урынына эчә, Шәрәф Мөдәррис тә шундый иде: «Нарспи»ны ул оригиналдан тәрҗемә итте. Чувашларның бүгенге

халык шагыйрьләре Валери Тургай, Порфирий Афанасьев, Юрий Семендер шулай ук татарча шактый гына әйбәт сукалыйлар. Удмуртиянең халык язучысы, минем якын дустым Вячеслав Ар-Серги да телефоннан шалтырата башласа, татарча сөйләшеп җанга тия. Кирәк чакта марича, башкортча, чувашча сөйләшергә дә күп сорап тормый.

* * *

Телләр белмәү, аеруча үз туган телеңне өйрәнмәү бүгенге көндә зур кимчелек саналырга тиеш. Теләгән кеше өйрәнә дә, сөйләшә дә, файдалана да. Җүләр хатынын мактар, ди. Минем дә җәмәгатем Клара Әмир кызын мисалга китерәсем килә. Ул тумышы белән үзебезнең Югары Яркәйдән. Район үзәге кызы. Бер класс та татарча укымаган. Бөре педагогия институтында да рус филологиясе факультетында белем алды. Ягъни мәсәлән, рус теле һәм әдәбияты укытучысы. Казанга килгәч, башка эш булмау сәбәпле, «Татарстан коммунисты» журналы редакциясенә татар корректоры булып эшкә урнашырга мәҗбүр булды. Тәвәккәл дә булган инде үзе! Татарча минем хатлардан башканы укып та карамаган килеш шул эшкә алынсын әле! Еллар узды. Ул да чын профессионалга, татар теле белгеченә әйләнде. Хәзер «Татарстан» журналында җаваплы секретарь булып эшли, татарчаны миннән әйбәтрәк белә, югары белемле татар филологының, ягъни минем ялгышларны, хаталарны төзәтеп утыра. Тагын бер мисал. Төпчек энем Кимне, русча белсен дип, Әнкәй Югары Яркәй мәктәбендә, рус классында укытты. Сигезенчедән соң ул Казанга килеп һөнәр училищесында белем алды, солдат хезмәтендә булды. Һәм, минем киңәш белән, Казан университетының үзем укыган татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга барып керде. Шул егет хәзер филология фәннәре докторы. Татар гуманитар-педагогика университеты профессоры булды. Диссертацияләрен татар телендә язып яклады. Менә ничә еллар инде Татарстан Министрлар Кабинетында Телләрне үстерү бүлеген җитәкли, татар теле дәүләт теле булсын дип җан атып йөри.

Бу мисаллар белән минем шуны да ассызыклап әйтәсем килә: бөтен әйберне дә мактап кенә хәл итми. Күңелеңдә булмаса,

канында булмаса, гаиләңдә булмаса, сине бер мәктәп тә, бер генә дәреслек тә татар теленә өйрәтә алмый. Иманың булса, тоткан кыйблаң булса, ныклы нәсел-нәсәбең булса, ата-анаңа, әби-бабаңа тирән ихтирам булса, үз туган телеңне, әлбәттә, беләчәксең. Шул чагында гына син изге туган телең хозурында яшәячәксең: сине бу якты дөньяда каршы алган әткәң-әнкәңнең теле соңгы юлга да озатып калачак. Газиз әнкәң теле белән туып та ят кавем теле белән гомер сөрү, татар булып туып та бу фани дөньядан маңкорт булып китү, үз әнкәң белән дә үз телеңдә серләшә алмау, әнкәңнең сиңа: «Балам!» — дип дәшүен дә аңламау адәм баласы өчен зур фаҗига түгелмени? Фаҗиганең дә нинди әле?!

Безнең халык кызык бит ул: рус телен зур горурлык белән «икенче туган телем» дияргә ярата. Булмый гына торсын әле! Туган тел берәү генә, бердәнбер генә була. Әлбәттә, рус телен, дәүләт теле буларак, берсүзсез шәп итеп белергә кирәк. Ләкин икенче бер телне күпме генә әйбәт үзләштерсәң дә, ул барыбер үзеңнеке була алмый, ул — үги тел. Эш теле, аралашу теле, дипломатия теле, интернациональ тел булырга мөмкин, әмма анаң теле, милләтең теле түгел.

Әгәр дә бик беләсегез килсә, соңгы берничә дистә елларда үсеш алган азгынлык, әхлаксызлык, җинаятьчелек, фәхишәлек, пычраклык һәм илебездәге, халкыбыздагы тагын әллә никадәр җүнсезлекләр — барысы да, иң элек, телсезлектән, туган телеңне, димәк, милләтеңне, тарихыңны, рухыңны сатудан, фәкать башка телләрнең, димәк, башка милләтләрнең һәм аларның мәдәниятләренең колы булудан башлана. Үз телендә уйламаган, фикер йөртмәгән, үз телендә җырлый белмәгән, үз хисләрен үз телендә аңлата алмаган татарыбызга татарлык каян килсен? Татарча бишек җырлары тыңлап үсмәгән, татарча ата-ана тәрбиясе, татарча мәктәп тәрбиясе алмаган татарыбыз нигә әле үз милләте өчен тырышсын? Андыйлар бит олы туганыбыз йогынтысында үскән, аның тәрбиясен алган. Нишлисең, андыйларга олы туганның теле, аның рухы якынрак. Шуңа күрә дә андый милләттәшләребез, патша заманнарындагы кебек үк, әлеге дә баягы шул руска хезмәт итәргә мәҗбүр. Йә Хода, күпме бездә шундый

рус тәрбиясендә үскән татар балалары! Кызганыч, үзебез үзебезчә белем бирә алмагач, үзебезчә тәрбия кыла алмагачтын тәрбиягә, асрауга бирергә туры килә. Уллыкка, кызлыкка биргән кебек!

Бу дөньяда барысы да туган телдән, аның моңыннан башлана: милләтпәрвәрлек тә, ватанпәрвәрлек тә, ата-анаңа, туганнарыңа ихтирам да, туган җиреңә, туган туфрагыңа мәхәббәт тә...

*2006*

## ВНЕДРЕНИЕ РЕАЛЬНОГО ДВУЯЗЫЧИЯ

**Весьма сложный и длительный процесс...**

История появления в парламенте комиссии по идентификации текстов связана с тем, что в Татарстане два государственных языка и мы, соответственно, должны принимать законы как на русском, так и на татарском. Несколько созывов подряд шел разговор об этом, но как приступить к делу, никто не представлял. Переводить закон с одного языка на другой? Но ведь даже чисто литературный текст невозможно перевести без потери каких-то нюансов, а тут все же тексты законов, где, как говорится, каждая буква должна соответствовать, а не только все слова и их значения. Но и механически, подстрочно перевести текст невозможно, так как не всегда можно найти в татарском языке все соответствующие термины и понятия. Вставал вопрос: на каком языке изначально писать тексты законов, чтобы затем перевести их на второй государственный язык?

В составе парламента в основном русскоязычные депутаты, они не знают татарского, следовательно, не смогут голосовать за принятие закона, написанного на татарском. С татарами проще — они владеют обоими государственными языками и могут голосовать за законы в любом из вариантов. А как поступают в других парламентах? Оказалось, ни в одном субъекте Российской Федерации нет такой практики: везде законодательство идет на одном языке, даже если провозглашены два государственных языка.

В результате депутаты пришли к такому мнению: принимать законы надо по-прежнему на русском языке, а потом передавать

их комиссии по идентификации, которая берет на себя ответственность за текст закона на татарском языке. В составе этой комиссии, которую я возглавляю, несколько татароязычных депутатов, переводчики, лингвисты и эксперты. Наша задача — отслеживать, идентичны ли два текста закона.

Скажу, что это очень напряженная работа, в первую очередь, для переводчиков. По регламенту после принятия закона мы должны направить Президенту РТ оба текста в течение двух недель, поэтому время, отведенное на перевод и идентификацию текстов, очень сжато.

Процесс перевода приводит иногда к ошеломляющим открытиям. Например, когда возник вопрос о переиздании Конституции РТ (а она давно принята и переведена), члены комиссии, с пристрастием заново перечитав ее, пришли к неутешительным выводам. Оказалось, что некоторые статьи Основного закона переведены непрофессионально. Кроме того, за последнее десятилетие изменилось значение отдельных терминов, в языке появились их татарские варианты. Что же теперь делать? Пока ответа на этот вопрос нет. Юристы думают.

В переводческом деле много проблем, к тому же мы только учимся ему, если учесть, что тексты законов никогда ранее не переводились. В комиссии очень грамотные специалисты, но, бывает, и они встают в тупик. Например, проблема специальной терминологии, которой прежде никто не занимался. Между тем в нашу жизнь в последнее время вошло множество иностранных слов, аналогов которым нет ни в русском, ни в татарском языках. Не прикладывать же к каждому закону специальный толковый словарь. Депутаты в какой-то мере разбираются в них, но гражданам бывает сложно понять, что хотел сказать законодатель.

О том, сколь сложен процесс перевода законов, можно судить уже по тому, что даже между переводчиками постоянно случаются расхождения. Право законодательной инициативы имеют, кроме Государственного Совета, Президент и Кабинет Министров республики. Нередко переводчики из этих структур трактуют тот или иной термин иначе, чем в нашей комиссии. Приходится со-

гласовывать с ними все нюансы. Более того, даже между учеными, работающими в нашей комиссии, случаются разногласия.

Приведу лишь один пример. В период работы над законодательством по местному самоуправлению комиссия едва успевала за парламентариями — законов было принято множество. Столько же возникало и вопросов. К примеру, название города Набережные Челны. В законе на татарском языке написано «Чаллы», и все. А слово «Набережные» осталось, как говорится, за бортом. Татарская энциклопедия дает свой вариант: «Яр Чаллы». Схожая история со словом «Зеленодольск»: в татарском варианте закона это «Яшел Үзән», а в Конституции такого слова нет вообще!

Татарский язык развивается, как и любой другой, обогащаясь новыми словами, а в последние годы — возвращая в обиход забытые тюркские понятия. Это закономерный процесс. Скажем, в Турции, ради сохранения языка, еще в тридцатые годы прошлого столетия убрали из речи арабизмы. Если не было в языке адекватного термина, то просто заново придумывали свои. Люди привыкли к новым словам, и у турков получился хороший чистый язык. Хотя и там проблемы еще остались. Если татары, к примеру, нашли в своем языке аналоги привычных с советских времен слов «экономика», «культура», то у турок так и осталось — «экономика», «культура».

В начале девяностых годов прошлого столетия, случалось, татарский читатель жаловался, что газеты и журналы стало невозможно читать — уж очень много появилось в текстах арабизмов, смысла которых не понять без словаря. Мне кажется, это большая проблема. Между тем в начале двадцатого века литературная речь тюркских народов почти не отличалась друг от друга. Татарскую периодическую печать все читали и прекрасно понимали: и азербайджанцы, и казахи, и киргизы, и башкиры. В 1926 году на съезде тюркологов был рассмотрен вопрос о том, что у каждого народа должен быть все-таки свой литературный язык, отличающийся от языка сородичей. Постепенно так оно и произошло, и теперь мы уже плохо понимаем, к примеру, казахский или азербайджанский. Что же касается политических, юридических и экономических терминов, в основном они западного происхождения, и никуда от

этого не денешься. Русские ведь тоже почти не занимаются переводами иностранных слов. И я не берусь однозначно ответить на вопрос: надо ли это делать?

Когда мы принимаем экономические законы, утверждаем ежегодный бюджет, филологи хватаются за голову, пытаясь разобраться в специальных терминах. Все это говорит о том, что пришло время включиться в процесс ученым Академии наук РТ. Возможно, надо разработать общетюркские экономические термины (к слову, у казахов есть очень хорошие переводы, которые можно позаимствовать). Пока же у нас даже с соседями-татарами, которые проживают в Башкортостане, наблюдаются разночтения. Например, иначе, чем у нас, по-разному переводится слово «поселение» — кстати, и на русском оно вызывает ненужные для законов ассоциации.

Вообще, язык — очень тонкая вещь, у него свои законы. Институт языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова, конечно, занимается проблемами развития языка, но один он не в силах сделать татарский оригинальным языком. Есть вообще не решаемые вопросы. Загляните в русско-татарский словарь: едва ли не половину терминов в нем можно вымарать без ущерба. Трактор — это трактор, а комбайн — тоже комбайн! Да, собственно, и русский язык заимствовал это слово из английского.

Много споров было по поводу перехода татарского языка на латинскую графику. Немного остыв от дебатов, я пришел к выводу: хотя вопрос не прост, но не произошло бы ничего страшного, перейди мы на латиницу. Почему в Москве боятся этого перехода и превратили его в политический вопрос — не понимаю. Ведь пользоваться латиницей стало бы только татарское население, больше никому это не нужно. Русский язык, как государственный, остается, никто его в республике и не думает запрещать. Между тем все тюркские народы постепенно переходят на латиницу. К примеру, казахи перешли на нее в ноябре 2006 года указом своего президента.

Но даже если мы откажемся от латиницы, нам все равно придется реформировать орфографию татарского языка. Изучать наш язык на кириллице очень трудно, поскольку она приводит к искажению его звучания.

К сожалению, проблема реального двуязычия в республике пока, на мой взгляд, остается. Я помню времена, когда едва ли можно было найти дюжину депутатов, способных произнести публичную речь на татарском без бумажки. Те, кто владеет родным языком по-настоящему, старались выступать на татарском, но... нас никто не слушал, просто потому, что не понимали. Так что принципиально важные вещи, дабы донести их до сознания всего депутатского корпуса, приходилось озвучивать на русском языке.

Должно быть, порой наше упорство выглядело со стороны даже смешно. Но постепенно оно сделало свое дело. Чтобы поднять статус татарского, чтобы подать положительный пример, мы стали настаивать на том, чтобы председательствующий, хотя бы изредка, вел сессионные заседания попеременно на двух языках. Для нас было принципиально важным, чтобы татарская речь звучала в стенах Госсовета. Было трудно, но постепенно привыкли. Дело пошло веселей, когда внедрили синхронный перевод, и русскоязычные депутаты стали пользоваться наушниками. Я бывал во многих региональных представительных органах Российской Федерации и могу утверждать, что по сравнению с ними Татарстан значительно продвинул внедрение двуязычия. Парламентские заседания в национальных республиках идут исключительно на русском языке. Коллеги наши удивляются тому, что мы имеем возможность выступать на татарском и принимать документы на двух языках.

К сожалению, и у нас аппаратура, позволяющая использовать синхронный перевод, есть пока только в Государственном Совете. Пока она не появится везде, вряд ли в государственных учреждениях будет звучать татарская речь.

Внедрение реального двуязычия — это не единовременный акт, это весьма сложный и длительный процесс. Но надо двигать его и всегда помнить, что дорогу осилит идущий.

**...и о журналистах**

Наши средства массовой информации, особенно татароязычные, частенько ругают депутатов. Их возмущает, что коллеги не го-

ворят по-татарски. Да, на самом деле это так. Но они не задаются при этом вопросом: почему? Почему так сложно реализуется закон о двух государственных языках?

Вспомните, как было в столь неуважаемое прессой советское время. Нужно разобраться в проблеме? Пожалуйте — журналистское расследование. Приходите в любое министерство, в любую государственную структуру и заговорите по-татарски. Начинайте с вахтера, с приемной — как отреагируют? Посмотрите документы — есть ли там написанные на татарском... А как отвечает чиновник на письма, написанные по-татарски? Или, например, посидите на совещании, послушайте, на каком языке проводит его министр, свободно ли общается на татарском. Сходите в больницу, посмотрите, на каком языке врач объясняется с бабушкой, приехавшей из татарской деревни. Поговорите с людьми, наконец. Уверяю, ситуация станет для вас абсолютно прозрачной.

И не будете вы в своих публикациях зацикливаться на депутатах, не говорящих по-татарски... Депутаты — это только малая и, пожалуй, самая благополучная часть проблемы под названием «государственное двуязычие». В целом же надо отдать должное: сессии, заседания комиссий, парламентские слушания полно и всесторонне освещаются во всех серьезных средствах массовой информации. Эффективно работает пресс-центр и аккредитованные при нем журналисты. Они «в теме», они знают законы и неплохо в них разбираются.

Понятно, что у каждой газеты свои политические и экономические приоритеты. «Вечёрка», например, освещает проблемы иначе, чем «Республика Татарстан». Кстати, можно заранее ожидать, о чем будет писать то или иное издание.

Общее у них, пожалуй, одно. В Госсовете случаются и какие-то казусы, и конфликтные моменты — это естественно. Уж вот этого ни газетчики, ни телевидение не упустят. Это нормально.

Вызывает сожаление лишь то, что в некоторых, особенно татарских, изданиях «летопись» парламента ведется преимущественно в информационных жанрах: кто выступил, что сказал — и все. Это скучно. Сами журналисты не любят получать на свой

вопрос ответ «без комментария». Но и читатели, думаю, этого не любят.

Но самое досадное — из средств массовой информации у избирателей может сложиться впечатление, что депутат, как студент, живет от сессии до сессии. Выступил с трибуны, проголосовал — и свободен. И если ход сессий как-то анализируется, осмысляется, то остальная, большая часть деятельности депутатов остается «за кадром». Кому же как не парламентским корреспондентам рассказать об этой кропотливой, ежедневной работе, в чем заключается ее смысл. Вот этого не хватает, на мой взгляд, ни русским, ни татарским изданиям.

*2007*





Роберт Миңнуллин һәм академик Мирза Мәхмүтов (2001)

Роберт Миңнуллин, Бөтендөнья татар конгрессы рәисенең беренче урынбасары Рәмис Сафин, академик Роальд Сәгъдиев, тарихчы, фән докторы Дамир Исхаков, Татарстан Фәннәр академиясе президенты, академик Әхмәт Мазһаров, ТФА президенты урынбасары, профессор Әсхәт Гомәров, Бөтендөнья татар конгрессы рәисе, тарих фәннәре докторы Ринат Закиров (2008)





Ким Миңнуллин ТӘҺСИ галимнәре белән (2007)

Роберт һәм Ким Миңнуллиннар ТФА президенты Әхмәт Мазһаров, академик Индус Таһиров белән (2008)





Казахстанның күренекле шагыйре, дәүләт эшлеклесе, галим-тюрколог Олжас Сөләйманов белән очрашу. Казан (2007)

Роберт белән Ким Миңнуллиннар галимнәр һәм язучылар арасында (2006)





Ким Миңнуллин һәм ТФА президенты, академик Әхмәт Мазһаров

Роберт һәм Ким Миңнуллиннар азәрбайҗан шагыйре Кыязыйм Мәмәд (*уңнан икенче*) һәм Казандагы Азәрбайҗан җәмгыяте рәисе Зыяфәт Гасимов белән (2008)




Төркия профессорлары Айшә-Гөл һәм Осман Фикри Серткаялар белән. *Сулда* – аспирант Бәхтияр Миңнуллин (2008)





Иртуган Миңнуллиннар. *Алгы планда*: Ким. *Сулдан*: Рим, Роберт, Фән. Башкортстан, Шәммәт (1962)

«Без әнкәйнең биш шатлыгы идек...» (2005)





Бертуганнар: 31 ел үткәч (1993)

Роберт Миңнуллинның 60 яшьлек юбилеенда Шәммәт кунаклар җыйды





Роберт һәм Ким Миңнуллиннар (*сулдан уңга*) КДУ профессорлары Ринат Нәбиев, Васил Гарифуллин, Флорид Әгъзәмов белән (1998)

Ким Миңнуллин (*уңнан өченче*) якут галимнәре янында (2008)

## Кем ул Ким Миңнуллин?

Бәрәкәтле Башкортстан туфрагында туып, үз халкына хезмәт итүче милләттәшләребез байтак. Гөлҗәүһәр апаның — Роберт улы әйтмешли, исемендә алфавитның татарга гына хас бөтен хәрефләре дә сыеп бетә язган юмарт әнкәйнең — биш җәүһәре дә шулар җөмләсеннән. Әлеге китап исә — биш туганның икесе башкарган хезмәтләрдән бер парә.

Кардәш татар һәм башкорт халыкларының күренекле әдибе булып танылган, иҗаты дәүләт бүләкләренә лаек булган һәм халыкара мәйданга чыккан, шулай да «шагыйрь генә булып кала алмаган» Роберт Мөгаллим улы турында каләмдәшебез Шамил Муллаяновка өстәп сүз әйтергә калмагандыр да кебек.

Шәхсән үземә кагылганы — гомер Роберт Миңнуллин белән бергә узган икән: ул бераз олырак булса да, университетның тарих-филология факультетында бер тирәләрдә укыдык, берара «Казан утлары» журналында бергәләп эшләп алдык, аннан соң да хаҗәтенчә аралашып, бер «казан»да кайнау дәвам итте. Икебез дә «әни белән үскән бала» — үз тормышыбызны үз кулларыбыз белән көйләдек... Уфа тарафларына юл чыкканда, Шәммәткә «кагылып», Гөлҗәүһәр апа йортының капка келәсенә басуга, ни хикмәттер, мине дә Миңнуллиннар белән уртак хис били — үз нигезеңә кайту, үз-үзеңә кайту. Дусты дип мактана алмыйм, әмма уртак дусларыбыз бар иде, әле дә алар юк түгел... Роберт Мөгаллим улы зур даирәләрдә эшли башлагач, шәхси үтенечләр белән түгел, уртак максатка — халкыбызның киләчәгенә хезмәт итү, ягъни яшь буынга милли дәреслек һәм балалар китабы чыгаруда туган кайбер кыенлыкларны җиңүдә теләктәшлеген сорап эндәшкән чакларым булды. Әле дә туры килгәли. Чын күңелдән рәхмәтлемен: ул беркайчан да бусагадан бормады, алдалап озатмады, кулыннан килгәнчә ярдәм итте.

Ким Мөгаллим улы, киресенчә, миннән яшьрәк, аралашу еллары да күпкә кыскарак. Танышканда ул минем өчен иң әүвәл эш буенча бәйләнешле хөкүмәт чиновнигы, аннан соң гына Роберт Миңнуллин энесе иде. Еллар узган саен, безнең арадагы чикләр пәрәвез җебедәй нечкәрде,

ахирәтләр үк булып китмәсәк тә, ул минем эшемдә-тормышымда ышанычлы гамьдәш сурәтен алды. Кемгәдер сәер тоелыр, әмма без урамда очраклы гына күрешсәк тә, хәтта сирәк ял сәгатьләрендә телефоннан хәл белешсәк тә, гел эш турында, бары тик эш турында сөйләшәбез, һәм бер очрашу-киңәшүебез дә сүздә генә калмый: яңа проектларга, саллы китапларга әверелә, теге яки бу проблеманың иң дөрес чишелешен табарга ярдәм итә.

Бүген К.М.Миңнуллин — танылган җәмәгать эшлеклесе һәм зур галим, илдә бер гыйльми үзәк директоры, мөгаллимнәр әзерләүче югары уку йорты профессоры, фән докторы һәм Татарстан Фәннәр академиясенең мөхбир әгъзасы... Тик ул нинди генә дәрәҗәләргә ирешмәсен, безнең риясыз бәйләнышлар үзгәрмәде: үзара хөрмәт, ярты сүздән аңлашу, фикердәшлек, эшлекле хезмәттәшлек рухында дәвам итә.

Танышуыбыз, алда искәртелгәнчә, әле кичә генә кебек. Яшь ягыннан мине узып китә алмаса да, инде әнә ул да ир уртасы булып килә. Әйләнеп карасаң... Кемнәрдер безнең өстән шикаять арты шикаять яудырып, башлыкларның үкчә эзен ялап гомер уздырган арада, байтак эшгамәл башкарырга өлгергәнбез икән. Яшерен-батырын түгел: халкыбызга, аны тагын да зыялырак, тагын да бөегрәк итеп күрәсе килү теләге шәхси мәнфәгатьләребезгә туры килгән; үз алдыбызга куйган максатларга ирешү өчен төп терәгебез — безгә ышанып тапшырылган эш урыннары-вазифалар булган. Һәм без фикердә «әшнәлек»не берәүгә каршы да бормадык, киресенчә, уртак эшләребезгә яңадан-яңа талантлы галимнәрне, булдыклы яшьләрне җәлеп итәргә тырыштык, аларга үз мөмкинлекләрен тулырак ачарга ярдәм күрсәттек.

Премьер-министр урынбасарлары Илгиз Кәлимулла улы Хәйруллин, аннары Зилә Рәхимьян кызы Вәлиева, шулай ук Министрлар Кабинеты Аппараты башлыгы Шамил Хәмит улы Гафаров кул астында эшләү дәвере — үзе бер мәктәп булса, аларның ышанычын Ким Мөгаллим улы көндәлек фидакарь хезмәте беләнаклады. Аңа бу юлда ныклы иманы, зур җаваплылык хисен тоюы, кешеләр белән эчкерсез мөгамәләсе, тирән фәнни әзерлеге, фикердә принципиальлеге, зирәклеге һәм кыюлыгы ярдәм итте дип уйлыйм.

Хөкүмәт эшендә чагында туган телне саклау һәм үстерү буенча гыйльми эшчәнлекне оештыру җәһәтеннән — һич арттырусыз — бер ялгызы бер институтка тиң булган Ким Миңнуллин, сәгате суккач, үзен фән юлына алып кергән остазлары янына әйләнеп кайтты. Хәер, аспирантурада укыган чакларыннан алып, Г.Ибраһимов исемен йөрткән

Тел, әдәбият һәм сәнгать институтыннан аның киткәне дә юк кебек иде. Әмма бу кайту әнисе һәм абыйсы сабакларын алган, тормыш мәктәбен узган яшь җитәкченең икенче сулышы ачылуга тиң булды... Ниһаять, әтисенең Мөгаллим дигән исемен аклап, мөгаллимлек итүгә күбрәк вакытын сарыф итү, үз шәкертләрен тәрбияләү, яшь галимнәрне үстерү мөмкинлеге, — кыскасы, фәнгә һәм фикер алгарышына хезмәт итү мөмкинлеге артты... (Хөкүмәттә эшләү дәверендә дә ул үз бүлегенә булдыклы егетләр алды, аларны чын мәгънәсендә үз канаты астында тәрбияләп, яңа, катлаулырак вазифаларга озатты, һәм бүген аларның барысы да диярлек эш башында торучы дәрәҗәле җитәкчеләр.) Фәнни-оештыру эшчәнлегенең ябалдашы шул рәвешле куерса, тамырга ныгуы исә гыйльми эзләнүләренең иң тирән мәдәни катламга — халык иҗатына багышлавында да чагылыш тапты.

Тел сәясәтенең нәзари (теоретик) һәм гамәли (практик) мәсьәләләрен киң колач белән күтәрү, аерым алганда, XX гасыр дәвамында һәм әлегә кадәр татар филологиясенең иң четерекле мәсьәләләреннән берсе булып кала килгән алфавит белән орфографияне камилләштерү, шулай ук югары белемне туган телдә алу өчен мөмкинлекләрне киңәйтү, әлеге бурычларны башкарып чыгуның юлларын ачыклап күрсәтү, аларны хәл итүнең төп авырлыгын үз иңенә алу... — Миңа калса, Ким Миңнуллинның эш-иҗат үзәнен әнә шул ярлар билгели, ләкин ул алар арасына гына да сыеп бетми кебек. Аның киштәсендә үз фәнни хезмәтләре, югары уку йорты өчен дәреслекләре белән рәттән, аларны язгандагы кебек үк, зиһенен егәрләп, күңелен салып башкарган тау-тау китаплар тезелеп тора. Татар телендә югары уку йорты дәреслекләре, гыйльми хезмәтләр, терминология сүзлекләре. Сүзлек димәктән, хөкүмәттә Ким Миңнуллин эшләгән ун еллап вакыт эчендә «тел ачкычлары»на аеруча зур игътибар бирелгән, аларның гомуми саны да XX гасырның шуңарчы туксан елында басылып чыккан кадәр икән. Шулай да бу хезмәтләр арасында «Татарстан Республикасында тел сәясәте» дигән икетомлык аеруча кадерлесе булса кирәк. Әлеге куш китап — узган гасырның ике кызыклы һәм катмарлы дәверен — егерменче-утызынчы еллар белән туксанынчы елларын тоташтыручы күпер дә, янәшә куеп караганда күп кенә гыйбрәтләр алырлык манзара да кебек. Аның гыйльми һәм гамәли әһәмияте шундый ук киң колачлы һәм ерак перспективага юнәлгән.

Укучыга тәкъдим ителә торган шушы «куш-парлы» җыентык та республикабызда тел сәясәте өлкәсендә кабул ителгән карарларны гамәлгә ашыруда Ким Миңнуллинның, Роберт абыйсы кебек үк, акыл белән, ныклык

белән, эзлекле рәвештә шәхси катнашуын сыйфатлаучы бер дәлил булыр. Аның туган тел хакына күпьяклы һәм нәтиҗәле хезмәт итүе әлеге китапта урын алган тирән эчтәлекле, зур мәгънәле чыгышларында, әңгәмәләрендә һәм мәкаләләрендә шактый ачык булып күз алдына баса. Шулай да... һәркөнлек даими эшчәнлекне, ә кайчакта, мәгълүм Сизифның тауга каршы тәгәрәткән ташы шикеллерәк, чигенә-чигенә булса да алга этәрергә туры килгән мәсьәләләрне бер тупланмада гына чагылдырып бетерү бик читен. Шунысы тәгаен ачык: бу — әле йомгак ясау түгел, бу — озын юл уртасында бер мизгелгә тукталып, узганнарга борылып карау гына. Алда исә — яңа үрләр, яңа борылышлар, кыскасы, хәрәкәт, эш, тормыш дәвам итә! Ким Мөгаллим улы Миңнуллин җитәкләгән институтның якын киләчәктә, Галимҗан Ибраһимов заманнарындагы кебек, «татарны өйрәнү» (татароведение) — татар фәне һәм мәгарифен әйдәп баручы чын Академик үзәк — креатив идеяләр фонтаны, яңа ачышлар технопаркы булып җитлегәсенә иманым камил минем. Галим-җитәкченең үз уңышлары да шул биеклек-дәрәҗәләрне билгеләр, иншалла.

Әлеге язмага керешкәндә, «*Кем ул Ким Миңнуллин?*» дигән сорауны мин үземә куйган идем. Чөнки моңа кадәр ул хакта уйланырга җае да чыкмаган, вакыты да тимәгән икән. Чыннан да, беренче карашка бик аңлаешлы, итагатьле, ачык йөзле, шул ук вакытта вакыт-вакыт күзлек өстеннән «сөзеп», кара мыеклары астыннан серле генә елмаеп куючан бу шәхес кем соң әле минем өчен һәм, әлбәттә, башкалар өчен дә?

Аны республиканың зур җитәкчеләре дә, олпат галимнәр һәм әдипләр дә, укытучылар һәм студентлар да яхшы белә. Бер сүз белән әйткәндә, халык таный. Инде шушы урында туктап: тынгысыз эзләнүләргә чумган «эш аты», язмышына шөкер итсә дә, үз-үзеннән һичкайчан канәгать булмаган галим һәм мөгаллим, абруйлы җитәкче һәм асыл ир-егет, — бик беләсегез килсә, менә кем ул Ким Мөгаллим улы, дип әйтергә буладыр. Әмма мин аның турында сүзне ничаклы гына дәвам итсәм дә, кәгазь битеннән күп нокта белән аерылырга туры киләчәк: Ким Миңнуллинны инде тулысынча ачылган, кемлеген тәмам танытып өлгергән шәхес дип расларга кем җөрьәт итәр икән...

*Мөдәррис Вәлиев*

# К. М. МИҢНУЛЛИН



*Талбишекләрне өй түренә иң элек әнкәйләр, әткәйләр элә. Ил түрендә аны милләт тибрәтә. Җырдан-моңнан үрелгән талбишекләргә, татарның талбишегенә киләчәк гасырлар түрендә дә тибрәлергә, тибрәнергә язса икән.*

*Наша работа повлияла и на языковую, и на национальную политику в России.*

## ЯҢА АЛФАВИТ ПРОЕКТЫ ТУРЫНДА

*(Телләр турындагы Законны гамәлгә ашыру комитеты утырышында ясалган чыгыш)*

Кешелек дөньясында иң бөек ачышларның берсе, мөгаен, хәреф, язу уйлап табу булгандыр. Дөнья тарихында аерым халыкларның узган юлы, аларның дөнья цивилизациясенә керткән өлеше турында фикер йөрткәндә дә, нигездә, бу халыкларның язма мәдәниятенә, тарихка билгеле язма хәзинәләренә, язма һәйкәлләренә карап бәя бирелә. Татар халкы бу җәһәттән олы бәхеткә ия. Аның күп гасырлык язма байлыгы бар. Болар безнең тарихи көзгебез, горурлыгыбыз һәм мактанычыбыз. Әмма шул ук язу, шул ук алфавит халкыбыз тарихының күңел өшеткеч битләрен тәшкил итә, халкыбызның олы фаҗигасенә дә әверелә. Чөнки ул укый-яза белмәгән һәрбер татар кешесенә кагыла. Гап-гади әлифба язмышы турыдан-туры халкыбыз язмышы, халкыбызның киләчәге белән бәйләнгән.

Ана телебездә яңгыраган авазларны теркәгән татар әлифбасының графикасын алыштыру, үзгәртү ул — бөтен рухи тормышыбызны, фикерләү рәвешебезне, дөньяга карашыбызны да үзгәртү дигән сүз.

Мәгълүм ки, озак елларга сузылган фикер алышулардан, бәхәсләшүләрдән, сәяси гамәлләрдән соң гасырлар дәвамында гарәп язуыннан файдаланган татар халкы да 1927 елдан башлап, башка төрки халыклар белән беррәттән, латин графикасына нигезләнгән язуга күчте. Шул ук елларда Советлар Союзында яшәгән һәм борынгы уйгур-монгол, борынгы яһүд язуындагы халыклар да латинга күчерелде. Ә 12 ел узуга, Татарстан Республикасы Югары Советының 1939 ел, 5 май Указы нигезендә, татар язуы кириллицага нигезләнгән алфавитка күчәргә мәҗбүр булды. Бу вакыйгадан соң

59 ел узды, әмма алфавит мәсьәләсенә әле һаман нокта куелмаган, фикер алышулар һәм бәхәсләр куера гына бара.

Соңгы елларда бу темага булган сөйләшүләр аеруча актив төс алды. Татар язуы өчен кайсы графика кулайрак, дигән сорау халкыбызның зыялылары, галимнәре, җәмәгатьчелек җыелган күплəгəн җыелышларның көн тәртибенә куелып тикшерелде. Матбугат битләрендә дә дистәләгән язмалар дөнья күрде. Озак эзләнүләр, аңлашулар нәтиҗәсендә җәмәгатьчелек, гомумән алганда, латин графикасына нигезләнгән татар алфавитына кайтуны гамәлгә ярашлы дип таба. Хөрмәтле Президентыбыз Минтимер Шәрипович Шәймиев тә үзенең Икенче Бөтендөнья татар конгрессында ясаган чыгышында, бу мәсьәләгә тукталып, төрки халыкларда барган ситуацияне ачыклады һәм: «Татарлар — төрки дөньяның бер өлеше. Үзебезнең 20 нче еллар тәҗрибәсеннән һәм башка төрки халыклар тәҗрибәсеннән чыгып, безгә дә латин графикасына күчә башларга кирәктер», — диде. Шуңа күрә безнең бүгенге бурычыбыз латин графикасына кайту кирәкме-юкмы дигән мәсьәләне хәл итү түгел, ә бәлки алфавитның соңгы вариантын гамәлгә кертерлек итеп әзерләп бетерү һәм әлеге алфавитны кайтаруга караган документларның проектлары буенча фикер алышу, андагы эшләп бетерәсе урыннарны ачыклау. Бу документлар утырышта катнашкан һәр кешегә дә өләшенде.

Латин графикасындагы алфавитка карата бик күп фикерләр әйтелде. Хөкүмәт исеменә министрлыклардан, фәнни оешмалардан рәсми җаваплар, җәмәгатьчелек исеменнән бик күп хатлар, мөрәҗәгатьләр килде. Алфавитның берничә варианты тәкъдим ителде. Матбугат битләрендә тәкъдим ителгән вариантлар, нигездә, өч төркемне тәшкил итәләр: төрки телләр өчен тәңгәлләштерелгән вариант, яңалифкә нигезләнеп эшләнгән вариант һәм компьютер өчен җиңел дип табылган алфавит. Хөкүмәткә адресланган материаллардан чыгып, бүгенге утырышка исә Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты исеменнән тәкъдим ителгән «яңа татарча» дип аталган һәм бер төркем галимнәрдә, Матбугат һәм мәгълүмат, Мәгариф министрлыкларында яклау тапкан «Яңалиф» вариантлары тәкъдим ителә.

Тәкъдим ителгән вариантларның икесендә дә татар теленә хас булган барлык авазлар да урын алган. Әмма авазларны билгеләүче хәрефләрдә аермалыклар күп калган әле. Алар — 8.

Хәзер инде, миңа калса, шушы документлар нигезендә алфавит вариантлары һәм башка документларның проектлары буенча фикер алышуга керешергә кирәктер.

*1998*

## ТЕЛЛӘР САГЫНДА — ДӘҮЛӘТ

— *Ким Мөгаллимович, Телләр комитетының оешу тарихына тукталып китик әле.**

— Безнең комитет, тулы исеме белән әйтсәк, болай атала — «Татарстан Республикасы халыклары телләре турында» Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы комитет. Атап үтелгән Закон, мәгълүм булганча, 1992 елда кабул ителгән иде. Ике елдан соң аны тормышка ашыруга юнәлдерелгән Дәүләт программасы расланды. Нәкъ менә шушы программада, Законны тормышка ашыру өчен, Министрлар Кабинеты каршында махсус комитет оештыру каралган иде. Җәмәгать тәртибендәге бу структура әнә шулай барлыкка килде.

Комитет составына күренекле дәүләт һәм җәмәгать эшлеклеләре, халык депутатлары, галимнәр — барлыгы 30 га якын кеше керә.

Комитетның рәисе — республика Премьер-министры. Аның ике урынбасары бар: Премьер-министр урынбасары И.К.Хәйруллин һәм академик М.З. Зәкиев.

Күргәнегезчә, комитет җитәкчелегендә сүзләре теләсә кайсы дәрәҗәдә үтәрдәй олы җитәкчеләр дә (урыннарда законның үтәлешен тәэмин итәр өчен монысы аеруча мөһим), катлаулы тел процессларына фәнни бәя бирә алырдай абруйлы галимнәр дә бар.

---

* Әңгәмәдәш — КДУ профессоры, журналистика факультеты деканы Васил Гарифуллин.

Мин исә комитетның агымдагы эшләрен һәм, гомумән, хөкүмәттә бу законга караган мәсьәләләрне алып барам.

Комитетта өч төп комиссия эшли: терминология, топонимия һәм тел хезмәте күрсәтү комиссияләре.

*— Татар телен тулы канлы дәүләт теле итү турында сүз барганда, бөтен җәмгыятьне шушы максатка туплау бурычы торганда, Телләр комитетының җәмәгать тәртибендәге бер структура гына булып калуы аңлашылмый...*

— Телләрнең яшәеше белән бәйле мәсьәләләрне җәмәгать тәртибендәге комитет җилкәсенә генә дә, Фәннәр академиясенең Тел, әдәбият һәм сәнгать институтына гына да йөкләп бетереп булмый. Бездә еш кына тел мәсьәләсенә караган һәрнәрсәне телче галимнәр карамагына тапшырырга була дигән шактый хаталы фикер алга сөрелә.

Тел — сәясәт тә бит ул. Шуңа күрә аның үсеш перспективалары белән тел белгечләре генә түгел, сәясәтчеләр, юристлар, икътисадчылар, социологлар һәм башка бик күп төрле һөнәр ияләре дә шөгыльләнергә тиеш. Телләр үсешенең стратегиясен эшләү өчен, берәр махсус үзәк булдыру зарур.

Телнең яшәешенә контрольлек итүче дәүләти структуралар күп илләрдә уңышлы эшләп килә. Кытайда шундый махсус министрлык бар икәнлеген беләм. Илнең аерым субъектларында, мәсәлән, Синьцзян-Уйгур автономияле районында телләр үсешен тәэмин итүче, аларны куллануны җайга салучы дәүләт комитеты эшли. Комитетның контроль ясау вазифасы көчле, административ җаваплылыкка тарту хокукы бар. Шуңа күрә финанс ягыннан үзләрен тәэмин итеп тә тора алалар.

Тиешле норматив-хокукый документлар кабул иткәндә мондый оешмаларны инде бүгеннән республикабыз шәһәрләрендә төзергә мөмкин булыр иде. Шәһәр тормышының бөтен өлкәләрендә телне куллануга күзәтчелек итүче, ярдәм күрсәтүче ул структура хуҗалык исәбенә дә яши алачак. Киләчәктә Татарстан кебек күпмилләтле республиканың хөкүмәтендә тел сәясәтен алып баручы махсус бер бүлек, ә Президент Аппараты каршында махсус департамент кебегрәк подразделение булыр дигән өмет бар.

*— Җәмәгать тәртибендә эшләп тә, Телләр комитеты шактый гына эшләр башкарып өлгерде кебек.*

— Баштан ук шуны ачыклап китсәк дөрес булыр: бер әңгәмәдә генә комитетның барлык эшләрен яктыртып бетерү, телләр мәсьәләсенә караган проблемаларның һәр ягына тукталу мөмкин түгел. Иң мөһимнәренә генә тукталыйк.

Комитет эшне берничә юнәлештә алып бара: Законның, Дәүләт программасының үтәлешен контрольдә тоту, хокукый һәм норматив документлар эшләү, әлеге мәсьәләне фәнни яктан өйрәнү, шәһәр һәм районнарда оешкан комиссияләргә гамәли һәм методик ярдәм күрсәтү. Комитет, кварталга бер тапкыр җыелып, телләр турындагы Законны гамәлгә ашыруның барышын тикшерә. Узган утырышларда аерым районнарда законның үтәлеше каралды. Әйтик, Әлмәт, Аксубай, Кукмара, Алабуга шәһәре һәм районында, Чаллыда татар телен гамәлгә кертү турындагы мәсьәлә җентекләп тикшерелде. Шулай ук кайбер министрлыклар һәм дәүләт комитетларының, мәсәлән, республика Элемтә министрлыгының законны үтәү буенча эшчәнлеген тикшердек.

*— Бу уңайдан аеруча Мәгариф министрлыгына зур бурычлар йөкләнә, шулаймы?*

— Телләр турындагы Законны гамәлгә куюда Мәгариф министрлыгы шактый гына эшләр башкарды инде. Закон кабул ителгәннән соң, балалар бакчаларында, мәктәпләрдә никадәр алга китеш булуы — барыбызның да күз алдында. Бүген телне укытуның сыйфатына игътибарны арттыру — көнүзәк мәсьәлә.

Гомуми урта белем бирү системасыннан тыш, махсус урта белем һәм югары белем бирү учреждениеләребез дә күп бит әле. Менә аларда эш кыенрак бара. Бигрәк тә техникумнарда һәм училищеларда. Дөрес, хәзер татар телен укытуга игътибар аларда да арта төште. Фәннәрне татар телендә укытуга килсәк, хәлләр аяныч. Ә бит уку йортларының күбесендә татар телен камил белергә тиешле урта буын җитәкчеләр әзерләнә. Без, энтузиастларны тартып та, махсус совет оештырып та, эшне җанландырырга тырышып карадык. Соңгы вакытта бу эшне җайга салуның нәтиҗәле юлын

таптык кебек: уку йортларының үзенчәлегенә бәйле рәвештә берничә училище базасында махсус координацион советлар оештырдык. Уңышлар булыр дип өметләник.

Югары мәктәпләребездә эшләр җайга салына башлады, дияр идем. Татар телен гамәлгә кертү буенча вузара махсус гыйльми-методик совет оештырылды. Совет утырышларында сүз татар телендә укытуны яхшырту турында бара, югары уку йортларына Татарстан хөкүмәте тарафыннан бирелгән өстәмә акчаның ничек сарыф ителүе тикшерелә. Узган ел дәүләт вузларына ул вакыттагы акча белән 1 миллиард 500 миллион сум, быелның беренче яртыеллыгында 500 мең сумнан артыграк акча бүлеп бирелде. Югыйсә татарча укыту мәсьәләсен кузгата башласак, вуз җитәкчеләре акча юклыктан зарлана иде. Хәлбуки, акчаны федераль бюджеттан гына алган очракта да, югары уку йортлары татарларга татар телендә белем бирүне оештырырга тиеш. Бу хакта Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы хөкүмәтләре арасында югары белем өлкәсенә караган килешүнең беренче маддәсендә акка кара белән язып куелган.

Телләр турындагы Законны тормышка ашыруда республикабызның барлык педагогик уку йортлары, шулай ук Казан архитектура-төзелеш академиясе, Авыл хуҗалыгы академиясе, Кама политехник институты уңышлы эшли. Мәдәният һәм сәнгать академиясендә татарча укытуны гамәлгә кую эшен махсус программа нигезендә алып баралар.

Соңгы елларда гына «Мәгариф» нәшрияты югары уку йортлары өчен математика, гомуми химия, теоретик механика кебек фундаменталь фәннәр, авыл хуҗалыгы белгечлекләре буенча шактый дәреслекләр чыгарып өлгерде. Бу эш дәвам итә.

Вузара гыйльми-методик совет, безнең комитет белән берлектә, югары уку йортларында татарча укыту проблемаларына багышланган махсус фәнни-практик конференция дә уздырды.

— *Мондый конференцияләр үткәрү Телләр комитетының мөһим бер эш юнәлешенә әйләнеп бара бугай.*

— Әйе. Бая әйтелгәннән тыш, быел гына да «Татар теле һәм яңа информацион технологияләр», аннары «Татарстан Республи-

касында ономастика мәсьәләләрен хәл итү юллары» дигән темага фәнни-гамәли конференцияләр уздырдык. Бу конференцияләрнең материалларын туплаган махсус җыентыклар чыгарабыз.

Менә шушы уздырган конференцияләрне йомгаклау һәм телләр турындагы Законны үтәүдәге алты еллык эшчәнлегебезгә йомгак ясау максатында, шулай ук бу юнәлештәге стратегик бурычларны ачыклау өчен быелның ноябрь аенда Казанда тагын бер бик зур фәнни-гамәли конференция уздырачакбыз. «Татарстан Республикасында телләрнең бүгенгесе һәм киләчәге» дигән исем астында оештырыла торган бу чарада тел галимнәре, вуз укытучылары, мәктәп хезмәткәрләре генә түгел, төрле министрлык һәм ведомстволар вәкилләре дә турыдан-туры катнашачаклар. Мәсәлән, республиканың Куллануучылар хокукларын яклау дәүләт комитеты һәм Татарстан Сәүдә министрлыгы белән берлектә халыкка хезмәт күрсәтү өлкәсендә икетеллелекнең тормышка ашырылуы мәсьәләләре буенча махсус секция эшләячәк.

Конференция уңаеннан татар телен гамәлгә куюда булган тәҗрибәне гомумиләштергән ике җыентык әзерләнә. Аларның беренчесе — «Татарстан Республикасында тел сәясәте: Документлар һәм материаллар (20—30 нчы еллар)», икенчесе «Татарстан Республикасында тел сәясәте: Документлар һәм материаллар (80—90 нчы еллар)» дип атала.

В целях выполнения одного из пунктов Государственной программы Республики Татарстан по сохранению, изучению и развитию языков народов Республики Татарстан в сентябре 1999 года после долгих и многократных обсуждений был принят Закон Республики Татарстан «О восстановлении татарского алфавита на основе латинской графики». Это было обусловлено необходимостью введения научно обоснованного оптимального для фонетической системы татарского языка алфавита, создающего

благоприятные условия для его вхождения в систему мировой коммуникации.

В целях реализации данного закона начата переподготовка кадров, подготовлена материально-техническая и научно-методическая база восстановления латиницы. Разработаны и изданы учебники и учебные пособия, детская художественная литература, подготовлен к изданию орфографический словарь татарского языка на основе латинской графики. С учетом современных тенденций и технологий разработаны стандарты кодировки символов татарского алфавита на основе латинской графики и базовые программы для компьютерных применений. Министерством образования республики в каждом районе и городе республики организован и проведен эксперимент по адаптации к правилам татарской орфографии на основе латинской графики.

Вопрос татарской письменности раскрыл состояние общества не только у нас в республике, но и в целом в России. Что я имею в виду? Проблема выявила миропонимание, отношение ученых, интеллигенции, людей самых разных возрастов и профессий к вопросу о будущем нашего народа. Здесь четко обозначились позиции, в том числе взаимоотношения. Мы увидели нашу способность и вместе с тем желание и нежелание решать серьезные задачи. Редкий вопрос может так ярко, подобно рентгену, высветить общество.

Проблема высветила и младенческий возраст демократии в нашей стране, что допускает обсуждение уже принятых региональных законов на предмет их «лояльности» к России. Как известно, группой депутатов Государственной Думы России был разработан проект Федерального Закона «О внесении дополнения в статью 3 Закона РФ «О языках народов РФ» и прошел первое чтение. Суть дополнения заключается в обязательном использовании государственным языком РФ и государственными языками республик в составе РФ алфавитов только на основе кириллицы, то есть букв русского алфавита. Иные обозначения букв алфавитов государственных языков в составе РФ могут устанавливаться лишь федеральными законами.

Считаю необходимым обратить внимание на то, что проект данного закона противоречит концептуальным основам и положениям как Конституции Российской Федерации, так и Закону о языках народов Российской Федерации. Не случайно и вполне логично, что ни их разработчики, ни законодатель не затронули в содержании указанных документов вопрос о письменности наций и народов России. Ибо определение графики письма родного языка, тем более государственных языков, языков, имеющих многовековую историю письменности, является внутренним делом каждого народа — носителя языка.

Общество вошло в новый XXI век с определенным накопленным опытом и конкретными результатами в реализации языковой политики. Прошедшие 10—12 лет следует охарактеризовать как качественно новый этап в данном направлении. В нашей республике идет процесс становления и развития полиэтнической языковой среды нового качества. Разумно выбранные темпы движения к поставленной цели позволили не только сохранить, но и укрепить основы межнационального мира и согласия в Татарстане и в России в целом.

Вместе с тем выявилось множество серьезных проблем, стало возможным более глубокое их понимание, с одной стороны, и осознание необходимости проведения фундаментальных научных исследований, разработки и реализации долгосрочных и краткосрочных программ разных уровней, с другой. Языковая политика не может проводиться в виде единовременного акта, путем принятия одного закона или одной программы. Международный опыт показывает: эффективная языковая политика становится результатом длительного, последовательно осуществляемого законодательного регулирования.

Опыт реализации Государственной программы за прошедшие годы выявил ряд факторов, препятствующих достижению поставленных целей:

— сложность процессов, происходящих в языковой сфере общества, и медленный характер изменений, отражающих повышение статуса и расширение функций татарского языка;

— наличие пробелов в правовом регулировании языковой политики, в том числе описательно-декларативный характер Закона о языках (как республиканского, так и федерального);

— недостаточная разработанность научных основ, регламентирующих объемы и специфику функционирования татарского языка в различных сферах деятельности;

— массовое снижение речевой культуры, стирание границ между функциональными стилями языков, пренебрежение литературной нормой, непомерно высокий удельный вес заимствованной лексики;

— сокращение сферы функционирования татарского языка в регионах компактного проживания татар в Российской Федерации и др.

Этот список обозначил первоочередные направления дальнейшей деятельности в области языковой политики, которые требуют не только материальных и финансовых, но и интеллектуальных вложений, преодоления психологических барьеров. Для выполнения этих задач необходима разработка и реализация новых нормативно-правовых документов, а также программы следующего уровня сложности. Все это является признаком выхода республики на новый этап решения национально-языковых проблем.

*2002*

## МАТЕРИАЛЫ ПО ВОПРОСАМ РЕФОРМЫ ПИСЬМЕННОСТИ ТАТАРСКОГО ЯЗЫКА

Как известно, 15 ноября 2002 года Государственной Думой Федерального Собрания Российской Федерации в третьем окончательном чтении принят Закон «О внесении дополнения в статью 3 Закона Российской Федерации „О языках народов Российской Федерации"», обязывающий использовать в письменности государственных языков республик в составе Российской Федерации только алфавиты на основе кириллицы (букв русского алфавита).*

* Информация для Совета Федерации.

Подходы к проблеме, сама форма обоснования, увязывающая восстановление татарского алфавита на основе латинской графики с вопросами безопасности России, глубоко потрясли общественность республики и наших соотечественников, проживающих за пределами Татарстана. Закон прямо противоречит Коституции Российской Федерации (ст. 26, ст. 68, пп. 2 и 3, ст. 71), нарушает основополагающие принципы международного права — правосубъектности народов. Подобное решение может явиться беспрецедентным для государства, стремящегося освоить демократические принципы развития общества. Тогда как и в царской России, и в советский период использование народами алфавитов, отличных от кириллицы, воспринималось естественно.

Языки народов Российской Федерации имеют свою многовековую историю, а часть из них прошла долгий путь совершенствования письменности с учетом своей природы и уникальных отличий. Народы помнят и то, насколько пагубным оказался по отношению к языкам «эксперимент» с навязыванием алфавитов, проведенный в годы советской власти. Тогда целые народы при жизни одного поколения были вынуждены по два-три раза менять свои алфавиты. В результате не до конца продуманных шагов и острой политизации лингвистического процесса был потерян целый пласт культуры народов России, приобретенной ими в течение многих веков. На этом этапе языкового строительства особенно большие потери понесли языки с развитой письменностью и богатым литературным наследием, в число которых, несомненно, входит и татарский язык.

Булгаро-татарская письменность, существовавшая с V века н.э., в своей истории трижды пережила смену алфавита. Первоначальную руническую письменность в X—XI вв. сменил арабский алфавит, который просуществовал до XX века. В 1927 году он был заменен латинским Яналифом (аббревиатура, которая с татарского расшифровывается как «новый алфавит»). В 1939 году татарский язык был переведен на кириллицу.

Арабское письмо пришло к нашему народу вслед за принятием Волжской Булгарией ислама и установлением культурных, эконо-

мических отношений с Аравией и Ираном. Оно в разных формах и стилях написания более тысячи лет прослужило татарскому народу. Однако это письмо не во всем соответствовало звуковому строю татарского языка, так же как и языкам некоторых других народов, что требовало совершенствования алфавита. Татарская общественность в конце XIX века поставила вопрос о проблеме исправления правописания, добавления специальных знаков в алфавит и наоборот — исключения знаков, обозначающих арабские звуки, которых не было в татарском языке. Кроме того, для пишущих и читающих арабские буквы всегда существовал вопрос владения секретами, особенностями разных форм почерка арабской письменности. Постепенно все это и привело к мысли о необходимости изменения графики.

Одним из первых о недостатках арабского алфавита, используемого для тюркских языков, уже в середине XIX века выступил азербайджанский писатель и драматург Мирза Фатали Ахундов, который предложил самый первый проект тюркского алфавита, основанного на латинской графике. В развитие этой идеи в начале XX века известный татарский поэт Сагит Рамеев разработал собственный вариант непосредственно татарского алфавита.

Тем не менее в 1910— 1920 годах проходили острые дискуссии, велась огромная работа по усовершенствованию арабского алфавита, этому было посвящено множество съездов и конференций. Но параллельно уже усиливалась работа по созданию алфавита на основе латинской графики.

Партийно-государственные органы, оценив перспективы отрыва тюркских народов от многовековой истории и культуры, написанной арабской графикой, ликвидации влияния мусульманской религии, перевели лингвистические поиски в добровольно-принудительное русло. Окончательный поворот в сторону латиницы произошел после I тюркологического съезда в Баку, состоявшегося в феврале 1926 года. Съезд после бурных дебатов принял в духе своего времени следующую резолюцию: «Констатируя преимущество и техническое превосходство нового тюркского алфавита (латинского) над арабским, (...) съезд считает введение нового алфавита

и метод его проведения в отдельных тюрко-татарских республиках и областях делом каждой республики и каждого народа».

После дальнейших жарких обсуждений специальным постановлением Совета Народных Комиссаров ТАССР от 3 июля 1927 года татарский алфавит, основанный на латинской графике, утверждается как официальный алфавит татарского языка. Алфавит, который в народе называется «Яналиф», был составлен крупными языковедами разных народов (Г. Нугайбек, М. Корбангалиев, Г. Алпаров, Л. Щерба, Л. Жирков, Н. Яковлев, Ф. Агазаде, Н. Тюрокулов, С. Агамалы-оглы, М. Ахундов, С. Атнагулов, А. Богородицкий и др.) и выдающимися деятелями литературы (С. Рамеев, Ш. Усманов, Ф. Сайфи-Казанлы и др.) в течение нескольких лет (с 1912 по 1927г.). Несмотря на сложный и неоднозначный характер реформы алфавита и негативные побочные проявления в процессе его внедрения, впоследствии сам алфавит получил одобрение и признание татарского народа за простоту, красоту и стройность начертания букв, а главное — более полное соответствие звуковой системе татарского языка.

В эти же годы переход на латиницу был осуществлен и в других тюркских республиках бывшего СССР. А с конца 30-х годов процесс перехода на латиницу приобретает в стране широкомасштабный характер. В общей сложности были разработаны алфавиты на основе латинской графики для более чем 60 языков народов страны, включая и те народы, у которых алфавиты были основаны на кириллице. При Наркомпросе РСФСР существовала комиссия, целью которой была разработка вопросов перевода на латиницу и русского языка. Часть алфавитов осталась в виде проектов, другие использовались недолгое время, тюркским языкам, пользовавшимися арабской графикой, латиница послужила до конца 30-х годов — до массового перехода на кириллицу.

Процесс поиска и выбора оптимального для звуковой системы своих языков алфавита народами мира продолжался и за пределами границ Советского Союза. В первой четверти XX века с арабского письма на латиницу были переведены ряд языков в Индонезии, Малайзии, Северной Африке, чуть позже — в Турции.

5 мая 1939 года Указом Президиума Верховного Совета Татарской АССР алфавит татарского языка на основе латыни был переведен на кириллицу. Однако этот переход был сделан уже без какого бы то ни было обсуждения, учета мнений общественности и специалистов. Критика алфавита началась практически с момента его принятия, но всякая попытка подогнать новый алфавит под систему звуков татарского языка объявлялась проявлением национализма. Впервые реальная возможность усовершенствовать татарскую графику возникла в период «оттепели», в конце 50-х годов. Многие тюркские народы — башкиры, казахи, азербайджанцы, туркмены — не преминули ею воспользоваться и внесли ряд уточнений в свои алфавиты. Однако тогда в татарский алфавит не были внесены изменения.

Коренные перемены, происходившие за последние десятилетия в общественно-политическом строе, в экономической системе, в идеологии и национальной политике Российской Федерации, находят отражение во всех сферах жизнедеятельности. Глубокие изменения происходят и в языковой сфере: создаются новые принципы языковой политики, выдвигаются языковые проблемы, требующие научного осмысления и практического решения. Адекватно реагируя на эти процессы, Верховный Совет РСФСР в начале 90-х годов принял ряд нормативно-правовых документов, а именно: Закон РСФСР «О языках народов РСФСР», Декларацию «О языках народов РСФСР», Концепцию Государственной программы по сохранению и развитию языков народов Российской Федерации, которые явились основополагающей базой для возрождения национальных культур, стимулом для сохранения самобытности народов и их языков.

На основе этих политико-правовых актов и в Республике Татарстан в 1992 году был принят Закон «О языках народов Республики Татарстан», позднее была утверждена Государственная программа Республики Татарстан по сохранению, изучению и развитию языков народов Республики Татарстан. Закон закрепил за татарским и русским языками статус равноправных государственных языков, гарантировав языкам других народов защиту со стороны

государства. Эти принципы заложены в Конституции Республики Татарстан. Главным итогом деятельности органов государственной власти республики за эти годы можно считать сохранение оптимального микроклимата в межэтнической среде, становление и развитие полиэтнической языковой среды нового качества.

Наряду с деятельностью по расширению сфер функций татарского языка как государственного в среде татарской общественности и интеллигенции развернулись бурные дискуссии о необходимости совершенствования письменности. В ходе широкого обсуждения, горячих дискуссий преобладало мнение о восстановлении латиницы.

Усиление этих взглядов было связано с тем, что алфавит, основанный на кириллице, рассматривался как память о культе личности 30-х годов и решение проблемы письменности татарского народа насильственным путем. Оно было продиктовано и тем, что не выполнялись принятые парламентом России в начале 90-х годов документы, где были заложены демократические принципы формирования и развития двуязычия и многоязычия в обществе. Отсутствовали соответствующие государственные структуры, курирующие эту деятельность на федеральном уровне и обобщающие опыт Татарстана и других регионов в интересах многонациональной России. В то же время основным аргументом было и остается, прежде всего, то, что существующий алфавит не отвечает целому ряду критериев оптимального алфавита, в частности:

— **Алфавит, основанный на кириллице, неадекватно отражает звуковую систему и усложняет орфографию современного татарского языка.** Например, в данном алфавите отсутствуют буквы для обозначения следующих специфических звуков татарского языка: [къ], [гъ], [w]; в то же время в алфавите имеются знаки, для которых вовсе нет звуков в татарском языке: «Е», «Ё», «Э», «Ц», «Щ», «Ю», «Я», «Ж»;

— **Один алфавит на две сильно различающиеся фонетические системы русского и татарского языков, функционирующих в одной и той же среде, приводит к интерференции русской речи татар и татарской речи русскоязычных.** При этом наблюдается диффузия, размыва-

ние фонем и, соответственно, происходит разрушение обоих языков, но первую очередь и в большей степени того, который оказался в роли полифункционального. Например на письме одними и теми же буквами («К», «Т», «В», «Ч», «Ы», «О», «А» и некоторыми другими) передаются различные звуки этих языков; передача специфических звуков татарского языка буквами, похожими на русские, создает дополнительные трудности для лиц нетатарской национальности, изучающих татарский язык как государственный язык республики;

— **Алфавит на основе кириллицы значительно сложнее адаптируется к компьютерным технологиям.** Возникает оторванность от мировой компьютерной информационной системы. Аналогично обстоят дела и с алфавитом русского языка. Решения требуют дополнительных усилий и средств.

Адаптация кириллического алфавита под татарские фонемы требует изменения порядка 20 графем (букв) и, следовательно, внесения в алфавит татарского языка на основе кириллицы новых графических изображений: либо совершенно новых, отличных от существующих, либо измененных имеющихся графем за счет добавления «хвостов» и «рожек» к кириллическим буквам. Очевидно, такой алфавит уже трудно будет назвать кириллическим, скорее это будет некая эклектика, попытка создать «новый» искусственный алфавит. А это уже действительно бессмысленный, неоправданный уход от существующего алфавита, с потерей всех плюсов кириллицы.

В этих условиях был разработан и предложен для обсуждения депутатам проект Закона Республики Татарстан «О восстановлении татарского алфавита на основе латинской графики», который после многократных обсуждений и внесения замечаний, предложений в сентябре 1999 года был принят парламентом. Закон предусматривает поэтапное введение нового алфавита в течение десяти лет.

Должен привлечь внимание тот факт, что лишь через полтора года после принятия указанного закона, не вникая в исторические корни данной проблемы и не предлагая альтернативные пути ее решения, ряд депутатов Государственной Думы подняли вопрос

о мнимой угрозе безопасности России в связи с переходом татарского языка на латинскую графику.

Восстановление латинской графики является логическим завершением длительного этапа совершенствования татарской письменности, начавшегося целое столетие назад. В решении этого вопроса не должны играть роль политические амбиции, не должно доминировать мнение людей, не имеющих должного опыта в профессиональном анализе письменности различных языков.

Специалисты, усиленно занимавшиеся конкретными вопросами реформы татарской письменности в течение десяти последних лет, более других имеют представление о реальных сложностях и необходимости дополнительной проработки организационных, научных и учебно-методических аспектов этого процесса. Однако они полагают, что освобождение лингвистического вопроса от политизации и надуманных опасностей позволит бескризисно решить его в рамках полномочий народа — носителя языка, гарантированных Конституцией Российской Федерации. Многонациональный народ Республики Татарстан сохраняет уверенность в возможности цивилизованного урегулирования вопроса. Объединение усилий народов Российской Федерации с федеральным центром и в специфическом вопросе алфавитов, возвращение к документам по вопросам национально-языковой политики, принятым в начале 90-х годов Верховным Советом РСФСР, сделает это урегулирование еще менее болезненным.

*2002*

## ПРЕДЛОЖЕНИЯ ПО РЕШЕНИЮ ПЕРВООЧЕРЕДНЫХ ВОПРОСОВ РЕАЛИЗАЦИИ ЗАКОНОДАТЕЛЬСТВА О ЯЗЫКАХ В РЕСПУБЛИКЕ ТАТАРСТАН

За последние годы в Республике Татарстан осуществлены практические меры по достижению реального двуязычия.* В процессе работы выявился и ряд факторов, снижающих их эффективность.

---

* Служебное письмо заместителю премьер-министра РТ З. Р. Валеевой.

Одними из основных являются недостаточная разработанность научных основ и механизма функционирования языков в качестве государственных в условиях многонационального государства. В конце 2002 года Государственный Совет Республики Татарстан принял решение о необходимости внесения изменений и дополнений в Закон республики Татарстан «О языках народов Республики Татарстан» и Государственную программу Республики Татарстан по сохранению, изучению и развитию языков народов Республики Татарстан.

На новом этапе осуществления языковой политики в первую очередь требуется проведение комплексных социологических и лингвистических исследований в различных сферах функционирования языков, анализ и прогнозирование языковой ситуации и разработка государственных программ и проектов в области языковой политики на качественно новом уровне. В связи с этим возникает необходимость создания в Татарстане структуры, аккумулирующей имеющийся потенциал по данному направлению и обеспечивающей на этой основе своевременное обновление научной базы и социомониторинговых данных, на которых должна строиться языковая политика республики. Одним из возможных вариантов решения проблемы является создание Центра социальной лингвистики и информационных технологий при АН РТ.

**Задачами Центра являются:**

— **разработка концептуальных основ языковой политики республики;**

— **социологические и лингвистические исследования в сферах функционирования языков на территории Республики Татарстан и в местах компактного проживания татар** (разработка программ, проектов и нормативно-правовых документов, направленных на сохранение, развитие и функционирование языков; прогнозирование языковой ситуации, постоянный мониторинг и подготовка рекомендаций для принятия решений в соответствующих инстанциях);

— **национальная локализация компьютерных систем и разработка пакетов прикладных программ** (концепции, стандарты татарской локализации; татарская локализация продукции различных фирм

— совместная разработка или локализация готового продукта; разработка автоматизированных рабочих мест и пакетов прикладных программ; разработка лингвопродукции — словарей, форматированных и неформатированных текстов);

— **теоретические и прикладные проблемы компьютерной лингвистики** (создание машинного фонда татарского языка, разработка компьютерной концептуально-функциональной модели татарского языка; компьютерное лингвистическое моделирование).

**Структура Центра,** исходя из перечисленных задач, может включать следующие направления (сектора): языкового планирования, социолингвистического мониторинга, компьютерных лингвистических разработок, машинного фонда языков народов РТ. Численность штатных научных кадров при различных вариантах структуры и различных объемах задач на данном этапе может составлять от 14 до 21 специалиста.

Организация, способная выполнять перечисленные задачи на данном этапе, может быть создана **на базе Совместной научно-исследовательской лаборатории «Проблемы искусственного интеллекта» Академии наук Татарстана и Казанского госуниверситета**.

*2003*

## ТЕЛЛӘРНЕ ҮСТЕРҮГӘ МОНДЫЙ КАРАШ БАШКА ТӨБӘКЛӘРДӘ ЮК УЛ

— *«Татарстан Республикасы халыклары телләре турында»гы Закон кабул ителүгә 10 елдан артык вакыт үтте. Ким әфәнде, шушы еллар дәвамында нинди нәтиҗәләргә ирешә алдык дип саныйсыз?**

— 80 нче еллар ахырында ук республиканың үз мәнфәгатьләрен кайгырткан законнар кабул ителә башлады. Гомумән, ул чорда Советлар Союзындагы атмосфераны тел проблемасы аша үзгәртүгә кискен омтылыш ясалды. Ник дигәндә, тел мәсьәләсе — барлык халыкларга да кагыла торган чара. Ул милләтне үстерүнең бер чаткысы иде. Шулай итеп, 1992 елда «Татарстан Республикасы ха-

* Әңгәмәдәш — журналист Әгъзам Фәйзрахманов.

лыклары телләре турында» Закон кабул ителгәнгә кадәр үк җәмгыятьтә, шул исәптән безнең республикада да тел мәсьәләсе шактый нык куерды.

Ун ел дәвамында башкарылган эшләрне ничек бәяләргә? Монда инде программада урын алган һәр чарага, аларның үтәлү-үтәлмәвенә бәя бирергә була. Тел мәсьәләләрен фәнни яктан тикшерү, татар телен дәүләт теле дәрәҗәсенә җиткерү юллары, белем бирү, компьютерлык технологияләре һәм күп кенә башка нәрсәләр хакында тәфсилләп сөйләргә мөмкин булыр иде. Миңа калса, соңгы 10—12 ел эчендә җәмгыятьтә тел мәсьәләсе шактый югары дәрәҗәгә күтәрелде, аңа игътибар артты. Ике дәүләт теленә дә тиешле игътибар биреп, җәмгыятьтә бер-береңне аңлап яшәү рәвешенә киленде. Ике һәм аннан да күбрәк телләрнең үзара аңлашып яшәү мөмкинлегенә бик күпләр инанды. Без шушы бик катлаулы, җаваплы чорны уздык.

Закон кабул ителгәнче үк, ул нәрсәгә китерер, дигән шикләнү дә, курку да бар иде. Вакыт кабул ителгән законның да, дәүләт тарафыннан алып барылган сәясәтнең дә шактый үлчәнгән, нигезле булуын күрсәтте. Без программада каралган барлык юнәлешләр буенча билгеле дәрәҗәдә уңышларга ирешә алдык. Әлбәттә, куелган бурычлар тулы күләмдә үтәлеп җитмәде. Бу программа гомумроссия күләмендәге хәлләргә турыдан-туры бәйле.

90 нчы еллар башында Россиядә бик җитди документлар кабул ителде: телләр турындагы Закон, Россия халыкларының телләре турында Декларация, Россия Федерациясе Югары Советының 1991 елда кабул иткән карары бигрәк тә зур өмет уяткан иде. Анда бик мөһим әйберләр язылды. Телләр турындагы концепцияне, 1992 елның 1 декабренә кадәр телләрне үстерү турындагы программаны эшләп бетереп кабул итәргә кирәк иде. Телләр турындагы Законны гамәлгә ашыруга багышланган бу программа барлык телләрне үстерүне күздә тота иде. Милли мәсьәләләр буенча дәүләт комитетына программаны гамәлгә ашыру юнәлешендә аерым структура барлыкка китерү, Россия халыклары телләре институтын, тәрҗемәчеләр буенча дәүләт хезмәте төзү планлаштырылды. Кызганыч ки, ун ел вакыт үтсә дә, санап үтелгән чараларның берсе

дә гамәлгә ашмады. Бүгенге көндә Россиядә депутатлар, галимнәр, гомумән, җәмәгатьчелек тарафыннан бу концепциянең барлыгын телгә алучы да юк.

*— Казанга рәсми визиты вакытында Россия Президенты Владимир Путин болай дигән иде: «Әгәр кайдадыр милли телне өйрәнүне тыялар икән — тулысынча ахмаклык һәм зыян бу. Дөньяда башка беркайда да телләргә бездәгедәй байлык юк, моның белән горурланырга кирәк». Ләкин Россиядә сүз белән эш шактый аерыла шул.*

— Ун ел элек кабул ителгән документларны «онытып», аларны күрмәмешкә салышу тел мәсьәләсен шактый четерекле хәлгә әверелдерде. Татарстанда исә телләрне үстерү буенча 1994 елда кабул ителгән программа, җитәрлек күләмдә үк булмаса да, өзлексез рәвештә финансланып килә. Бераз гына булса да, елдан-ел аны финанслау өчен акчасы да арта. Телләргә карата мондый мөнәсәбәтне Россиянең башка төбәкләрендә күргәнем юк минем.

1996 елдан башлап, хөкүмәттә шушы мәсьәләләр белән шөгыльләнүче махсус бүлек эшли. Ул барлык министрлыклар белән элемтә тота, координация эшен башкара. Әлбәттә, өч кешедән торган бүлек бөтен мәсьәләләрне хәл итеп бетерә алмый. Ләкин урыннарда да эшлиләр. Күпчелек шәһәрләрдә шулай ук тел мәсьәләләре буенча махсус бүлекләр төзелде. Мәсәлән, Казан хакимиятендәге шундый бүлек актив эшли. Финанс белән тәэмин итү өчен «Өмет» фонды оештырылды. Шәһәр хакимияте, мәсьәләнең мөһимлеген аңлап, телне, мәдәниятне үстерүдә бюджет керемнәренең бер проценты күләмендә акча бүлеп бирде. Шул рәвешле эзлекле сәясәт алып барыла. Ә Россия хөкүмәтендә тел мәсьәләләре белән шөгыльләнүче структура бөтенләй юк. Берәр сорау килеп чыкса, кемгә мөрәҗәгать итәргә белмисең. Координация булырга тиеш бит югыйсә, һәр төбәкнең үзе белгәнчә генә эшләп утыруы дөрес нәрсә түгел ул. Россия күләмендәге сәясәткә анализ ясап, шушы юнәлешне бергәләп алып барганда гына тиешле нәтиҗәгә ирешергә мөмкин.

Менә шул рәвешле узган ун елны төрлечә бәяләп була. Федераль дәрәҗәдә бу мәсьәләгә игътибар юк икән, тормыш куйган катлау-

лылыклар да һәрвакыт чыгып тора. Шул сәбәпле һәр нәрсәне тиешле дәрәҗәдә үк хәл итеп бетерә алмыйбыздыр әле.

— *Икетеллелекнең мөһимлеген аңлау буенча кешеләр психологиясендә бераз үзгәрешләр бармы?*

— Әйткәнемчә, телләрнең бер-берсе белән яраклашып, аңлашып яшәве шактый зур нәтиҗәләр бирде. Тел мәсьәләсен уңай хәл итү бары акчага гына бәйле түгел бит. Кешеләрнең психологик барьерны, киртәләрне үтеп чыгуы, бу проблемаларны аңлаулары — иң зур казанышларыбызның берсе. Бүген балаларның 99 проценты татар телен дәресләрдә дәүләт теле дәрәҗәсендә өйрәнә. Бу да — проблеманы аңлауның бер нәтиҗәсе.

Әмма гомумроссия күләмендәге тел мәсьәләсенә карата сәясәт шулай ук үзенең тискәре йогынтысын ясамый калмый. Татарстан Президенты дәүләт теле саналган ике телне дә (шул исәптән татар телен дә) белергә тиешме, юкмы дигән мәсьәлә федераль дәрәҗәдә куела икән, бәхәс судка чыгарыла икән, әлеге проблемага кайберәүләрнең шикләнебрәк караулары, фикерләрен тиз генә үзгәртә алмаулары табигый хәл. Алга таба да хөкүмәт кешеләренең, министрлыкларның, мәгариф системасының, журналистларның бу мәсьәләгә игътибарны арттыра төшүенә, халык фикеренең тотрыклылыгына ирешүгә бик җитди карарга кирәк.

— *Россиядә үзәкләштерү сәясәте бара, без моны һәр адымда тоябыз. Беренчедән, ул финанс мәсьәләләренә кагыла. Чөнки акчасыз эшләү бик авыр. Шушы шартларда хакимият органнарының татар телен, республикада яшәүче башка халыкларның телләрен саклап калуга, үстерүгә ышанычлары бармы?*

— Тел сәясәте дәүләт сәясәтенең аерылгысыз өлеше. Телгә мөнәсәбәт үзгәрә икән, димәк, дәүләт сәясәте дә үзгәрергә, башка юнәлеш алырга тиеш. Тел проблемасына, милли мәдәнияткә, гомумән, милли мәсьәләгә демократик федераль дәүләттә тиешле игътибар булдырырга кирәк. Бу — бердәнбер дөрес юл.

Әйткәнемчә, бүгенге көндә Дәүләт программасын үтәүгә акча бирелә тора. Мәсьәләнең икенче ягы да бар. Безнең югары уку йортлары, фәннең аерым тармаклары, кайбер башка юнәлешләр феде-

раль структуралаларга буйсына. Шулар аша Мәскәүдән акча алу, аны файдалану турында уйларга кирәк. Моның өчен норматив-хокукый мөмкинлекләр дә бар. Кызганыч, без бу юнәлешне тиешле дәрәҗәдә файдаланып җиткермибез әле. Татар телен үстерергә Мәскәү рөхсәт бирми, комачаулый, дип зарланып йөрүдән файда юк. Үзебез башкара ала торган чаралар да күп әле.

*— Федераль максатчан программалардан да Татарстан өчен өлеш чыгарырга була.*

— Әлбәттә. Финанс мәсьәләсендә дә. Гомумән алганда, киләчәккә таба безнең ышаныч бары үзебездән тора. Мәскәү безгә бернинди рецепт бирмәячәк.

*— Татар теле чын мәгънәсендә дәүләт теле булып әверелмәде әле. Дәүләт оешмаларында ул тиешле дәрәҗәдә кулланылмый. Документларның күпчелеген бары рус телендә генә әзерлиләр.*

— Беләсезме, эш кәгазьләрен, бөтен күргәзмә такталарын тиешенчә башкарып чыгу һәм, гомумән, тел сәясәтен нигезле, эзлекле рәвештә алып бару өчен программаның норматив-хокукый дәрәҗәсен көчәйтергә кирәк. Минемчә, программаның бик зәгыйфь урыны бар. Аның алдында бернинди концептуаль аңлатма, кереш юк. Әйтик, нәрсә ул тел сәясәте? Аның төп максатлары нәрсәдә? Бурычлары нидән гыйбарәт? Программаны үтәү механизмы нинди? Менә шушы сорауларга анда җаваплар салынмаган.

Законның һәр пунктын үтәү өчен норматив-хокукый документлар эшләргә кирәк. Мәсәлән, Конституциянең һәр маддәсен диярлек ничек үтәргә кирәклеген аңлатучы законнар, нигезләмәләр бар. Дәүләт программасын әзерләгәндә андый эш башкарылмаган. Норматив-хокукый базаны ныгыту, аны үстерү юнәлешендә программага тулы бер бүлек керми калган. Без хәзер менә шуны эшлибез.

Башта соңгы ун елда нинди эшләрнең тиешле дәрәҗәдә башкарылмавын, моның сәбәпләрен өйрәнәбез. Аннары максат һәм бурычларны, төп юнәлешләрне ачыклыйбыз. Татар теленең үз проблемасы булган кебек, рус теленең дә борчу-проблемалары бар.

Бүгенге көнгә кадәр без аны аерып куюны кирәк тапмаган идек. Чоры да шундый иде. Хиснең алгы планга чыгуы комачаулык итте. Аннан инде Татарстанда тупланып яшәүче халыкларның телләре һәм читтә яшәүче милләттәшләребез проблемалары.

— *Бу яңа программа булырмы, әллә элеккеге программага төзәтмәләр кертелерме?*

— Дәүләт Советы каршында «төзәтмәләр кертергә» дип язылган иде. Әмма бу инде төзәтмәләр генә булмый. 2004—2013 елларга «Татарстан халыклары телләре турында»гы Законны үтәү буенча Дәүләт программасы була.

— *Гамәлдәге программаның вакыты күрсәтелмәгән иде булса кирәк.*

— Күрсәтелмәгән иде. Без телләр мәсьәләсенә кагылышлы федераль һәм халыкара законнарны өйрәнеп чыктык. Хәзер күргәзмә мәгълүмат чараларында, матбугатта, радио-телевидениедә, эш кәгазьләрендә, нәшрият һәм реклама эшчәнлегендә татар телен куллану буенча норматив-хокукый мәсьәләләрне көйләүче нигезләмәләр эшлибез. Ул нигезләмәләрдә телләрнең кайда, ничек кулланылырга тиешлеге ачык күрсәтелгән булырга тиеш. Терминнар стандарты булдыру буенча шулай ук нигезләмә кирәк. Мәгариф, урта һәм югары һөнәри белем бирү юнәлешендә дә концепция эшлисебез бар. Бөтен дөнья тәҗрибәсен өйрәнеп, татар телен куллануның перспективалары өйрәнелә. Әйтик, мәктәптә татар телендә белем биреп чыгарабыз икән, киләчәктә ул белемне ни дәрәҗәдә кулланып булачак? Менә бу проблемаларның барысын да безнең ныклап торып өйрәнәсебез бар.

Дәүләт телләрен тигез дәрәҗәдә куллану мәсьәләсен өйрәнеп, бик күпләр Канаданың Квебек провинциясенә барып кайттылар. Анда әйбәт, диләр. Документлар белән ничек эшләүләре турында кызыксындым. Әйтик, һәр документ ике телдә аерым кәгазьләрдә тутырыламы, әллә инде бер үк битнең бер ягында бер телдә, икенче ягында икенче телдә языламы? Беркем дә җавап бирә алмады. Һәр нәрсәнең технологиясен, механизмын өйрәнергә кирәк.

Документлар белән эшләү — катлаулы проблема ул. Әгәр бүген

һәр кәгазьне ике телдә эшлисең икән, чыгымнар да икеләтә арта. Мәскәү белән мөнәсәбәтләрдә, башка төбәкләр белән аралашканда ике дәүләт телен тигез дәрәҗәдә ничек кулланырга? Бу мәсьәләләрне бик ашыктырып хәл итеп булмый. Ул дистә елларга сузылырга мөмкин.

Менә шул ук Квебекны алып карыйк. Бер караганда анда барлык мәсьәләләр бик тиз хәл ителгән кебек. Әгәр тарихка әйләнеп кайтсак, тел мәсьәләләре белән анда 60 нчы ел урталарыннан ук дәүләт дәрәҗәсендә шөгыльләнүләрен күрәсең. Дистәләрчә норматив документлар, программалар кабул ителгән инде. Аларда француз теленең сүзлеген чыгару, аның терминологиясен эшләү проблемасы юк. Дөньяда иң бөек дәүләтләрнең берсе булган Франция бөтен нәрсәне эшләгән инде. Программалар, дәреслекләр җитәрлек. Андый проблемалар күптән хәл ителгән булуга карамастан, Квебекта әле һаман инглиз, француз телләренең яраклашып эшләү юлларын эзлиләр. Ә без барлык мәсьәләләрне тиз арада хәл итәргә телибез. Милләт яши икән, тел проблемасы да булачак. Суверенлык белән бәйле рәвештә генә барлыкка килгән проблема түгел ул.

*— Вертолет, авиация, моторлар төзү берләшмәләре кебек эре предприятиеләрдә татар теле бөтенләй кулланылмый диярлек. Андый заводларга йогынты ясау механизмын табып буламы? Сез аларга: «Нигә Законны үтәмисез?» дип бәйләнә аласызмы?*

— Бәйләнеп була, әмма закон нигезендә генә. Күптән түгел Татарстанның Административ кодексы кабул ителде. Мәсьәләне хәл итү юнәлешендә ул этәргеч бирер дип уйлыйм.

*— Административ кодекста Татарстан халыкларының телләре турындагы Законны бозган өчен җәза бирү турында аерым маддә бар. Әйтик, теленә карап, гражданнарның хокук һәм ирекләрен кысу, рәсми документларны тупас хаталар белән чыгару, юл хәрәкәте билгеләрен дөрес язмау кебек гамәлләр өчен җавапка тартылучылар бармы?*

— Миндә андый фактлар юк. Минемчә, башта законны бозган өчен җавапка тарту механизмын халыкка аңлатырга кирәк. Аннан соң инде андый гамәлләр өчен җавапка тартуны таләп итүчеләр барлыкка килер.

*— Латинга күчү — шулай ук тел мәсьәләсе. Бу проблемага карата мөнәсәбәтегезне белдерсәгез иде.*

— Чыннан да, бу катлаулы мәсьәлә булып чыкты. Ул сәясиләштерелде. Шул сәбәпле катлаулана төште. Болай да ул гади проблема түгел иде. Миллионлаган халыкның язуын алыштыру авыр нәрсә. Монда мәсьәләгә хокукый яктан якын килү сорала. Без балаларга латин графикасын өйрәтүне дәвам итәбез. Балалар өчен 8—10 мең тираж белән шактый китап чыгардык. Латин графикасына күчү, беренчедән, аның тел үзенчәлекләренә туры килү-килмәвенә бәйле. Икенчедән, төрки дөнья бар бит әле. Төрки дөнья инде латинга күчеп бетте дияргә була. Азәрбайҗаннар, үзбәкләр, төрекмәннәр күчтеләр. Казахстанда һәм Кыргызстанда бу проблема өйрәнелә. Башкалардан аермалы буларак, бу ике республикада рус телле халыклар саны шактый күп. Кыргызларда да, казахларда да үз телләрен белү дәрәҗәсе түбән.

Кыргызстанда, кыргыз теле белән беррәттән, рус телен дә кабат дәүләт теленә әверелдерү — кыргыз теленең ни дәрәҗәдә авыр хәлдә булуын раслаучы факт. Моны рус теленә хөрмәт күрсәтү дип кенә аңларга ярамый. Кыргыз теле тиешенчә дәүләт теле дәрәҗәсенә күтәрелә алмады әле. Словения, Болгария кебек славян дәүләтләрендә дә әкренләп латин графикасына күчү мәсьәләсе куела. Бездә дә латинга күчүне Россия үткәрә торган сәясәт белән генә туктатып булмый дип уйлыйм. Гомумән алганда, ул инде көн тәртибеннән төшмәс тә.

*— Безгә туктап калырга ярамый.*

— Ярамый. Барыбер графиканы, язуны камилләштерергә кирәк. Бу проблема русларның үзләрендә дә бар.

Кайберәүләр, нигә бу проблеманы татарлар гына күтәрә соң, дип гаҗәпләнәләр. Миңа калса, аны көн тәртибенә кую өчен бик зур көч, республиканың, халыкның фәнни, икътисади мөмкинлекләре булырга тиеш. Шунлыктан, башкарып чыгуларына ышанмагач, аны кайберәүләр кузгалтмыйлар да.

*— Телләр турындагы Законны гамәлгә ашыру өчен, Казан шәһәре бюджеты керемнәренең 1 проценты файдаланыла. Республика күлә-*

*мендә дә шулай эшләп буламы? Бүген, яңа программа эшләүдән тыш, хөкүмәт алдында нинди бурычлар тора?*

— Казан гына түгел, кайбер башка шәһәрләр дә 90 нчы еллар урталарыннан Законны гамәлгә ашыруга акча бүлеп бирәләр. Ләкин бу эш планлы төстә, закон нигезендә алып барылмый. Гомумән, тел мәсьәләсен хәл итүне милләт үсеше, милләтнең киләчәге, яшәү рәвеше белән бәйләп карарга кирәк. Бүгенге көндә безгә аналитик эш белән шөгыльләнү зарур. Дөнья күләмендә татарның үсеш перспективалары нинди? Россия төбәкләрендә алар ничек яши? Мәктәпләре бармы? Булса, аларны саклап калу өчен нәрсәләр эшләргә кирәк? Телне саклап калу, үстерү механизмнарын өйрәнергә, моның өчен күпме акча кирәк булуын ачыкларга. Боларның барысын фәнни нигездә тикшереп, җавап табу зарур.

Татарстаннан читтә яшәүче татарлар мәсьәләсе тагын да катлаулырак. Федераль органнар белән тиешле аңлашуга барып, мәсьәләгә дөрес диагноз куярга кирәк. Табиблар да эшне шуннан башлый бит. Диагноз дөрес куелса, тиешле дәва да табылыр.

*2003*

## ЙӨЗЕБЕЗ ЮГАЛМАСЫН!

Март башында Чаллыда «Модернизацияләү шартларында тел фәннәрен укыту: тәҗрибә, эзләнү, проблемалар» дигән темага республикакүләм фәнни-гамәли конференция үткәрелде. Анда Казан, Кама аръягы регионы вәкилләре белән бергә Ижау, Липецк һәм башка төбәкләрдән дә дәүләт һәм фән эшлеклеләре, укытучылар катнашты. Конференциядә милли мәгариф системасы үсеше һәм дәүләт телләрен гамәлгә кертү юнәлешендә татар теле укытучыларының роле тикшерелде.

— *Ким Мөгаллимович, сүзебез — республикадагы бүгенге милли мохит, милли мәгариф мәсьәләләре хакында. Ә үзебез еш кына 90 нчы еллар башындагы милли күтәрелешне сагынып искә алабыз...**

— Сүз дә юк, 1990 еллар башында СССР дәүләте таркалу нәти-

* Әңгәмәдәш — журналист Лариса Яруллина.

җәсендәге үзгәрешләр Россиядәге милли республикаларга да ифрат зур тәэсир ясады. Гомумән, үзебезне милләт буларак саклау, гореф-гадәтләребезне кайтару мөмкинлеге туды. Федераль үзәк тарафыннан телләр турында хокукый-норматив документлар кабул ителде. Аннан соң алар Татарстанда һәм башка милли регионнарда да барлыкка килде. Болар барысы да милли мәсьәләләрне хокукый яссылыкта чишүгә омтылыш булды. Ниһаять, боз урыныннан кузгалды һәм демократик җәмгыять төзүгә йөз тоткан дәүләттә мондый адымнар бик уңай күренеш дип бәяләнде.

Шушы үзгәрешләр барышында татарлар илдә сан ягыннан икенче урындагы халык булып әверелде. Татарстан да үзенең икътисади, фәнни, мәдәни потенциалы ягыннан Россиядә әйдәп баручы республика буларак танылды.

Әлеге чор татар халкы алдына катлаулы мәсьәләләр дә куйды. Әйтик, миллион ярым тирәсе милләттәшебезнең чит илләрдә торып калуы — иң зур югалтуларның берсе. Чөнки бүгенге көндә РФ, Федераль үзәк БДБ илләрендә яшәүче халыкларның борчу-проблемаларына берьяклы гына карый. Алар бары тик рус телле гражданнар мәнфәгатен генә кайгырта — рус телен саклап калу турында гына сүз алып бара. Димәк, безнең чит илдәге милләттәшләребез турында федераль дәрәҗәдә кайгырту булыр дигән ышаныч юк әлегә.

2002 елгы халык санын алу мәгълүматларына күз салсак, тагын да бер мәсьәләгә игътибар итәргә кирәк: бүген Россия халкының 80 процент тирәсе — руслар, 20 проценты — башка милләт вәкилләре. Элекке СССР дәүләтендә халык санының яртысын рус булмаган милләтләр тәшкил итә иде. Шуннан чыгып, дәүләтнең Югары Советында милләтләр палатасы эшләп килде. Бүген исә Россиядә милләтләр палатасы булдыру түгел, хәтта милли мәсьәләләр буенча министрлык та юкка чыгарылды. РФнең яңа хөкүмәтендә бу мәсьәләләрнең Мәдәният һәм массакүләм коммуникацияләр министрлыгы карамагына күчүе турында мәгълүмат бар. Милли мәсьәләләргә игътибарның сүлпәнәю тенденциясе, әлбәттә, бездә борчылу уята.

Әмма, ни генә булмасын, Татарстанның абруе инде башка. Аның дәрәҗәсе күзгә күренеп күтәрелде. Дөньяга танылуда, чит

илләр белән бәйләнешләрне ныгытуда, әлбәттә, Президентыбызның олы шәхес булуы зур роль уйнады. Гомумән, милләт, тел, дин мәсьәләләренең Федераль үзәк күз уңыннан төшеп калмавы — Татарстанның шул юнәлештәге актив эшчәнлеге нәтиҗәсе.

Бай тарихыбызны, милли традицияләребезне, бүгенгебезне саклап калырга, тагын да камилләштерергә телибез икән, үз тавышыбызны, җан авазыбызны мөмкин кадәр көчлерәк, нигезлерәк ирештерү юлларын эзләп табарга кирәк. 90 нчы еллар дәвамында яуланган позицияне, абруйны югалтмыйча, тагын да көчәйтү хакында уйлансак иде. Республикабызда һәм чит төбәкләрдә яшәгән зыялы затларыбызны, милләттәшләребезне туплап, берләштереп кенә максатыбызга ирешә алырбыз.

— *Икетеллелек программасын тормышка ашырабыз дип күп сөйлибез дә...*

— Соңгы дистә елда, чыннан да, республикабызда телләр мәсьәләсенә игътибар шактый артты. Байтак эшләр башкарылды. Шушы бихисап эш-гамәлләребез халкыбызның киләчәген кайгыртырлык дәрәҗәдәме? Барлык мөмкинлекләр файдаланылдымы? Узган этапны ничек бәяләргә?

1992 елда расланган телләр турындагы Закон әле дә үз көчендә. Алай гына да түгел, ТР Дәүләт Советы үзенең соңгы утырышларында Законга без әзерләп тапшырган өстәмәләрне дә, 2004—2013 елларга исәпләнелгән яңа программаны да кабул итте. Монда беренче чиратта өстәмә норматив-хокукый документлар эшләү каралган. Бер генә эш тә үгет-нәсыйхәт аша, өстәл сугып яисә энтузиастлар көче белән генә тиешле дәрәҗәдә башкарыла алмый, һәрбер гамәл законга нигезләнергә тиеш. Дөньяда һәм Россиядә барган тенденцияләрне өйрәнеп, тел сәясәтенең барлык юнәлешләре буенча да норматив база булдыру мәслихәт.

Шулай ук һәр өлкәдә проблеманы тирәнтен аңлаучы һәм киләчәкне ачык күзаллаучы милли белгечләр әзерләү — көнүзәк мәсьәлә. Кызганыч, бу өлкәдә заман таләпләренә җавап бирердәй кадрлар җитәрлек түгел әлегә. Узган ун-унике ел эчендә телләрне үстерүдәге уңышларыбызның күбесенә экстенсив, ягъни сан ягын-

нан арттыру юлы белән ирешелде. Татар телен тиешенчә яңгырату өчен, милли кадрлар мәсьәләсен ныклап хәл итәсе бар әле. Чөнки кайсы гына аудиториягә керсә дә, татар укытучысы профессиональ яктан да, кеше буларак та, туган телен белү дәрәҗәсе ягыннан да үрнәк булырга тиеш. Укытучы — милләт көзгесе, дип юкка гына әйтмиләр.

*— Сер түгел, мәктәпләрдә татар сыйныфлары ачу эшендә кыенлыклар күп...*

— Дөрестән дә, бу — күпләрне борчыган мәсьәлә. Аерым ата-аналар балаларын татар сыйныфларында укытырга теләми. Югары уку йортларында югалып калырлар, дип уйлыйлар... Гәрчә, ана теленә мәхәббәт, мәктәптән бигрәк, нәкъ менә гаиләдә уянырга, тәрбияләнергә тиеш булса да.

Димәк, безгә әлеге мәсьәләне җентекләп тикшерергә һәм аны хәл итү юлларын эзләргә кирәк. Бүгенге татар мәктәпләренең киләчәге нинди? РФ шартларында милли мәгариф нинди булырга тиеш? Болар — татар мәгарифчеләрен һәр дәвердә борчыган сораулар. Бүген шунысы ачык: безгә татар мәктәпләрендә белем һәм тәрбия бирүнең концептуаль нигезләрен тудырырга кирәк. Аларны тәмамлаучыларның белеме үзләре теләгән югары уку йортына кирәрлек дәрәҗәдә камил булырга тиеш.

Аннан соң, ана телен белү-белмәүләренә карамастан, шәһәрдә туып үскән милләттәшләребезгә таянып, аларның гыйлем һәм тәҗрибәсен тиешенчә файдаланасы иде. Аларның милләтебез өчен эшләү теләкләрен сүндермик.

Үзебезгә читтән карап, объектив, аек бәя бирергә өйрәнсәк, милләтебезне һәм ана телебезне ихластан яратсак кына киләчәгебез өметле булыр.

*2004*

## ТАТАРНЫҢ ТАЛБИШЕГЕ

*— Ким Мөгаллимович, Сез бәхетле, Сез җырдан-моңнан үрелгән «Талбишек»ләрдә тибрәнеп үскәнсез. Яраткан шагыйребез Роберт Миңнуллинның асыл мәгънәле әлеге шигыре Сезгә дә карыйдыр, дим.*

*Ә менә яңа гасырда, яңа дәвердә татар баласын андый бишекләрдә үстерә алырбызмы? Сезнең карашка мөмкинлекләребез нинди?**

— Без гасырлар дәвамында татар булып яшәп киләбез икән, димәк, киләчәгебез дә бар. Соңгы ун-унбиш елда ул дөньяда үзенең көч-гайрәтен күрсәтә алды, үзенең олы халык икәнен раслады. Әгәр дә безнең җырлы-моңлы талбишекләрдә үскән улларыбыз, кызларыбыз булмаса, без Россия шартларында, гомумән, үз дәүләте булмаган халыкларга карата кырыс, кискен бу дөньяда юкка чыгу ихтималын да инкарь итә алмас идек. Бер яктан, элекке тамырларыбыз нык, икенче яктан, без көткән, без өмет иткән кадәре булмаса да, сөенерлек ул-кызларыбыз бар. Алда әле тагын да зуррак имтиханнар тотарга туры киләчәк халкыбызга.

*— Сез моны глобальләштерү проблемаларын күздә тотып әйтәсезме?*

— Чыннан да, дөнья алга таба үзенең дәүләте булмаган халыклар белән санлашып тормаячак, аның кире тәэсире үзен нык сиздерәчәк. Кайберәүләр, глобальләштерү элек тә барган, хәзер дә барачак, ди. Әмма XX гасыр дәвамындагы глобальләштерү соңгы унбиш-егерме ел эчендәге үзгәрешләр белән һич тә чагыштырырлык түгел.

*— Димәк, соңгы ун ел эчендә мөстәкыйль дәүләтләрдә телләрнең статусын билгеләү, аларга дәүләт телләре статусы бирүнең киң таралуы да шуның белән аңлатыла?*

— Бу чыннан да шулай. Һәм ул тел, мәдәният мәсьәләләрендә аеруча нык чагыла. Дәүләт теле статусы бирелү — шушы телнең рәсми танылуы дигән сүз ул. Аңа барлык мөмкинлекләр тудырыла. Хөкүмәт, дәүләт тулысы белән шушы телдә эшли. Бу тел башка телләрдән нык аерылып тора. Дәүләт теле статусы алмаган телләрнең хәле исә кискен рәвештә начарлана. Чөнки дәүләтнең мөстәкыйльлеген саклау, дәүләтнең үз йөзен булдыру, дөньяда башка дәүләтләр белән аралашу шушы телләрнең дәрәҗәсен үстерү белән бергә бара. Әгәр дә Россияне һәм рус теленең Россиядәге хәлен

* Әңгәмәдәш — журналист Филисә Хәкимова.

алсак, соңгы елларда Федераль үзәк нык борчылу кичерә. Һәм инде ул төрле норматив документлар аша аның статусын күтәрүгә, саклауга, яклауга зур көч куя башлады. Соңгы вакытларда Федераль үзәк тарафыннан рус телен Россия территориясе җирлегендә генә түгел, бүгенге БДБ илләрендә, элекке союздаш республикаларда да саклап калу сәясәте алып барыла. Алай гына да түгел, бу сәясәт чит илләрдә рус теленең статусын күтәрүгә дә карый. Шушы шартларда Россиядәге башка телләрнең хәле авырлаша бара.

*— Бу шаукым безнең татар теленә турыдан-туры кагыла, шулай бит инде?*

— Татарстанны мисал итеп, аның соңгы ун-унбиш ел эчендә телне саклау һәм үстерү өлкәсендә башкарган эшләрен, кабул иткән норматив документларын, Конституциянең аерым маддәләрен алып карасак — һәрберсенә диярлек һөҗүм бара.

Төрле милләт вәкилләре — алар барысы да Россия халкы. Һәм бу халыкларны, аларның телләрен саклап калу һәм үстерүгә исәпләнгән программа, фәнни-теоретик карашларны чагылдырган концептуаль документларның кабул ителгәне юк, шунысы гаҗәп.

*— Димәк, җаваплылыкны үз өстебезгә алып, бу документларны безнең үзебезгә эшләргә, юлларны үзебезгә табарга кирәк була?*

— Билгеле, Федераль үзәккә үпкәләп, зарланып кына утырсак, бу мәсьәләне хәл итеп булмаячак. Аны чишәргә, хәл итәргә беркайчан да, беркем дә алынмаячак. Без бүгенге ситуацияне ничек бар шулай кабул итәргә һәм, шушы чынбарлыктан чыгып, үз адымыбызны ясарга, хәлебезне анализларга тиешбез.

*— Бүгенге чынбарлыкка, телебезнең бүгенге хәл-хәятенә бәя бирүләр төрле. Сезгә аның уңыш-табышлары да, югалтулары да күренәрәк төшә.*

— Күбрәк күргән саен, күбрәк белгән саен тынычсызлык арта бара: уйланмаган бер көн, бер сәгать юк, шуның белән яшисең. Тугызынчы ел инде. Эшкә тотынганда буш урында, буш өстәлдән диярлек башладык, һәм кабул ителгән берничә документ бар иде.

Өч-дүрт елдан соң гына махсус бүлек төзүгә ирештек. Моның кадәр мәгълүмат, моның кадәр китаплар, республикадагы тел сәясәтенә караган, тел ситуациясен өйрәнә алырлык мәгълүматларның, документларның туплануы — ул инде үзе зур бер казаныш. Чыннан да, зур эшләр башкарылды һәм, минем аңлавымча, соңгы ун-унике ел эчендә Татарстан милли мәсьәләләргә, телгә бәйле юнәлештә зур бер тарихи этап узды, XXI гасырга зур тәҗрибә туплап керде.

20—30 нчы елларның беренче яртысында әлеге мәсьәләләр белән дәүләт дәрәҗәсендә шөгыльләнгән шундый чорыбыз булган инде. Әмма бүгенге ситуация, бүгенге шартларыбыз белән чагыштырганда, ул башка, аны чагыштырып та булмыйдыр, чагыштыру ярамыйдыр да. Мин бу мәсьәләне һәрвакыт анализларга тырышам.

Әлбәттә, бәя бертөсле генә түгел, дөресен генә әйткәндә, мин үзем дә аның бик күп җитешмәгән якларын күрәм, бәлки башкаларга караганда күбрәк тә күрәмдер, сәбәпләрен дә, нинди юл белән барып булырын да ачыграк күрәмдер. Без бирелгән мөмкинлекләрдән файдаланып бетерә алмадык. Тел сәясәтен республикадагы бүгенге шартларга җавап бирерлек дәрәҗәгә үстереп җиткерә алмадык. Аның сәбәпләре күп.

— *Алай да кайберләрен аерып әйтергә мөмкинме?*

— Күпмедер вакытлар элек без беренче урынга финанс мәсьәләсен куя идек. Хәзер дә шулай исәпләүчеләр күп. Мин монда бераз эшләгәннән соң шундый нәтиҗәгә килдем: беренче урында акча түгел, ә кадрлар мәсьәләсе тора икән ич. Кадрлар бар икән, мәсьәләнең бик күбесен хәл итәргә була. Шушы акыллы кадр кирәк акчаны да таба белә, барын да дөрес файдалана ала.

Бүгенге хәлебезнең без көткәнчә булмавы да шушы факторлардан килә. Әлбәттә, монда финанс мәсьәләсен дә читкә куярга ярамый, ул да шушы рәтләрдә. Ләкин фәннең тулысы белән әлеге проблемаларга борылып бетә алмавы янәдән кадрларга барып тоташа. Чөнки кабул ителгән законнар гына түгел, аларның һәр маддәсен эшләтерлек итеп өстәмә норматив документлар эшләү зарур.

Инде проблеманың тагын да зуррагы — ул Россиядәге шартлар. Без аларны исәпкә алмыйча гына гомер кичерә алмыйбыз.

Әмма аларга карап, нәрсәдер көтеп кенә утыру дигән сүз түгел бу. Әйтик, 2004—2013 елларга хөкүмәттә яңа Дәүләт программасы эшләнде. Чөнки ун елга билгеләнгән элекке программаларның инде вакыты тәгәлләнде. Нигездә, ул үтәлде.

Зур проблемаларның тагын берсе — инфраструктура булдыру. Әйтик, тормыш җәмгыять алдына проблемалар куйган икән, аларны хәл итү өчен махсус структуралар барлыкка килергә, һәр юнәлешнең профессиональ белгечләре, тиешле финансы, норматив документлары булырга тиеш. Әгәр боларның барысы булып та, аның тиешле структурасы юк икән, без тагын кыен хәлдә калачакбыз.

Бүгенге көндә, инде әйткәнемчә, без тел сәясәте белән шөгыльләнүче белгечләр тәрбияли һәм булганнарын бердәм көч итеп туплый алмадык. Кемдер: «Ничек инде алмадык, безнең Тел, әдәбият һәм сәнгать институтыбыз бар, югары уку йортларында тел кафедраларыбыз, факультетларыбыз, Фәннәр академиясе бар, алар нәрсә белән шөгыльләнә, алар белгеч түгелме?» дип әйтергә мөмкин.

Бер караганда, чыннан да, структураларыбыз бар. Әмма тел сәясәте, дәүләт телләрен үстерү, татар телен рус теле белән бер тигез дәүләт теле дәрәҗәсенә күтәрү, телнең җәмгыятьтәге яшәү рәвеше кебек мәсьәләләр — алар моңарчы безнең фән өлкәсендә тиешле дәрәҗәдә өйрәнелгән юнәлешләр түгел. Аның үз белгечләре булырга тиеш.

Әгәр дә Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтын алсак, анда лексикология бүлеге, тел белеме бүлеге бар. Андагы белгечләр татар теленең эчке структурасы, эчке законлыклары белән шөгыльләнәләр. Бу бик кирәкле юнәлеш, ул үсәргә, эшләргә тиеш. Тик бу белгечләргә сәяси лингвистика проблемаларын йөкли алмыйбыз. Университетта да, педагогика уку йортларында да шундый ук хәл. Бу — эшләнеп бетмәгән, гакылыбыз җитеп бетмәгән юнәлешләрнең берсе.

— *Аны кайчан эшләп булачак соң?*

— Аны кичә дә эшләп була иде.

— *Кызганыч, кичәгесе үткән, ә бүген күзаллау мөмкинлеге?*

— Ничек итеп эшләрбез, әлегә төгәл әйтү кыен. Бу мәсьәләләр яңа Программада да урын алды. Дөрес, булган структуралар белән дә эшли торырга кирәк, туктарга ярамый. Шул ук институтларда, факультетларда эшләгән галимнәр һәм яшь белгечләр бүген ихтыяҗы булган темаларга курыкмыйча алынырга тиешләр. Татар теленең функциональ үсеш юнәлешләрен өйрәнергә кем комачаулады безгә? Бер кеше дә тыймады, берәүгә дә үпкәләргә кирәк түгел. Шул ук латин графикасына күчүне карасак та, бармы шушы проблеманың тарихын өйрәнгән, латинга күчкән төрки дәүләтләрнең хәлен, яңа алфавитларның уңайлыкларын, җитешсезлекләрен өйрәнеп, анализ ясап, безнең шартларыбызга туры китереп, бүгенге һәм иртәгесе юлыбызны күрсәтеп, тәкъдимнәр белән баетып эшләнгән саллы хезмәтләребез?!

— *Димәк, канәгатьсезлек һәм борчылыр өчен сәбәпләребез шактый.*

— Мин, инфраструктура дип, юкка гына кат-кат әйтмәдем, алар дәүләт дәрәҗәсендә башкарылырга тиеш. Бик күп эшләр башкарылды, ә русча әйтсәк, прорывка ирешә алмадык... Эшләгән эшләребез күп була торып та, ахырынача җитмәгәннәре дә байтак. Ә безнең потенциалыбыз зур!

— *Ким Мөгаллимович, әйтегез әле, заманында Милли университет ачу әлеге мәсьәләләрне хәл итүнең бер юлы түгел идеме?*

— Мин бу мәсьәләгә карата дүрт-биш еллар элек үз карашымны матбугатта язып чыккан идем. Шушы язмалардан соң «син Милли университетка каршымыни?» дигән сүзләрне дә ишеттем.

Әйтик, җәмгыятьтәге зур үзгәрешләрдән соң, элекке СССР республикаларында да шуңа охшаш проблемалар туды. Белүемчә, бер генә җирдә дә булган уку йортлары янына милли уку йорты ачып, мәсьәләне хәл итү юлына басучылар юк. Барлык республикаларда да, шул исәптән Урта Азиядә дә, булган уку йортларын үзләренеке итү юлы белән баралар. Чөнки аларга милли эчтәлек кенә салырга кирәк.

*— Бу — тулысынча үзебезнеке итә алган очракта шулайдыр?..*

— Мин аны болайрак күз алдына китерәм: бу университет бик кирәк, аның үз йөзе булырга һәм ул бүгенге уку йортларын кабатламаска тиеш. Хәзерге шартлардан чыгып, татарның иртәгесе көнен, дөньяда тоткан урынын исәпкә алып, башка уку йортларындагы милли белгечләрне сайлап, шушы юнәлештә үсәргә тиеш ул. Безнең республикадагы дәүләти булган уку йортларының барысына да планлы рәвештә милли төс салынмаса, безнең берничә милли уку йортыбыз мәсьәләне хәл итми. Боларны икесен бергә, параллель рәвештә алып барырга кирәк. Россиядә генә түгел, БДБ илләрендә һәм, гомумән, дөньядагы югары уку йортларындагы милли белем бирү, милли юнәлешләрнең үсү, үстерү тенденцияләрен өйрәнү зарур.

Әйткәнемчә, Милли университетыбыз да, башка уку йортларыбыз да тамырыннан ук үзебезнеке булырга тиеш.

*— Минем үземә бәхәсләрдә үтеп киткән бу ун ел шактый кызганыч. Инде җимешләрен җыймас идек микән, дим... Тагын дистәләгән елларны югалтмабызмы?*

— Мин югалту булмагандыр дип әйтә алмыйм. Дүрт-биш ел элек бу проблемага якынрак килергә кирәк булгандыр. 1996—1997 елларда татарларда гына түгел, башка милләт кешеләрендә дә шактый матур, рациональ фикерләр бар иде. Ниндидер этапта бу кузгалыш, фикерләр, эзләнүләр сүрелеп калды. Хатабыз менә шундадыр.

*— Килешерсез дип уйлыйм, татар җанын иң борчыганы — ул телебезнең кулланылыш даирәсе, аның тарлыгы.*

— Ул — иң катлаулы мәсьәләләрнең берсе. Монысы турыдантуры хөкүмәт эшчәнлегенә, безгә кагыла. Әйткәнемчә, телнең функциональ кулланылыш механизмнарын булдыру зарур. Өстәл сугып кына бөтен язуларны да, бөтен эш кәгазьләрен дә ике телгә әйләндерү мөмкин түгел. Энтузиазм белән генә дә эш барып чыкмый. Ни өчен шушы вакыт эчендә аның механизмнары уйланып табылмаган дип әйтергә мөмкиннәр. Хаклы

сорау. Яңа Программа турында әйткән идем инде. Бу сөйләшкән сүзләрнең, җитешеп бетмәгән эшләрнең бик күбесе яңа Программага салынды.

Программа кабул ителеп, алга таба шуның нигезендә эш алып барабыз икән, бик зур эшләр башкарылыр дигән өметем бар. Анда норматив документлар тәгаенләнә. Барлык эш кәгазьләре турында нигезләмә урын ала. Гомумән, эчке һәм тышкы язма атрибутлар турында аерым бер документ булдырырга кирәк. Программада иҗтимагый структуралар төзү мәсьәләсе дә куелды. Әйтик, гаиләдә туган телне саклау проблемасы. Бу әлегә безнең бәгырьдә утырган таш кебек. Синең оян-гаиләң нинди, иманлымы ул, милли җанлымы? Гореф-гадәтләрең, мирасың, тарихың, телең — аның өчен кадерлеме?! Гаилә нигезенә шушы асыл кыйммәтләр салынса, буыннан-буынга әманәт булып сакланса гына татар милләте, татар теле заман зилзиләләренә каршы тора алыр.

*— Ким Мөгаллимович, Сезнең бу гаять игелекле гамәлләрегездә уңышлар телибез.*

— Әйе, талбишекләрне өй түренә иң элек әнкәйләр, әткәйләр элә. Ил түрендә аны милләт тибрәтә. Җырдан-моңнан үрелгән талбишекләргә, татарның талбишегенә киләчәк гасырлар түрендә дә тибрәлергә, тибрәнергә язса икән.

*2004*

## СҮЗДӘН — ГАМӘЛГӘ

*—Быел Татарстанда халыкара туган тел көненә багышлап күп төрле чаралар үткәрелде. Шул кысаларда Казанда «Татарстан Республикасында телләрнең кулланылышы һәм үсеш мөмкинлекләре» дигән темага фәнни-гамәли конференция дә уздырылды.**

*Ким Мөгаллимович, кыскача гына конференциянең эше, анда күтәрелгән мөһим проблемалар турында сөйләсәгез иде.*

— Бүгенге көндә кешелек җәмгыяте үзенең кабатланмас мә-

* Әңгәмәдәш — журналист Наил Гыйззәтуллин.

дәни мирасы булган телләр күптөрлелеген югалта бара. Галимнәр белдерүенчә, элегрәк чорда дөньяда сигез меңгә кадәр тел исәпләнгән, бүген исә Җир шарында алты мең чамасы тел бар. Әмма бу телләрнең дә яртысында сөйләшүчеләр саны ун меңнән артмый, ә чирегендә аралашучылар хәтта бер меңнән дә кимрәк.

Соңгы өч гасыр дәвамында телләрнең юкка чыгу күренеше аеруча артты. Бу хәл бигрәк тә Америка континентына һәм Австралиягә хас. Әмма Европада да берничә дистә телгә шундый ук куркыныч яный. Быел республикабызда Халыкара туган тел көне атналык буларак билгеләп үтелде. Бу эштә Мәгариф, Мәдәният министрлыклары белән беррәттән, башка бик күп оешмалар һәм уку йортлары катнашты. Ә инде конференциягә килгәндә, әлеге чараның пленар утырышында мин яңа шартларда телләр турындагы Законны гамәлгә ашыру мәсьәләләре турында чыгыш ясадым. Моннан тыш, конференциядә Казан дәүләт педагогика университеты ректоры Җ. Нигъмәтов, Татарстан мәгариф министры урынбасары Л. Ногманова, Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитетының бүлек башлыгы Р. Вәлиуллин, Казан дәүләт медицина университеты проректоры, философия фәннәре кандидаты Л. Мөхәррәмова, Казан шәһәре хакимиятенең милли эшләр бүлеге башлыгы И. Арсланов докладлары тыңланды. Чыгышларда Татарстан халыклары телләрен саклау һәм үстерү буенча күп кенә файдалы фикерләр әйтелде.

Әйе, республикабызда телләр мәсьәләсенә зур игътибар бирелә. Халыкара туган тел көнен билгеләп үтүне дә без, Россиядә беренчеләрдән булып, өч ел элек башлаган идек. Аңа багышланган чаралар ел саен акрынлап-акрынлап киңәеп килә, алар җәмгыятебезнең туган тел мәсьәләсенә игътибарын җәлеп итүгә юнәлтелә. Әлеге чараларны уздырганда, аларны чишү юллары да өйрәнелә. «Intertat.ru» электрон газетасында on-line конференция вакытында да миңа милләттәшләребез 40 лап сорау бирделәр. Бүгенге көндә халык бу мәсьәлә белән кызыксына. Алар алда торган проблеманы тирәнрәк күзаллыйлар, сораулар хөкүмәт исеменә дә, җитәкчелек исеменә дә төгәл бирелә. Әйтик, дәүләт учреждениеләрен дә татар теленең ни өчен тиешле дәрәҗәдә үсә алмавы борчый аларны.

Урамнардагы барлык язма мәгълүматларның тиешле дәрәҗәдә була алмавы борчый. Шул ук мәктәпләрдәге проблема, югары уку йортларында, аеруча һөнәри белем бирү системасында татар теленең торышы тиешле дәрәҗәдә түгел.

— *Татарстанда телләр турында Закон кабул ителүгә дистә елдан артык вакыт узды. Шушы чорда бу тармакта нинди дә булса үзгәрешләр булдымы?*

— Җәмгыять тарафыннан таләпләр кискен куелган бер вакытта тел сәясәтен өйрәнү, телнең актуаль проблемаларын тирәнтен аңлату өчен квалификацияле кадрлар әзерләргә, аерым, махсус структуралар булдырырга кирәк. Узган 10—12 ел эчендә шактый гына эшләр башкарылды, зур гына уңышларга ирештек кебек, әйтик, республикада психологик яктан татарлар гына түгел, татар булмаган халыклар да инде тел мәсьәләләренең шактый мөһим икәнлегенә инандылар, шуны аңладылар. Шулай да бу проблеманы фәнни-теоретик яктан тирәнрәк өйрәнергә, бүгенге көнебезгә тулы анализ ясарга, иртәгәге көнебезне ачык күзалларга омтылырга кирәк. Россия Федерациясендә милли мәсьәләләргә, тел мәсьәләсенә караш без күз алдына китергәнчә, бик үк уңай якка үзгәрә дип әйтеп булмый. Шуңа күрә безгә тагын да көчлерәк, тагын да акыллырак булырга кирәк. Күреп торасыз, ничә еллар дәвамында инде, Россия Федерациясендә 1991 елда телләр турында Закон кабул ителсә дә, 1992 елда шушы Законны гамәлгә ашыру буенча Программа концепциясе эшләнеп кабул ителсә дә, телләрне үстерү программасы эшләнмәде бит! Андый документ юк. Рус телен үстерү программасы бар. Ә башка халыкларның телләрен үстерү буенча Россия күләмендәге максатчан программа кабул ителми.

— *Татар теленең бүгенге торышы, язмышы һәм аның киләчәге турында Сез ничек уйлыйсыз?*

— Әйтүемчә, дөньяда күп телләр юкка чыга. 2000 елдан да артык яшәгән телләрне хәзер бармак белән генә санарлык. Алар барысы да берничә гасыр дәвамында акрынлап үзгәрә, юкка чыга бара. Шуңа күрә татар теленең киләчәге турында уйланганда, бу гади мәсьәлә түгел. Мөстәкыйль дәүләте булган телләр генә сакла-

нып кала. Россия шартларында телне саклап калу —зур проблема. Бүгенге хәлебезне аңларга, табиблар әйткәнчә, бүгенге хәлебезгә дөрес диагноз куярга кирәк. Телебезне үстерү, ныгыту юллары бармы, нинди юллар алар? Ә телебезнең хәле катлаулы. Ярый әле Татарстан бар. Бездә 1 миллион 800 мең тирәсе татар яши. Тагын 5 миллионнан артыгы читтә яши. Шуның 3 миллионы Россия төбәкләрендә. Монысы үзе бер проблема. Беренчесе: Татарстандагы халкыбызны ничек сакларга, татар телен дәүләт теле дәрәҗәсенә нинди юллар белән күтәрергә? Россиядә бу мәсьәлә белән берәү дә шөгыльләнми һәм шөгыльләнмәячәк тә. Аңа өмет итеп, кемгәдер үпкә белдереп, алар безнең проблемага игътибар итми дип күпме генә утырсак та, бернинди дә уңай җавап булмаячак.

*— Татарстанда татар һәм рус телләре икесе дә тигез хокуклы дәүләт телләре дип игълан ителде. Әмма сер түгел, рәсми оешмаларда, Дәүләт Советы сессияләрендә, башка төрле мөһим чараларда булсын, сөйләшү, башлыча, рус телендә бара. Татар теле читтәрәк кала шикелле. Сез моны ничек бәялисез?*

— Дөрес, без әлегә дәүләт теле булган татар телен рус теле дәрәҗәсенә күтәрә алмадык. Минем аңлавымча, аз вакыт эчендә аның дәрәҗәсен үстерү мөмкин дә түгел иде. Монда барлык юнәлештә, шул ук театрларыбыз, радио, телевидение аша эшләргә кирәк. Мин инде бернәрсә дә эшләнми дип әйтмәс идем. Без Дәүләт программасы буенча эшлибез. Әмма эшләнеп бетмәгәннәре дә бар, телнең функциональ яшәешенең аерым өлкәләре бар. Аларны эшләү беренче чиратта татар кешеләренең үзләреннән дә тора. Бервакыт Европа Советыннан килгән Ирландия вәкиле: «Әгәр сезнең телегез бетүгә дучар ителгән икән, бу аның бетүе котылгысыз булганнан түгел, ә телне саклап калу өчен сезнең акылыгыз һәм кыюлыгыгыз җитмәүдән»,— дигән иде. Шуңа күрә без гаепне, беренче чиратта, үзебездән эзләргә тиешбез.

*— Бу юнәлештә гаммәви мәгълүмат чаралары нәрсә эшли ала?*

Мәгълүмат чараларының, газеталарның вазифалары, аларга йөкләнгән бурычлар бик үзенчәлекле. Күп кенә гаммәви мәгълүмат чаралары Татарстандагы проблемалар белән генә шөгыльләнәләр.

Татарлар, Татарстаннан тыш, БДБ илләрендә, шулай ук ерак чит илләрдә дә күпләп яшиләр. Менә аларны ничек хәл итәргә? Татарстан җитәкчеләре күп вакыт безнең мөмкинлекләребез, вәкаләтебез чикләнгән, без читтәге милләттәшләребезгә турыдан-туры ярдәм итә алмыйбыз, финанс мөмкинлекләребез дә чикле диләр. Мәгълүмат чаралары, газеталар бу мөһим мәсьәләләрне җентекләп өйрәнергә, ачыкларга, чит төбәкләрдә яшәүче милләттәшләребез тормышын яктырткан, аларны борчыган нәрсәләр турында проблемалы язмаларны даими рәвештә биреп барырга тиешләрдер дип фикер йөртәм мин. Ә сез үзегез ничек уйлыйсыз? Әйдәгез, бергәләшеп уйлашыйк, проблемаларны бергәләп хәл итик.

*2004*

## ӨМЕТ БЕРКАЙЧАН ДА ЮГАЛМАЯЧАК

*Пермь каласында «Россиянең милли телләре: төбәк аспектлары» дигән халыкара фәнни-гамәли конференция булып узды. Әлеге конференциягә Татарстан делегациясе Министрлар Кабинетының Мәдәният һәм Татарстан халыклары телләрен үстерү бүлеге башлыгы Ким МИҢНУЛЛИН җитәкчелегендә барган.**

— Бу конференциядә катнашырга мин үзем теләк белдердем. Ни өченме? Чөнки шушы эшчәнлек белән менә инде 10 ел шөгыльләнәм, әмма Россия күләмендә үткәрелгән мондый чараларга бер генә тапкыр да чакырганнары булмады. Милли мәсьәләгә кагылышлы чаралар бездән башка гына — төбәкләрнең фикеренә колак салмыйча гына үткәрелә кебек. Әнә шуңа да Пермьдә булачак конференция бик нык кызыксындырды. Беренчедән, анда башкарма хакимият вәкилләре катнашачагы хәбәр ителгән иде. Ул бит РФ Төбәкләрне үстерү министрлыгы, Пермь өлкәсе һәм Коми-Пермяк автономияле округларының хакимиятләре тарафыннан оештырылды. Икенчедән, конференциядә Россиянең бик күп төбәкләреннән галимнәр, мөгаллимнәрнең катнашачагы да кызыксындырды. Димәк, алардагы тәҗрибә белән танышыр-

* Әңгәмәдәш — журналист Нәсим Акмал.

га, фикер уртаклашырга мөмкинлек булачак дигән сүз. Аннары безнең өчен иң мөһиме — шушы очрашуда Европа Хартиясен тикшерергә вәгъдә ителгән иде, мондый эштә катнашмый калу безгә инде һич тә ярамый. Зур өметләр баглап юлга чыктык без Пермь якларына.

*— Ул өмет аннан кайткач та зурлыгын югалтмадымы?*

— Бездә өмет беркайчан да югалмаячак. Конференция канәгатьләндереп җиткермәсә дә, ул Россиядә милли сәясәтнең, телләргә мөнәсәбәтнең бүгенге көн үзенчәлекләрен тирәнрәк аңларга, үз сүзебезне, үз карашыбызны башкаларга җиткерергә мөмкинлек бирде. Ә бит андый форсат гел чыгып тормый, һәм мондый сөйләшү-аңлашулар кайчан да булса бер нәтиҗәсен бирми калмаячак. Мин бу фикергә, быел сентябрь аенда Мәскәүдә үткәрелгән «Телләр һәм мәдәният» дигән халыкара конференциядә катнашып кайткач, бик ныклап инандым. Республиканың, татар халкының позициясен дөньяга ирештерү өчен, һәр мөмкинлектән файдаланырга кирәк икән!

*— Ким әфәнде, төп сүздән бераз гына читкәрәк китеп, Мәскәүдәге шул конференция турында да сөйләшеп алыйк әле. Чөнки анда ясаган чыгышыгыздагы кайбер фикерләр, үзегез Казанга кайтып җиткәнче үк, зыялылар арасында таралып, канатлы сүзләр булып йөри башлады.*

— Ул конференцияне Мәскәү чит телләр институты, Россия Фәннәр академиясе, Лингвистика фәннәре академиясе оештырды. Соңгысының ректоры Эмма Володарская, минем белүемчә, Кырым татары, Ташкентта туып үскән. Эмма Федоровна Казанның 1000 еллыгына багышланган тантаналарга килгән иде. Без аның белән шунда таныштык, һәм ул әлеге конференциягә чакырып китте.

Ике көн дәвам иткән бу халыкара җыен Россия Фәннәр академиясенең иң затлы Президент залында үтте. Сөйләшүдә академик Челышев, Михальченко кебек исемнәре дөньяга танылган галимнәр катнашты. Югалып баручы халыкларның телләре Фонды президенты Николас Остлар да килгән иде. Миңа, Эмма

ханымның булышлыгы белән, чыгыш ясарга 25 минут вакыт бирделәр, ләкин ул бик күпкә озаграк дәвам итте. Чөнки сораулар явып кына тора. Татарстан белән кызыксыналар. Әмма, ни гаҗәп, аларны татар теленең язмышы түгел, ә Татарстанда рус теленә мөнәсәбәт күбрәк борчый икән. Гаммәви мәгълүмат чараларындагы безнең республиканы каралтып күрсәтүгә юнәлдерелгән сафсата нәтиҗәсез калмаган, димәк. Чын вазгыятьне аңлатып бирергә туры килде.

Шул ук утырышта Мирфатыйх ага Зәкиев тә чыгыш ясады. Фәннәр академиясендә чит ил галимнәре катнашындагы форумда бер республикадан ике кешенең сүз алуы,— минемчә, зур эш. Без анда Россия шартларында милли мәсьәләне, телләр мәсьәләсен көйләү, хәл итү мөмкинлеге булуын дәлилли алдык кебек.

*— Николас Остларга әйткән сүзләрегез дә күпләрне таңга калдырган, дип ишеттек...*

— Әлеге мөхтәрәм галим җитәкчелегендәге оешма үлеп баручы телләрне тарихка теркәп калдыру, аларны яңадан тергезү технологиясе белән шөгыльләнә. Мондый хезмәтнең барлыкка килүе юкка гына түгел, чөнки ЮНЕСКО мәгълүматларына караганда, дөньяда ай саен 2—3 тел юкка чыга бара. Остлар әфәнденең күңеле изгелектә, әлбәттә. Ләкин яраланган арысланның җан тәслим кылганын көтеп, баш очында бөтерелгән козгыннар күз алдына килде. Әлеге Фондның да ризыгы — үлеп баручы телләр бит. Шуңа күрә мин аңа: «Хөрмәтле Николас әфәнде, без сезгә артык эш тудырмаска тырышырбыз. Туган телебезне саклау өчен барысын да эшләячәкбез!» — дип мөрәҗәгать иттем. Остлар әфәнде — сизгер кеше, ул беркадәр юморга төреп әйтелгән бу сүзләргә бик тә җитди мәгънә салынганын төшенде кебек.

*— Инде Мәскәүдән Пермьгә кайтыйк. Ни өчен халыкара конференция уздыруга шушы шәһәрне сайлаганнар?*

— Моның төп сәбәбе анда бераз аралаша башлагач аңлашыла төште кебек. Биредә үткәрелгән референдум нигезендә 1 декабрьдән Коми-Пермяк автономияле округы Пермь өлкәсенә эреп кушыла бит. Димәк, коми-пермяклар барлы-юклы милли дәүләт-

челекләреннән дә колак кагалар дигән сүз. Бу конференция аларны бераз юату-юмалау өченрәк оештырылган сыман тоелды. Аның Пермь дәүләт педагогия университетында коми-пермяк — рус бүлегенең 50 еллыгына туры китерелүе шул максаттан булгандыр, күрәсең.

Җыенда Венгриядән, Финляндиядән, Россиянең 17 төбәгеннән вәкилләр катнашты. Россиядәге сәясәткә йогынты ясый алырдай абруйлы галимнәрнең булуы конференциягә саллылык өстәде.

Татарстан вәкилләре монда да игътибар үзәгендә булды. Академик Мирфатыйх ага Зәкиевнең, галимнәребез Алсу Вәлиева, Фәһимә Хисамова, Фирая Гаффарова, Фәүзия Сәгъдиеваның Татарстанда тел вазгыяте һәм аның проблемаларына багышланган чыгышлары зур кызыксыну уятты. Мин исә республикабызда телләр турындагы законнарны тормышка ашыруның барышы, килеп туган кыенлыклар белән таныштырдым. Мондый сүзне без дә әйтмәсәк, тагын кем әйтер дип, кайбер мәсьәләләрне мөгезеннән алырга да туры килде. Мәсәлән, ни өчен әле бу конференциядә башкарма дәүләт органнары вәкилләре юк дәрәҗәсендә? Ә бит без, әйтик мин, нәкъ менә шулар белән очрашырга, тәҗрибә уртаклашырга өмет итеп килгән идек. Аннары социолингвистика мәсьәләсенә бик ныклап туктадым. Мәскәүнең үзендә шөгыльләнәләр, әмма төбәкләрдә ул бик тә зәгыйфь куелган. Әйтик, безнең шартларда ике тел бердәй тигез хокуклы булып яши аламы? Әгәр яши алсалар, моңа нинди юллар белән ирешергә, аның механизмы ничек? Миңа, практик буларак, эшне дөрес алып бару өчен фәнни анализ, фаразлар һәм киңәшләр кирәк. Шулар өстенә әле мин Россиядә, БДБ илләрендә, чит илләрдә телләр вазгыятен белеп торырга тиеш. Дөнья күләмендә, мәсәлән, күпмилләтле дәүләтләрдә бездәге кебек проблемалар ничек хәл ителә? Менә шуларның барысын да өйрәнүче, гомумиләштерүче һәм киңәшен бирүче гамәли фән кирәк бүген безгә.

*— Татарстанда бу юнәлештә эшләүче галимнәр бардыр бит?*

— Бездә социолингвистика юк дәрәҗәсендә. Әйтик, төрле конкрет документлар мәсьәләсендә мәскәүлеләр белән аяк терәп бә-

хәсләшә алырлык белгечләребез кайда? Андый кадрлар әзерләнми дә. Ә бит чагыштырмача мөстәкыйльлек шартларында узган 15 ел эчендә әзерләп була иде. Без мөмкинлектән дөрес файдалана белмәдек. Их, менә Татарстан Фәннәр академиясе каршында һич югы 5—6 галим эшләгән бер аналитик үзәк булдырасы иде!

Пермь конференциясендә Татарстан тәҗрибәсенә игътибар зур булса да, кайберәүләрнең безгә карата негатив карашы да сизелми калмады. Мәскәүдәге Мәгарифтә милли мәсьәләләр институты директоры урынбасары Ольга Артеменко (РФ Конституцион судында Татарстанда татар телен укыту, латин графикасын кайтару мәсьәләләре тикшерелгәндә, ул экспертларның берсе булган иде), ике телне бер үк дәрәҗәдә укыту — укучыларга кирәгеннән артык нагрузка биреп, аларның сәламәтлегенә зыян китерә, дип гаепләп чыкты. «Татар балаларының сәламәтлеген кайгыртуыгыз өчен рәхмәт, Ольга Ивановна, — дидем мин аңа, — ләкин руслашкан татар балалары өчен борчылуыгыз гына сизелмәде...»

— *Европа Хартиясен тикшерү ничегрәк булды?*

— Без аны баштан ук тиешле дәрәҗәдә узмас дип шикләнгән идек. Шулай булды да. Әлеге документка Россия 2001 елда кул куйды. Шарты шул: бер ел эчендә парламент тарафыннан ратификацияләнергә тиеш. Инде 4 ел үтеп тә китте, ә ул һаман расланмаган хәлдә. Димәк, аның кабул ителүе җитәкче даирәләрне әллә ни кызыксындырмый. Әгәр ул расланса, Россия үзендә яшәүче халыкларның телләрен саклау җаваплылыгын үз өстенә алачак дигән сүз бит. Кемнең күрәләтә мондый камыт киясе килсен? Конференциядәге сөйләшү дә әзерлекле булып чыкмады. Мәскәүләр өстән-өстән генә мәгълүмат бирү белән чикләнделәр дә, әлеге документны тәнкыйтьләү башланды. Янәсе, Россия әле мондый адымга әзер түгел; әлеге Хартиягә барлыгы 27 ил кул куйган, шуларның унысы әле дә ратификацияләмәгән икән. Әгәр документ расланса, эте дә, бете дә Европа судына чаба башлаячак, дип тә куркытмакчылар.

Безнең яктан Мирфатыйх ага бу документның Россиягә үтә дә кирәк булуын, аның милли сәясәтне көйләү юлында яңа

мөмкинлекләр ачуын дәлилләп сөйләде. Ләкин каршы як козырь кәртен тартып чыгарды: Хартия кушканча яшәү өчен акча юк бездә!

Шунда 60 нчы елларда Татарстанда булган бер мәзәк хәлне сөйләп бирергә туры килде. Ул чакта татар халкының олуг язучылары, шагыйрьләре яшьләр өчен журнал чыгаруны сорап обкомга барганнар. «Сез монда зур акчалар тотып журнал чыгарырга йөрисез, ә Африкада, беләсезме, күпме кеше ачлыктан кырыла!»— дип кайтарып җибәргән ди аларны бер түрә. Бүгенге көндә Европа Хартиясен акча кытлыгына сылтап кабул итми калдырсак, без дә шул обком вәкиле дәрәҗәсендәрәк фикер йөрткән булачакбыз. Ярый, татар халкы ничек тә түзәр, безнең хәлләр әле бөтенләй үк мөшкел түгел, дидем мин, ә менә башка халыклар, әйтик, чувашлар нишләр? Әнә ич, чуваш галимнәре үзләре үк исәпләп чыгарган: әгәр ассимиляция бүгенге тизлек белән дәвам итсә, имештер, тагын 118 елдан Җир йөзендә чуваш телендә сөйләшүче кеше калмаячак. Тулы бер милләтләрне карап торып юкка чыгарабызмы? Менә шул рәвешчә, шактый ук кискен итеп сөйләргә туры килде. Әмма безнең сүзләрнең дә, гомумән, Хартия мәсьәләсендә барган сөйләшүнең дә уңай нәтиҗә бирүе бик тә икеле.

*— Сез сөйләгәндә уйлап куйдым: бер караганда, милли телләрне саклап калу өчен әллә ни кирәк тә түгел бит югыйсә, ләкин ни өчендер ул бездә беркайчан да уңай хәл ителми...*

— Үтә дә катлаулы мәсьәлә бу. Чөнки туган телләрен саклаган халыклар иртәме-соңмы мөстәкыйльлеккә ирешәчәк. Россия моны бик яхшы аңлый. Без дә белеп торабыз. Шуңа күрә саф акыл, зирәклек белән иҗтиһад итәргә туры килә дә инде.

*2005*

## КАК РАЗВИВАЮТСЯ ЯЗЫКИ В ТАТАРСТАНЕ

В Татарстане примерно равное количество русских и татар. С русским языком у нас все более или менее: это главный язык федерации и федерального центра, существуют давние непрерывные традиции его преподавания и изучения, центров русского языка

по стране немало, плюс сама жизнь диктует необходимость его знания. С татарским же не все так просто. Советский Союз разрушил практически все возможные формы исследования и практики родного языка. Время же демократических реформ дало сильный толчок вперед в этой области.

Что же будет с этими языками через десять лет? Какие меры принимают государственные органы?

*— Ким Мугаллимович, как вы оцениваете прошедшие 15 лет деятельности по развитию языков в Республике Татарстан?**

— Я, конечно, не могу дать объективную оценку в полной мере. Я уже более 10 лет работаю в государственных органах и пришел сюда именно для того, чтобы заниматься развитием языков. До меня никто этим на уровне госвласти не занимался. Сначала я работал в отделе культуры правительства, а в 1999 году мы создали в Кабмине единственный в своем роде отдел в России, который занимается именно языками. Первыми идут, естественно, два государственных языка — русский и татарский, затем остальные.

В Татарстане во многих областях практические дела намного обогнали теорию. Татарстан преодолел за эти годы этап, который, несомненно, оставит значительный след в истории. В новый XXI век мы вошли уже с опытом, открывая большие возможности. Наша работа повлияла и на языковую, и на национальную политику в России. Республика находится на первом месте в федерации в этой сфере и является локомотивом изучения, разработки и внедрения в практику норм, регулирующих вопросы языка. Например, уже во второй половине 90-х годов к нам приезжали перенимать опыт из многих регионов: Чувашии, Башкортостана, Якутии и других республик, из-за рубежа. Они каждый раз находили для себя что-то новое, пищу для размышлений, готовые модели работы. Мы только рады, если другие могут воспользоваться нашим опытом.

Когда я начал работать в Кабмине в 1996 году, здесь практически ничего не было. Были только распечатки принятого в 1992 году республиканского закона о языках, соответствующая программа

* Беседовал журналист Ильшат Саетов.

и несколько постановлений. То есть весь багаж знаний, разработки, нормативные документы (показывает полки, заполненные книгами, документами и журналами — *И.С.*), а также позиция по языковым вопросам — это все появилось за последние десять лет.

Но нельзя сказать, что удается все время выдерживать последовательное развитие языков. И отношения с федеральным центром не всегда были одинаковые, и наши дела не всегда шли успешно. Особенно беспокоят последние два-три года.

В Татарстане во многих областях практические дела намного обогнали теорию. В наших вопросах одна из самых главных проблем — непроработанность научно-практической базы работы. Мы в недостаточной мере анализируем международный и российский опыт, не извлекаем в полной мере оттуда уроки, не адаптируем другие модели и алгоритмы языковой политики к нашей ситуации.

Второй болезненный вопрос — кадры. Из первой проблемы явствует, что кадров для научной работы у нас мало или практически нет. За 15 лет мы должны были уже воспитать кадры, которые бы занимались всем спектром языковых проблем.

*— Насколько выполнены задумки и претворены ваши желания?*

— Я пережил большой этап своей жизни, занимаясь развитием языков, и могу сказать, что это было самое счастливое время в моей жизни. Я ощущал вкус работы, я ею жил. Очень многие мысли воплотились в жизнь, но есть и те, которые реализовать не удалось. Я с конца 90-х годов мечтал о создании специальной структуры при Академии наук или Институте языка и литературы (ИЯЛИ). В этом центре должны работать хотя бы 5—6 человек, которые будут заниматься конкретно проблемами национально-языковых от-ношений.

Может быть, моя вина, что я пока не смог объяснить важность создания этой структуры, где нужно собрать людей, занимающихся социолингвистикой, политикой и другими аспектами развития языка. Подобный центр может вырабатывать концептуальные основы языковой политики и предлагать различные решения, из которых мы могли бы выбрать самые эффективные.

*— А почему ИЯЛИ не выполняет эти функции?*

— Там сейчас работают около 70 научных сотрудников в шести отделах: фольклора, искусства, литературы, текстологии, языкознания и лексикографии, что для нас явно недостаточно. У языковедов, как у врачей, много специализаций. Поэтому необходимо создавать новую структуру с языковыми специализациями, требующими знаний в области национальной политики, общественных, международных отношений и других современных наук.

*— А Татарский государственный гуманитарно-педагогический университет не может этим заняться?*

— Гуманитарный университет не может быть панацеей. Вопросами подготовки национальных кадров, вопросами двуязычия, преподавания на двух государственных языках должны заниматься все учебные заведения. Кроме того, вуз не занимается академической наукой, у него свои задачи — готовить кадры. В вузе используют фундаментальные исследования для создания учебников, пособий, но сами такими разработками практически не занимаются.

*— Что необходимо делать для развития языка?*

Равнозначное знание двух государственных языков — это плюс для любого человека. Мы два года назад приняли программу развития языка. Этот документ привнес много нового, в то же время последовательно продолжая политику, проводимую ранее. У татарского языка будущее есть, если программа будет реализована.

Для развития языка необходим языковой центр, о котором я уже говорил. Также нужна окологосударственная структура, которая бы следила за выполнением закона о языках и этой программы. Ранее был общественный Комитет по языкам при Кабмине РТ, его расформировали, новый еще не создан. Мы свои предложения направили премьер-министру РТ, надеемся, что он возглавит совет по реализации законодательства о языках при Правительстве РТ. Языковые вопросы нельзя отдавать на откуп какому-либо отдельному министерству, оно не сможет координировать деятельность во всех сферах, тем более давать указания другим ведомствам.

Правительственный же совет будет стоять над ними. Мэры городов, например, будут отчитываться перед премьером: если что-то у них не в порядке, наверняка они это исправят гораздо быстрее, чем если бы им указало на это другое лицо или ведомство. Перед заседаниями совета инициативные группы из депутатов различного уровня, журналистов и заинтересованных граждан будут проверять исполнение закона на местах, осуществлять первичный надзор. Также будут приниматься обращения людей по нарушению того или иного пункта. Необходим контроль и снизу, и сверху.

*— Какие ожидаются результаты деятельности в области развития языков к 2016 году?*

— Многое опять-таки прописано в программе. Там все разделено на несколько сфер: организационное обеспечение, функционирование татарского и русского языков в области делопроизводства, информации, потребительского рынка, учебы и воспитания, формирования общественного мнения. Также предусмотрены меры по сохранению других языков республики, а татарского языка — за пределами РТ. По каждому из этих аспектов предполагается достижение определенных результатов. Для примера, в сфере делопроизводства предусмотрена организация информационного обслуживания населения на вокзалах, в аэропортах на двух языках; разработка типовых образцов деловых бумаг на русском и татарском и так далее. То есть желаемое будущее — в этой программе.

Создание такого нормативного акта — очень важное дело, потому что без юридической базы сейчас трудно что-либо урегулировать. И заниматься этим должны мы, никто за нас ни в федеральном центре, ни на местах этого не будет делать. Более того, выполнение этих норм год от года становится все более сложным делом. Кому-то эти шаги не нравятся, вызывают неодобрение. Хотя мое убеждение таково, что равнозначное знание двух государственных языков — это плюс для любого человека. В любом случае регламент не должен быть жестко наложен на многонациональное общество, нормы следует внедрять последовательно и логично.

*2006*

## ЭЧТӘЛЕК


Кереш сүз ........................................................................................ 5
Душа народа в его языке. *Ш.Мулаянов* ............................................ 7

**Р. М. МИҢНУЛЛИН**

Туган тел бәйрәме ........................................................................ 11
Балалар китабы — туган тел ачкычы .......................................... 12
Федерализм и языки национальных меньшинств — состояние и перспективы на примере Республики Татарстан ............. 14
Татар теленә ихтыяҗ... ................................................................ 17
Әле Мамадышка гына илтә ........................................................ 19
Телләр турындагы Закон — игътибар үзәгендә ................. 24
«Потомки скажут нам спасибо...» .......................................... 29
Теле барның — иле бар ............................................................... 33
Бер-беребездән тел яшермик! ...................................................... 40
Латинга күчүдән Россия иминлегенә куркыныч яныймы? ..... 44
Телсез халык та, республика да була алмый ............................ 47
Забвение или интеллектуальная деградация? ................... 53
Кузгалырга вакыт! ......................................................................... 59
Авыл исемнәре турында ............................................................ 63
«Подумаешь, авыл исемнәре!» ................................................... 69
Яңа дәреслекләр кирәк! ............................................................... 74
Ни хәлдә син, туган тел?.. ........................................................... 77
Внедрение реального двуязычия .............................................. 86

Кем ул Ким Миңнуллин? *М.Вәлиев* .............................................. 101

**К. М. МИҢНУЛЛИН**

Яңа алфавит проекты турында ................................................. 107
Телләр сагында — дәүләт ........................................................... 109
Инструмент и ключ науки ......................................................... 117

Закон о языках в действии ... 121
Югары белемне — татар телендә ... 128
Время диктует свое ... 132
Сынаулар алда әле ... 136
Тел язмышы — халык язмышы ул ... 140
Татары будут писать ... PO-NOVOMU! ... 145
Латиницу мы выстрадали за многие годы ... 150
О ситуации в области языковой политики ... 155
Реформа алфавита меняет буквы не по политическому курсу ... 158
Пришло время ответственных решений и реальных дел ... 168
Камыр-батыр против Бэтмена ... 170
Безгә берләшергә кирәк ... 177
Острые грани языковой политики ... 181
Материалы по вопросам реформы письменности татарского языка ... 189
Предложения по решению первоочередных вопросов реализации законодательства о языках в Республике Татарстан... 196
Телләрне үстерүгә мондый караш башка төбәкләрдә юк ул ... 198
Йөзебез югалмасын! ... 206
Татарның талбишеге ... 209
Сүздән — гамәлгә ... 216
Өмет беркайчан да югалмаячак ... 220
Как развиваются языки в Татарстане ... 225

Учебное издание

**Миннуллин** Роберт Мугаллимович
**Миннуллин** Ким Мугаллимович

СУДЬБА ЯЗЫКА — СУДЬБА НАРОДА

Казань. Издательство «Магариф». 2008

*На татарском и русском языках*

Уку-укыту басмасы

**Миңнуллин** Роберт Мөгаллимович
**Миңнуллин** Ким Мөгаллимович

ТЕЛ ЯЗМЫШЫ — ХАЛЫК ЯЗМЫШЫ

Редакторлары *Л. Ә. Гыйззәтуллина, Г. Р. Зарипова*
Тышлык рәссамы һәм бизәлеш редакторы *Л. С. Золондинова*
Техник редакторы һәм компьютерда биткә салучысы *Г. Г. Камалова*
Корректорлары *А. А. Дәүләтова, Р. Ә. Фәйзуллина*
Рәсемнәрне компьютерда эшкәртүчеләре
*Л. Р. Вафина, Э. Ф. Нурмөхәммәтова*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 12.12.2008. Форматы 60 × 84 $^1/_{16}$.
Офсет кәгазе. «Нимбус» гарнитурасы. Офсет басма.
Шартлы басма табагы 14,5. Тиражы 500 д.

«Мәгариф» нәшрияты. 420059. Казан, Оренбург тракты, 20а.
Тел./факс (843) 277-52-88; 277-52-62.
E-mail: magarif@mail.ru
http://www.magarif.com

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы» ААҖ.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.